Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова

# ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ 8

Методик әсбап



Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова

# ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ

**8 нче сыйныф**

Методик әсбап

Төп гомуми белем бирү оешмаларында
(туган (татар) телендә сөйләшүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

КАЗАН
2024

УДК 82 (072)
ББК 74.268.3 (=632.3)
А12

Методик әсбап
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать
институтында эшләнде

**Абдуллина Д. М.**

А12 Родная (татарская) литература. Туган телдәге әдәбият. 8 класс. Методическое пособие : для преподавателей образовательных организаций основного общего образования, работающих с обучающимися, владеющими родным (татарским) языком / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мухарлямова. – Казань, 2024. — 154 б.

Методик әсбапта 8 нче сыйныфта «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметыннан дәреслек белән эшләү тәртибе яктыртыла. Биредә предметны өйрәнүгә куелган максат-бурычлар, предметны өйрәнүдә планлаштырылган нәтиҗәләр, тематик планлаштыру, дәрес эшкәртмәләренең үрнәкләре бирелә.

Әсбап урта сыйныф укытучыларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

УДК 82 (072)
ББК 74.268.3 (=632.3)

© Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, 2024
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2024
© Абдуллина Д. М., Мөхәрләмова Г. Н., 2024

## ХӨРМӘТЛЕ ХЕЗМӘТТӘШЕБЕЗ!

Әлеге методик ярдәмлек дәреслек белән эшләүне беркадәр җиңеләйтү, юнәлеш бирү максатында әзерләнде.

Әдәбият — заман куйган таләпләр югарылыгында шәхес тәрбияләү һәм интеллектуаль, әхлакый-эстетик үсешенең дәрәҗәсен билгели торган төп предметларның берсе. Матур әдәбият әхлакый идеаллар турында күзаллауны, кешенең үзенә, дөньяга иҗтимагый һәм эмоциональ-кыйммәти мөнәсәбәтен формалаштыруны тәэмин итә һәм туган телне үзләштерү, камилләштерүдә дә төп җирлек булып тора.

Әдәбият дәресләрендә шәхснең мөстәкыйль үсеше өчен әдәбиятны өйрәнүнең әһәмиятен аңлый торган, үз фикерен телдән һәм язмача дөрес тәкъдим итә, дәлилләп башкаларга җиткерә белә торган китап укучы тәрбияләнә. Алай гына да түгел, укучы, дөньяны һәм бу дөньяда үзен танып белү өчен даими китап уку ихтыяҗы кирәклеген аңлый.

Мәктәптә әдәбият укытуның максаты шулай ук әдәби текстны эмоциональ кабул итү, образлы һәм аналитик фикерләүне үстерү, иҗади күзаллау, әдәби әсәр текстларын эчтәлек һәм форма берлегендә үзләштерү, төп тарихи-әдәби мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне өйрәнү, әдәби әсәрләрне уку һәм анализлау күнекмәләрен булдырудан гыйбарәт. Моннан тыш әдәби әсәрләр укучыларның телен баету, аларның сөйләм культурасын һәм коммуникатив күнекмәләрен формалаштыруда төп чыганак хезмәтен дә үти.

Мәктәптә сүз сәнгате яңа эчтәлектәге уку фәне — «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметы кысаларында өйрәнелә. Бу — туган (татар) телдәге әдәбият укытуның мөмкинлекләрен киңәйтте, ягъни әлеге предмет татар баласын туган телдәге әдәбиятка якынайта, сәнгатьнең бер төре булган әдәбият аша укучыны татар теле, тарихы, мәдәнияте, әхлагы, милли холык, милли кыйммәтләр белән таныштыра. Шуннан чыгып, аның максат-бурычлары да яңа нигездә корыла.

8 нче сыйныф дәреслеге тулысынча әдәби әсәрне оештыруда катнашкан төп сәнгати алымнарны өйрәнүгә багышлана.

«Туган (татар) телдәге әдәбият» уку предметыннан федераль эш программаларында, курсның эчтәлеге белән бергә, планлаштырылган предмет нәтиҗәләре дә яңадан каралды. Аерым алганда, төп мәктәптә, ягъни урта сыйныфларда укучыларда формалаштырылырга тиешле предмет нәтиҗәләре әдәбият белән бәйле мәсьәләләрне киңрәк планда хәл итүгә йөз тота. Шул рәвешле, укучыларда Россия Федерациясендәге рус булмаган халыклар әдәбиятлары арасында туган телдәге әдәбиятның урынын һәм ролен, шәхеснең мөстәкыйль үсеше өчен әһәмиятен, сүз сәнгате буларак әдәбиятның образлы табигатен аңлау; әдәбият әсәрләрен эстетик кабул итү; эстетик зәвык формалашу; төрле стиль һәм жанрдагы текстларны укый белү; үз фикереңне дәлилләү, фикер алышуда катнашу; әдәби әсәр турында фикер алышканда гади әдәби төшенчәләрне белү; тематика, проблематика, образлар дәрәҗәсендә төрле халыкларның фольклор һәм сәнгать әсәрләре арасындагы бәйләнешләрне билгеләү (охшашлык һәм аерымлык принцибы буенча); сүзләрне эстетик функциясендә аңлау; әдәби әсәрне анализлау: аның кайсы әдәби төргә һәм жанрларга каравын билгели алу; темасын, идеясен аңлау; әдәби геройларга характеристика бирү; бер яисә берничә әсәр геройларын чагыштыру кебек предмет нәтиҗәләр алга чыгарыла.

8 нче сыйныфта әдәбият дәресләренең төп бурычы — әдәби әсәрне сәнгать әсәре буларак кабул итәргә өйрәтү. Укучылар «Әдәби әсәр ничек туа? Ул тормыш чынбарлыгының күчермәсеме, әллә билгеле бер максатка хезмәт итү өчен бергә тупланган бер-берсеннән аерылгысыз өлешләрнең махсус уйланылган бөтенлегеме?» дигән сорауга җавап бирергә тиеш булалар. Билгеле, алар бу уку елында да әсәрнең эчтәлеге белән танышалар, аның геройлары турында фикер йөртәләр, бәялиләр, әсәрнең темасын, идея-проблематикасын табалар. Әсәрне тулы бөрбөтен буларак кабул итәләр. Шул ук вакытта бу бөтеннең нинди өлешләрдән торуын, әсәрдә аларның әһәмиятен дә билгелиләр. «Автор үзенең фикерен укучыга

ничек җиткерә, нинди чаралар куллана, ни өчен әсәрне укыганда без тәэсирләнәбез?» кебек сорауларга җавап табалар. Бу юнәлештә алар әсәр тукымасында мөһим роль уйнаган сәнгати адымнар: пейзаж, портрет бирелеше, әдәби деталь, әйберләр дөньясы, символлар, психологизм, әсәрнең төп нигезен тәшкил иткән хронотоп белән танышалар, әдәби әсәрдә аларның вазифаларын ачыклыйлар.

Әсәрне өйрәнү барышында укучылар эчтәлекне генә түгел, ә аны укучыга җиткерү алымнарын күрергә дә өйрәнәләр. Мәсәлән, авторның геройны укучыга тәкъдим итүнең күп төрле чараларыннан файдалануын ачыклыйлар. Автор (хикәяләүче) герой турында үзе сөйли, аның портретын тасвирлый, портрет геройны төрле яклап ача (аның социаль матди хәлен, зәвыгын, тәрбиясен һ.б.), пейзаж бирелеше аның рухи халәтенә тәңгәллектә була; психологизм алымы геройның эчке дөньясын ача, башка геройларның мөнәсәбәте, сөйләме, геройның исеме, кушаматы да аңа бәя бирә.

Әсәрне мондый ракурстан торып өйрәнү укучыларның рухи дөньясын тәрбияли; алар табигать матурлыгын күрергә генә түгел, ә аның кешегә тәэсирен тоярга өйрәнәләр. Кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрнең чишелеш юлларын аңлыйлар, аралашырга, фикерләрен башкаларга җиткерергә, янәшәдәгеләрнең күңел дөньясын аңларга, аларның кичерешләрен уртаклашырга өйрәнәләр. Язучының иҗат лабораториясенә үтеп керәләр, иҗат серләренә төшенәләр. Әсәргә анализ ясау, геройларга бәя бирү күпкә җиңелрәк бирелә башлый. Хронотоп төшенчәсен аңлау әсәрне бер юнәлештә сөйләп чыгылган вакыйгалар буларак кына түгел, ә масштаблы, реаль вакыйгалар хәлендә кабул итәргә ярдәм итә. Бу — әсәрне һәм аның аша укучыга җиткерелгән фикерне хәтердә сакларга юл ача. Димәк, укучы әсәрне укып кына калмый, ә аннан алган сабакны аңына сеңдерә һәм тормышта куллана.

Әлеге нәтиҗәләргә ирешү өчен, әлбәттә вакыт, тырышлык һәм укытучының ярдәме кирәк. Бердәм тырышлык кына уңышлы була.

# «ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ» УКУ ПРЕДМЕТЫННАН ФЕДЕРАЛЬ ЭШ ПРОГРАММАСЫ

## «Туган (татар) телдәге әдәбият» уку предметыннан федераль эш программасы

1. «Туган (татар) телдәге әдәбият» уку предметыннан федераль эш программасы (предмет өлкәсе — «Туган тел һәм туган телдәге әдәбият») (алга таба — туган (татар) телдәге әдәбияттан программа, туган (татар) телдәге әдәбият, татар әдәбияты) туган (татар) телдә һәм рус телендә белем бирүче оешмалар өчен туган (татар) телдә сөйләшүче укучылар өчен эшләнде, һәм аңлатма язуын, уку-укыту эчтәлеген, туган (татар) телдәге әдәбияттан программа үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләрен үз эченә ала.

2. Аңлатма язуы туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүнең төп максатларын, уку планы структурасындагы урынын, шулай ук эчтәлекне сайлап алуга, планлаштырылган нәтиҗәләрне билгеләүгә юнәлешләрне чагылдыра.

3. Уку-укыту эчтәлеге төп гомуми белем дәрәҗәсендә һәр сыйныфта мәҗбүри өйрәнү өчен тәкъдим ителгән эчтәлек юнәлешләрен ача.

4. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре төп гомуми белем бирү дәрәҗәсендә барлык уку чоры өчен шәхескә бәйле, метапредмет нәтиҗәләрне, шулай ук һәр уку елы өчен предмет нәтиҗәләрне үз эченә ала.

5. Аңлатма язуы.

5.1. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программа укытучыга белем бирүдә заманча тенденцияләргә һәм актив укыту методикаларына юнәлдерелгән эш программасын булдыруда методик ярдәм күрсәтү максатыннан эшләнде.

5.2. «Туган (татар) телдәге әдәбият» шәхеснең интеллектуаль һәм әхлакый-эстетик үсеш дәрәҗәсен билгели торган гуманитар белем бирү юнәлешендәге төп предметларның берсе булып тора. Туган телдәге әдәбиятны өйрәнү тормышны танып белүгә һәм чынбарлыкны модельләштерүгә булы-

ша, сүз-сурәт чаралары ярдәмендә дөньяның художестволы картинасын булдыра һәм аңа билгеле бер мөнәсәбәт тудыра, югары дәрәҗәдәге эмоциональ тәэсиргә ия.

Әдәби белем укуның һәм әдәбиятны өйрәнүнең үзенең шәхси үсеше өчен әһәмиятен аңлаган, үз фикерен дәлилли һәм аны телдән яки язма формада тәгъбир итә алган, шулай ук кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрен гармонияләштерү, дөньяны тану һәм үзен бу яшәештә күрә белү чарасы буларак системалы рәвештә укуга ихтыяҗы формалашкан укучы тәрбияләү белән бәйле.

5.3. 5—9 сыйныфларда туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү укучыларның татар әдәбияты әсәрләрен үзләштерүен, художестволы форма һәм эчтәлек бердәмлеге принципларына таянып шәрехләү һәм анализ күнекмәләрен үстерүне; милли үзаңны үстерү, этник чыгышны аңлау, системалы белемнәр алу өчен шартлар тудыру үз халкының тарихы, теле, мәдәнияте, дөньяга карашы, менталитеты, фәлсәфәсе турында белемне тәэмин итә.

5.4. Уку предметы гуманитар циклга караган башка уку предметлары белән, аеруча «Туган тел (татар теле)» һәм «Әдәбият» уку предметлары белән предметара бәйләнешләрне тәэмин итә.

5.5. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программаның эчтәлегендә түбәндәге эчтәлек юнәлешләре аерылып чыга:

халык авыз иҗаты (әкиятләр (тылсымлы, көнкүреш, хайваннар турында әкиятләр), мифлар, риваятьләр, легендалар, халык авыз иҗатының кече жанрлары (табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр), татар халык җырлары, дастаннар, бәетлар; татар фольклоры 5—8 нче сыйныфларда тәкъдим ителә);

татар әдәбияты чорлар буенча (әдәби әсәрне мөстәкыйль сәнгать әсәре һәм катлаулы әдәби процессның бер чылбыры буларак карау; татар әдәбиятын аның үсеш этапларына туры китереп өйрәнү, урта гасыр әдәбиятыннан, XVIII гасыр, XIX—XX гасыр әдәбиятыннан башлап, хәзерге татар әдәбиятына кадәр; туган телдәге әдәбиятта тарихи вакыйгаларның чагылышын күзәтү, тарихи барышта татар әдәбиятының роле турында күзаллауларны киңәйтү);

әдәбият теориясе (конкрет әдәби әсәрләрне өйрәнү процессында теоретик-әдәби төшенчәләрне үзләштерү: вакыт һәм сәнгать формалары арасындагы өзелмәс бәйләнешне күзәтү процессында әдәбият төрләре һәм жанрлары проблемасын карау, 5 нче сыйныфта аерым әсәрләр мисалында проза, лирика һәм драма үзенчәлекләре өйрәнелә, 6 нчы сыйныфта лирик әсәрләрдә, хикәядә һәм повестьта, лироэпик әсәрләрдә, драма әсәрләрендә, шулай ук фантастик, автобиографик характердагы әсәрләрдә образлылык тудыру алымнары карала, 7 нче сыйныфта укучылар хикәя, повесть, роман, драма, лирик һәм лиро-эпик әсәрләрнең жанр хасиятләрен беләләр), 8 нче сыйныфта өйрәнү объекты булып әдәби алымнар (пейзаж, портрет, символ, нәфис деталь һәм башкалар) тора, 9 нчы сыйныфта татар әдәбияты тарихы өйрәнелә.

5.6. Туган (татар) телдәге әдәбиятны укыту түбәндәге максатларга ирешүгә юнәлдерелгән:

туган мәдәниятнең мөһим өлеше буларак, туган (татар) телдәге әдәбиятка кыйммәти мөнәсәбәт тәрбияләү;

укучыларны үз халкының мәдәни мирасына һәм гореф-гадәтләренә якынайту;

үзбелем чарасы буларак, үз уку эшчәнлеген куллана алган грамоталы укучы формалаштыру.

5.7. Программаны гамәлгә ашыруның куелган максатларына ирешү туган (татар) телдәге әдәбият буенча түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүне күздә тота:

әдәби текстка комментарийлар бирү, анализлау һәм шәрехләү күнекмәләрен үстерү;

укучыларны әдәбият белемендәге анализлау элементларын кертү, аерым теоретик-әдәби төшенчәләр белән таныштыру аша, сүз сәнгате буларак, туган (татар) телдәге әдәбиятка якынайту;

татар әдәбиятының барышы белән танышу һәм аның тарихи барыш белән бәйләнешенә төшенү;

укучыларның коммуникатив күнекмәләрен (татар телендә сөйләм һәм язма диалогик һәм монологик сөйләмнәрен) үстерү;

уку күзаллауларын формалаштыру;

укучыларның әхлакый һәм эстетик хисләрен формалаштыру;

укучыларның туган (татар) телдә иҗади эшчәнлеккә сәләтләрен үстерү;

гомум уку күнекмәләрен һәм универсаль уку гамәлләрен үзләштерү.

5.8. Туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү өчен тәкъдим ителгән сәгатьләрнең гомуми саны — 170 сәгать: 5 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 6 нчы сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 7 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 8 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 9 нчы сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать).

6. 8 нче сыйныфта уку-укыту эчтәлеге.

6.1. Халык авыз иҗаты.

6.1.1. Дастаннар. Дастаннарның сәнгати үзенчәлеге. Дастаннарның төрләре. Халык авыз иҗаты ядкәре буларак «Идегәй» дастаны. Әсәрнең реаль җирлеге. Дастанда образлар системасы. Масштаблы вакыйгалар, бөек тарихи шәхесләр язмышы призмасы аша халыкның катлаулы юлын сурәтләү.

6.2. Әдәби әсәрдә сәнгать алымнары.

6.2.1. Әдәби пейзаж. Әдәби әсәрдә пейзажның төрләре һәм функцияләре.

Г. Бәширов, «Җидегән чишмә» (өзекләр). Татар халкының әхлакый асылы, гореф-гадәтләре, милли сыйфатлары. Туган як табигате картиналары.

Ә. Баян, «Яшьлегемне эзлим» (өзекләр). Геройның эчке монологы. Табигать картиналары. Пейзажның мәгънәви ягы.

Н. Арсланов, «Яз». Язгы табигать образы. Шигырьдә пейзаж бирелеше, функцияләре.

6.2.2. Сәнгати алым буларак портрет. Әдәби әсәрдә портрет бирелеше, функцияләре. Портрет төрләре: портрет-сурәтләү, портрет-чагыштыру, портрет-кичереш, психологик портрет.

Н. Фәттах, «Итил суы ака торур» (өзекләр). Тарихи чынбарлык һәм уйдырма. Халыкның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре. Тарихи персонажларның портретын тудыру үзенчәлеге.

Ф. Хөсни, «Йөзек кашы». Кеше язмышының катлаулылыгын сурәтләү. Әсәр геройларының якты лирик хисләре.

Мәхәббәт тарихының фаҗигалы финалы. Әдәби геройлар портретының үзенчәлекләре.

Ш. Җиһангирова, «Татар кызы». Лирикада портрет тудыру үзенчәлеге, сәнгатьле чаралар кулланылышы. Татар кызының матурлыгын данлау.

6.2.3. Әдәби деталь. Әйберләр дөньясы. Әдәби детальнең, әйбер образларының функцияләре.

Ә. Еники тормышы һәм иҗаты. «Әйтелмәгән васыять». Образлар системасы. Повестьның проблематикасы. Татар милләтенең язмышы, җәмгыятьтә әхлак югалу нәтиҗәләре. «Васыять» төшенчәсенең фәлсәфи асылы. Әсәрдә әйбер образлары. Әсәр идеясен ачуда әдәби детальнең роле.

Н. Думави, «Яшь ана». Әдәби деталь, символ. Геройны сурәтләүдә һәм ачып бирүдә әдәби детальнең роле.

Х. Туфан, «Каеннар сары иде». Бала образы. Образны тасвирлауда, мәгънәне ачуда әдәби детальнең функцияләре.

6.2.4. Әдәби символ. Әдәбиятта символларның төрлелеге.

Ф. Яруллинның тормышы һәм иҗаты. «Җилкәннәр җилдә сынала» (өзекләр). Кеше язмышы. Ихтыяр көче һәм көчле характер. Көчле кеше образы. Әсәрдә символларның роле.

Роб. Әхмәтҗанов, «Гомер китабы» Кешенең рухи дөньясы турында уйланулар. Шартлы образлар һәм символлар, ассоциацияләр.

Дәрдмәнд, «Кораб». Милләт, халык язмышын сурәтләү. Кораб, давыл, дулкын һәм упкын образлары. Кешенең галәм, дөнья белән бәйләнеше, табигать белән бердәмлеге. Шигырьдә символик образлылык.

6.2.5. Психологизм. Психологизмның төрләре. Әдәби образларны, әсәрнең идея эчтәлеген ачуда психологизм алымнарының роле.

Ә. Еники, «Кем җырлады?». Яралы лейтенант образы, тормышының соңгы мизгелләре, шул вакыттагы хис-кичерешләре. Татар җыры образы. Хикәядә психологик алымнар.

Г. Ибраһимовның тормышы һәм иҗаты. «Яшь йөрәкләр» (өзекләр). Иске һәм яңа каршылыгы. Әсәрдә образлар системасы. Шәхес иреге идеяләре. Романдагы психологик элементлар.

6.2.6. Әдәби әсәрдә вакыт һәм урын берлеге (хронотоп). Әдәби вакыт төрләре, пространство типлары. Хронотопик образлар.

Г. Исхакый, «Көз». Ике герой, ике язмыш. Повесть атамасының фәлсәфи мәгънәсе. Образларны ачуда кулланылган сәнгать чаралары. Повестьта хронотоп бирелеше.

Г. Кутуй иҗаты. «Тапшырылмаган хатлар». Әдәбиятта эпистоляр жанр. Мәхәббәт һәм гаилә проблемасы, аның повестьта хәл ителеше. Авторның Галия һәм Искәндәр образларына мөнәсәбәте. Яңа кешене романтик сурәтләү. Хронотопик образлар.

М. Галиев, «Кичке сурәт». Бинар оппозицияләрнең әсәрнең идеясен билгеләүдә роле.

6.3. Әдәбият теориясе.

Дастан, пейзаж, портрет, әдәби деталь, әйберләр дөньясы, вакыт һәм урын берлеге (хронотоп), психологизм, символизм, символик образ, эпистоляр стиль, тарихи роман, романтизм, романтик образ.

## ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘР

### Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

Төп гомуми белем бирү баскычында «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметын өйрәнү укучыларда түбәндәге шәхескә кагылышлы нәтиҗәләрне формалаштырачак:

1) ***гражданлык тәрбиясе:***

гражданлык бурычларын үтәүгә һәм хокукларын гамәлгә ашыруга әзер булу, башка кешеләрнең хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен хөрмәт итү, гаилә, белем бирү оешмасы, җирле берләшмә, туган як, туган ил тормышында актив катнашу, шул исәптән әдәби әсәрләрдә чагылдырылган вакыйгалар белән чагыштыру аша да;

экстремизм, дискриминациянең теләсә кайсы формаларын кабул итмәү, кеше тормышында төрле иҗтимагый институтларның ролен аңлау, гражданның төп хокукларын, ирекләрен һәм бурычларын, күп мәдәниятле һәм күп конфессияле җәмгыятьтә шәхесара мөнәсәбәтләрнең иҗтимагый

нормаларын һәм кагыйдәләрен күзаллау, шул исәптән туган (татар) телдәге әдәбияттан алынган мисалларга таяну аша да;

төрле уртак эшчәнлеккә әзер булу, үзара аңлашуга һәм үзара ярдәмләшүгә омтылу, шул исәптән әдәбияттан алынган мисалларга таяну аша да; мәктәп үзидарәсендә актив катнашу, гуманитар эшчәнлектә катнашырга әзер булу;

***2) патриотик тәрбия:***

татар әдәбияты, шулай ук рус әдәбияты әсәрләрен өйрәнү контекстында күп мәдәниятле һәм күп конфессияле җәмгыятьтә Россия гражданлыгы тәңгәллеген аңлау, туган телне (татар телен) һәм туган (татар) телдәге әдәбиятны, Россия Федерациясенең һәм үз төбәгеңнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән кызыксыну;

Ватаныбыз Россиянең казанышларына, фәнгә, сәнгатькә, спортка, технологияләргә, халыкның хәрби батырлыкларына һәм хезмәттәге казанышларына, шул исәптән сәнгать әсәрләрендә чагылдырылганнарына да, зур әһәмият бирү;

Россия символларын, дәүләт бәйрәмнәрен, тарихи, табигый мирасны һәм һәйкәлләрне, илебездә яшәүче төрле халыкларның гореф-гадәтләрен хөрмәт итү, аларның татар әдәбиятында чагылдырылуына игътибар бирү;

***3) рухи-әхлакый тәрбия:***

әдәби әсәрләрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянырга юнәлеш бирү;

үз-үзеңне тоту һәм гамәлләреңне, шулай ук башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышы һәм гамәлләрен аларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, әхлакый һәм хокукый нормалар позициясеннән бәяләргә әзер булу;

җәмгыятьтә кабул ителмәгән гамәлләрне тулысынча кире кагу, шәхси һәм иҗтимагый киңлек шартларында шәхеснең ирек һәм җаваплылык;

***4) эстетик тәрбия:***

үз халкың һәм башка халыклар сәнгатенең барлык төрләрен, традицияләрен һәм иҗатын кабул итү, сәнгатьнең, шул исәптән өйрәнелә торган әдәби әсәрләрнең эмоциональ тәэсирен аңлау;

аралашу һәм үзеңне чагылдыру чарасы буларак матур әдәбият һәм мәдәниятнең мөһимлеген аңлау;

Россия һәм дөнья сәнгатенең кыйммәтен, этник мәдәни традицияләрнең һәм халык иҗатының ролен аңлау;

сәнгатьнең төрле төрләрендә үзеңне чагылдырырга омтылыш;

***5) физик тәрбия, сәламәтлек һәм эмоциональ иминлек культурасын формалаштыру:***

тормыш һәм уку тәҗрибәсенә таянып, тормыш кыйммәтләрен аңлау, үз сәламәтлегенә җаваплы карау һәм сәламәт яшәү рәвеше (сәламәт туклану, гигиена кагыйдәләрен үтәү, дөрес оештырылган эш һәм ял режимы, даими физик активлык) алып бару;

начар гадәтләрнең (спиртлы эчемлекләр, наркотиклар куллану, тәмәке тарту) һәм физик-психик сәламәтлеккә башка зыян салу формаларын аңлау һәм кире кагу, шул исәптән интернет-мохиттә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү:

стресслы ситуацияләргә, үзгәрүчән социаль, информацион һәм табигать шартларына җайлашу, шул исәптән үз тәҗрибәсеннән чыгып һәм алга таба максатлар да куеп, үзеңне һәм башкаларны битәрләми кабул итә белү сәләтенә ия булу;

әдәби әсәрләрдән алынган мисалларга таянып, үзеңнең һәм башкаларның эмоциональ халәтен аңлау, үз эмоциональ халәтең белән идарә итә алу осталыгы, рефлексия күнекмәсе формалашкан булу, әдәби геройларның гамәлләрен бәяләү аша үзеңнең, башкаларның хаталану хокукы булуын тану;

***6) хезмәт тәрбиясе:***

технологик һәм социаль юнәлештәге практик мәсьәләләрне (гаилә, мәктәп, шәһәр, төбәк кысаларында) хәл итүдә актив катнашу максатын кую, мондый эшчәнлекне башлап җибәрү, планлаштыру һәм мөстәкыйль башкара алу сәләтенә ия булу;

өйрәнелгән предмет белемнәрен куллануга һәм әдәби әсәрләрдә геройларның эшчәнлеге белән танышуга да нигезләнеп, һөнәрләрне һәм хезмәт төрләрен гамәли яктан өйрәнү белән кызыксыну;

уңышлы һөнәри эшчәнлек өчен гомер буе белем алуның әһәмиятен аңлау һәм моның өчен кирәкле күнекмәләр булдыру һәм үстерү;

һөнәри мохиткә яраклаша белү; хезмәтне һәм хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәләрен хөрмәт итү, шул исәптән татар фольклоры һәм әдәбияты әсәрләрен өйрәнгәндә дә, шәхси һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрне, ихтыяҗларны исәпкә алып, белем алуның һәм тормыш планнарының индивидуаль траекториясен аңлы рәвештә сайлау һәм төзү;

***7) экологик тәрбия:***

иҗтимагый һәм табигать фәннәреннән алган белемнәрне әйләнә-тирә мохит өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү, гамәлләрне планлаштыру һәм аларның әйләнә-тирә мохит өчен мөмкин булган нәтиҗәләрен бәяләүдә куллануга юнәлдерү;

экологик культура дәрәҗәсен күтәрү, экология мәсьәләләренең глобаль характерын һәм аларны чишү юлларын аңлау;

экологик проблемаларны күтәргән әдәби әсәрләр белән танышканда формалашкан карашларга да нигезләнеп, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерүче гамәлләрне кире кагу;

табигый, технологик һәм иҗтимагый мохитнең үзара бәйләнеше шартларында гражданин һәм кулланучы буларак үз ролен аңлау, экологик юнәлештәге практик эшчәнлектә катнашырга әзер булу;

***8) фәнни танып белү кыйммәтләре:***

үз эшчәнлегендә кеше, табигать һәм җәмгыять үсешенең төп закончалыклары, кешенең табигый һәм иҗтимагый мохит белән үзара бәйләнешләре турындагы фәнни күзаллауларның заманча системасына юнәлгәнлек;

дөньяны танып белү чарасы буларак, тел һәм уку культурасына ия булу;

әдәби белем үзенчәлекләрен исәпкә алып, тикшеренү эшчәнлегенең төп күнекмәләрен үзләштерү, тәҗрибә, күзәтү, эш-гамәлләрне аңлауга юнәлгәнлек һәм шәхси, коллектив иминлеккә ирешү юлларын камилләштерү омтылышына ия булу;

***9) укучының үзгәрүчән социаль һәм табигый мохит шартларына яраклашуын тәэмин итү:***

укучыларның социаль тәҗрибәне, үз яшенең төп эшчәнлегенә туры килә торган иҗтимагый рольләрне, тәртип, нормаларны һәм кагыйдәләрне, төркемнәрдә һәм җәмгыятьтә, шул исәптән гаиләдә, һөнәри эшчәнлек буенча оештырылган төркемнәрдә һәм берләшмәләрдә, шулай ук башка мәдәни мохит кешеләре белән үзара социаль бәйләнеш кысаларында иҗтимагый тормыш формаларын үзләштерүе, әдәби әсәр персонажларының социаль рольләрен өйрәнүе һәм бәяләве;

билгесезлек шартларында үзара бәйләнештә эш итү сәләте, тәҗрибә алырга һәм башкаларның белемнәренә таянырга әзер тору, билгесезлек шартларында эш итә алу сәләтенә ия булу, гамәли эшчәнлек аша үзенең компетентлык дәрәҗәсен күтәрү, шул исәптән башка кешеләрдән өйрәнә алу, уртак эшчәнлектә башкаларның тәҗрибәсеннән яңа белемнәр, күнекмәләр һәм компетенцияләргә төшенү;

образларны ачыклау һәм үзара бәйләү күнекмәсе, яңа белемнәр формалаштыру сәләте, билгеле булган һәм моңа кадәр билгесез объектлар һәм күренешләр турында идеяләр, төшенчәләр, гипотезалар тәгъбирләү, үзендә белем һәм компетенцияләрнең җитенкерәмәвен аңлау, үз үсешен планлаштыру;

тотрыклы үсеш концепциясе өлкәсендә төп төшенчәләр, терминнар һәм күзаллаулар белән эш итә белү;

табигать, җәмгыять һәм икътисадның үзара бәйләнешләрен анализлый һәм ачыклый алу;

әйләнә-тирә мохиткә тәэсирне, максатларга ирешү һәм мөмкин булган каршылыкларны җиңүне, глобаль нәтиҗәләрне исәпкә алып, үз гамәлләрен бәяли алу;

стресслы ситуацияне аңлый, тормыш һәм укучы тәҗрибәсенә таянып, дөньяда бара торган үзгәрешләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бәяли алу, стресслы ситуацияне кире кагарлык чара күрелергә тиешле чакыру буларак кабул итү, стресслы ситуацияне бәяләү, кабул ителгән карарларны һәм гамәлләрне үзгәртү, килеп туган куркынычларны һәм аларның нәтиҗәләрен тәгъбирләү һәм бәяли алу, төрле юлларын эзләү, билгеле бер ситуациянең уңай ягын таба белү, уңышка ышаныч булмаганда да эшләргә әзер тору.

11.2. Төп гомуми белем дәрәҗәсендә туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү нәтиҗәсендә укучыда танып белү универсаль уку гамәлләре, коммуникатив универсаль уку гамәлләре, регулятив универсаль уку гамәлләре, уртак эшчәнлек осталыгы формалаштырылачак.

11.2.1. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге төп логик гамәлләр формалаштырылачак:

объектларның (сәнгати һәм уку текстлары, әдәби геройлар һәм башкалар) һәм күренешләрнең (әдәби юнәлешләр, әдәби-тарихи барыш этаплары) төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү;

классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, аларны гомумиләштерү һәм чагыштыруның нигезен гамәлгә кертү, үткәрелгән анализ критерийларын билгеләү;

тәкъдим ителгән мәсьәләне исәпкә алып, карала торган әдәби фактларда һәм текстны күзәтүләрдә закончалыкларны һәм каршылыкларны ачыклау, аларны ачыклау өчен, критерийлар тәкъдим итү;

куелган уку бурычын чишү өчен, кирәкле җитешмәгән мәгълүматны ачыклау;

әдәби күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, дедуктив һәм индуктив фикерләүне, охшашлык буенча фикерләүне кулланып нәтиҗәләр чыгару, аларның үзара бәйләнешләре турында гипотезалар тәгъбирләү;

текстларның төрле төрләре белән эшләү барышында уку мәсьәләсен чишү ысулын мөстәкыйль сайлау (чишелешнең берничә вариантын чагыштыру, мөстәкыйль билгеләнгән критерийларны исәпкә алып, иң кулаен табу).

11.2.2. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак укучыда түбәндәге төп тикшеренү гамәлләре формалаштырылачак:

әдәби белем алуда сорауларны танып белүнең тикшеренү коралы буларак куллану;

ситуациянең, объектның реаль һәм кирәкле халәте арасындагы аерманы теркәргә ярдәм иткән сорауларны тәгъ-

бирләү һәм нәрсә бирелгән, нәрсәне эзләп табасы икәнлеген мөстәкыйль билгеләү;

үз фикерләреңнең һәм башкалар фикерләренең дөреслеге турында гипотеза формалаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү;

әдәбиятта өйрәнү объектының үзенчәлекләрен, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен һәм объектларның үзара бәйлелеген билгеләүдә мөстәкыйль төзелгән план буенча зур булмаган тикшеренү үткәрү;

тикшеренү (эксперимент) барышында алынган мәгълүматның кулланырлык һәм ышанычлы булуына бәя бирү;

үткәрелгән күзәтү, тәҗрибә, тикшеренү нәтиҗәләре буенча гомумиләштерүләрне һәм нәтиҗәләрне мөстәкыйль рәвештә формалаштыру; алынган нәтиҗәләрнең һәм гомумиләштерүләрнең ышанычлылыгын бәяләү коралларына ия булу;

вакыйгаларның алга таба үсешен һәм аларның бердәй яки охшаш ситуацияләрдә нинди нәтиҗәләргә китерәчәген фаразлау, шулай ук аларның яңа шартларда һәм контекстларда, шул исәптән әдәби әсәрләрдә дә үсеше турында фаразлар тәкъдим итү.

11.2.3. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда мәгълүмат белән эш итүнең түбәндәге күнекмәләре формалаштырылачак:

чыганаклардан тәкъдим ителгән уку бурычын һәм бирелгән критерийларны исәпкә алып, әдәби һәм башка төр мәгълүматны эзләү һәм сайлау барышында төрле инструментлар, ысуллар һәм табу алымнарыннан файдалану;

төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү;

төрле мәгълүмат чыганакларында (бер үк идеяне, версияне раслаучы яки кире кагучы) охшаш аргументлар табу;

әдәби һәм башка төр мәгълүматны тәкъдим итүнең оптималь формасын мөстәкыйль рәвештә сайлау һәм гади схемалар, диаграммалар, башка графика һәм аларның комбинацияләре ярдәмендә чишелергә тиешле уку мәсьәләләрен тасвирлап бирү;

әдәби һәм башка төр мәгълүматның ышанычлылыгын укытучы тәкъдим иткән яки мөстәкыйль рәвештә тәгъбир ителгән критерийлар буенча бәяләү;

мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру.

11.2.4. Коммуникатив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге коммуникатив күнекмәләр формалаштырылачак:

фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү, аралашу шартларына һәм максатларына бәйле рәвештә эмоцияләрне белдерү, үзеңне (үз фикереңне) телдән һәм язма текстларда белдерү;

аралашуның вербаль булмаган чараларын тану, социаль билгеләрнең мәгънәсен аңлау, конфликтлы ситуацияләрнең алшартларын белү һәм тану, әдәби әсәрләрдә охшашлыклар табып, конфликтлы ситуацияләрне көйләү, сөйләшүләр алып бару;

башка кешеләрнең ниятләрен аңлау, әңгәмәдәшкә ихтирамлы мөнәсәбәт күрсәтү һәм үзеңнең килешмәгәнлегеңне әдәп белән тәгъбир итү, уку диалогы һәм (яки) дискуссия барышында фикер алышуда төп тема буенча сораулар бирү;

уку мәсьәләсен хәл итүгә юнәлдерелгән идеяләрне җиткерү, аралашуда үзара җылы мөнәсәбәтләрне саклау; үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау;

үткәрелгән тәҗрибә (әдәби эксперимент, тикшеренү, проект) нәтиҗәләрен башкалар алдында тәкъдим итү;

презентация бурычларын һәм аудитория үзенчәлекләрен исәпкә алып, чыгыш форматын мөстәкыйль сайлау, аңа ярашлы иллюстратив материаллар кулланып, телдән һәм язма текстлар төзү.

11.2.5. Регулятив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге үз-үзеңне оештыру күнекмәләре формалаштырылачак:

матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл итү өчен, проблемаларны ачыклау;

карарлар кабул итүдә төрле алымнарга (индивидуаль, төркемдә карар кабул итү, төркем тарафыннан карарлар кабул итү) юнәлеш тоту;

уку мәсьәләсен (яки аның бер өлешен) чишү алгоритмын мөстәкыйль төзү, булган ресурсларны һәм үз мөмкинлекләрен исәпкә алып, уку мәсьәләсен чишү ысулын сайлау, тәкъдим ителгән чишелеш вариантларын дәлилләү;

эш-гамәлләр планын (билгеләнгән чишү алгоритмын гамәлгә ашыру планын) төзү, һәм өйрәнелә торган әдәби объект турында яңа белемнәр алуны исәпкә алып, тәкъдим ителгән алгоритмны үзгәртү;

сайлау һәм карар чыгаруда җаваплылыкны үз өстеңә алу.

11.2.6. Регулятив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда үз-үзеңне контрольдә тоту, эмоциональ интеллект, үзеңне кабул итү һәм башкаларны тануда түбәндәге күнекмәләр формалаштырылачак:

әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү;

уку ситуациясенә тиешле бәя бирү һәм аны үзгәртү планын тәкъдим итү;

контекстны исәпкә алу һәм уку мәсьәләсен чишү барышында килеп чыгарга мөмкин кыенлыкларны алдан күрү, чишелешне үзгәрүчән шартларга яраклаштыру;

эшчәнлек нәтиҗәләренә ирешү (ирешмәү) сәбәпләрен исәпкә алу, алган тәҗрибәгә бәя бирү, билгеле бер ситуациядә уңай якны таба белү;

яңа шартлар һәм үзгәрешле ситуацияләр, билгеләнгән хаталар, килеп чыккан кыенлыклар нигезендә эшчәнлеккә төзәтмәләр кертү, нәтиҗәнең максат һәм шартларга туры килүен бәяләү;

башкаларның хисләрен һәм үз хисләреңне аеру, атау һәм алар белән идарә итү;

хисләрнең сәбәпләрен ачыклау һәм анализлау;

матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау;

үз хисләрен белдерү ысулын көйләү;

әдәби геройларның үзара мөнәсәбәтләре турында уйланып, башка кешегә, аның фикеренә аңлы рәвештә карау;

хаталанырга хокукыңны һәм башкаларның да шундый ук хокукын тану;

үзеңне һәм башкаларны гаепләмичә кабул итү;

үзеңә һәм башкаларга карата ачык булу;

тирә-юньдәге бар нәрсәне контрольдә тота алмауны аңлау.

11.2.7. Укучыда уртак эшчәнлекнең түбәндәге күнекмәләре формалаштырылачак:

туган (татар) телдәге әдәбият дәресләрендә конкрет мәсьәләләрне хәл итү барышында командалы (парларда, төркемнәрдә, күмәк) һәм индивидуаль эшнең өстенлекләрен аңлау һәм файдалану, куелган бурычны хәл иткәндә, үзара хезмәттәшлекнең төркем формаларын куллану зарурлыгын аңлау;

бергәләп уку эшчәнлегенең максатын аңлау, аңа ирешүдә күмәк рәвештә гамәлләр булдыру: рольләрне бүлү, килешүләр төзү, бергәләп эшләү барышы һәм аның нәтиҗәсе турында фикер алышу;

берничә кешенең фикерен гомумиләштерә белү, җитәкчелек итүгә, йөкләмәләрне үтәүгә, буйсынуга әзерлек күрсәтү;

туган (татар) телдәге әдәбият дәресендә бергәләп эшне оештыруны планлаштыру, үз ролен билгеләү (аралашуда катнашучыларның теләкләрен һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып), команда әгъзалары арасында бурычларны бүлеп бирү, төркем эшендә (сөйләшү, фикер алышу, «аң штурмы» һәм башкалар) катнашу;

эштә үз өлешеңне башкару, үз юнәлешең буенча сыйфатлы нәтиҗәгә ирешү һәм үз гамәлләреңне команданың башка әгъзалары белән координацияләү;

әдәбият дәресләрендә катнашучылар тарафыннан тәгъбир ителгән критерийларга таянып, гомуми нәтиҗәгә керткән өлешеңнең сыйфатын бәяләү;

нәтиҗәләрне башта куелган бурыч белән һәм һәр команда әгъзасының нәтиҗәләргә ирешүгә керткән өлеше белән чагыштыру, җаваплылык өлкәсе белән уртаклашу һәм төркем алдында хисап бирергә әзерлек күрсәтү.

11.3. Туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүнең предмет нәтиҗәләре.

8 нче сыйныфны тәмамлаганда, укучы:

*татар телендә белем бирү мәктәпләрендә түбәндәгеләрне өйрәнә:*

укылган әсәрләрнең тематикасын, проблематикасын һәм идея эчтәлеген билгеләргә һәм формалаштырырга;

әдәби әсәрне анализларга; эчтәлегенең һәм формасының мөһим үзенчәлекләрен анализлау нигезендә әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын күрсәтергә; әсәрләрдә конфликтны (тышкы һәм эчке) табарга;

әдәби детальнең ролен билгеләргә, аның вазифасын ачыкларга;

сюжет һәм композиция төзелеше үзенчәлекләрен күрсәтергә; әдәби әсәрләрдә сюжет үстерелешенең этапларын билгеләргә;

лирик шигырьдән алган тәэсирләре белән уртаклашырга; анда чагылган хисне укучыга җиткерү чараларын әйтергә;

әсәрдә пейзаж һәм интерьер тасвирланышының вазифасын билгеләргә;

әдәби әсәрдә психологизм элементларын атарга;

әсәрнең тел үзенчәлекләрен ачыкларга; текстта әдәби чараларны һәм аларның әсәрдәге ролен билгеләргә;

укыган әсәр буенча әңгәмәдә катнашырга, үз карашын формалаштырырга, аны дәлилләп якларга, башкаларның фикерләрен аңларга;

өйрәнелгән әдәби-теоретик төшенчәләрне (пейзаж, портрет, символ, әдәби деталь, психологизм, хронотоп һ. б.) әдәби текстны анализлаганда кулланырга;

тәкъдим ителгән әдәби тематика буенча (бер әсәргә яки бер язучының берничә әсәренә таянып) инша язарга.

*рус телендә белем бирү мәктәпләрендә түбәндәгеләрне өйрәнә:*

укылган әсәрләрнең тематикасын, проблематикасын һәм идея эчтәлеген билгеләргә һәм формалаштырырга;

әдәби әсәрне анализларга; эчтәлегенең һәм формасының мөһим үзенчәлекләрен анализлау нигезендә әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын күрсәтергә; әсәрләрдә конфликтны (тышкы һәм эчке) табарга;

әдәби детальнең ролен билгеләргә, аның вазифасын ачыкларга;

сюжет һәм композиция төзелеше үзенчәлекләрен күрсәтергә; әдәби әсәрләрдә сюжет үстерелешенең этапларын билгеләргә;

әсәрдә пейзаж һәм интерьер тасвирланышының вазифасын әйтергә;

әдәби әсәрдә психологизм элементларын билгеләргә;

әсәрнең тел үзенчәлекләрен ачыкларга; текстта әдәби чараларны һәм аларның әсәрдәге ролен атарга;

укыган әсәр буенча әңгәмәдә катнашырга, үз карашыңны формалаштырырга, аны дәлилләп якларга, башкаларның фикерләрен аңларга;

өйрәнелгән әдәби-теоретик төшенчәләрне (пейзаж, портрет, символ, әдәби деталь, психологизм, хронотоп һ. б.) әдәби текстны анализлаганда кулланырга;

тәкъдим ителгән әдәби тематика буенча (бер әсәргә яки бер язучының берничә әсәренә таянып) инша язарга.

# ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

## 8 класс — 34 сәгать, (татар телендә белем бирү мәктәпләренә)

| № | Тема | Эчтәлек | Сәгатьләр саны | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | **Халык авыз иҗаты** | | |
| 1 | Халык авыз иҗаты. Дастаннар (4 сәгать) | Халык авыз иҗаты буларак дастаннар. «Идегәй» — тарихи дастан. | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Фольклор әсәренең тексты белән эшләү: укыган текстның эчтәлегенә кагылышлы сорауларга җавап бирү, әсәрнең сюжет һәм композиция үзенчәлекләрен бәяләү.<br>Уку әңгәмәсе: укылган әсәр эчтәлегенә нигезләнеп, әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне формалаштыру һәм аны нигезли һәм яклый алу, дастан жанрына хас үзенчәлекләрне билгеләү.<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Проект эше: проект эшен башкару өчен, кирәкле материалны җыю һәм системага салу, фикер алышу, чыгыш ясау |
| | | Идел йортның улы Идегәй кем ул? («Идегәй» дастанында образлар системасы) | 1 | |
| | | Әдәм гарибә шул булыр — Кайтып илен тапмаса! («Идегәй» дастанының идеясе һәм аның сәнгатьчә гәүдәләнеше) | 1 | |
| | | Проект эше. «И, Идел йорт, Идел йорт» | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| **Әдәби әсәрдә сәнгати алымнар** | | | | |
| 2 | Әдәби әсәрдә сәнгати алым. Пейзаж (5 сәгать) | Таш кайчан телгә килә? (Әдәби алым буларак пейзажның әсәрдәге роле) | 1 | Уку: текстны аңлап, сәнгатьле уку.<br>Уку әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әсәрнең темасын һәм проблемасын билгеләү, әсәрнең идеясен формалаштыру.<br>Текстны сөйләү: иҗади сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү |
| | | Җидегән чишмә нәрсә турында җырлый? (Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» романының идеясен ачуда пейзажның роле) | 1 | |
| | | Табигать-ананың сулышын тоеп (Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» романында пейзаж сурәтләнеше ярдәмендә татар халкының рухи байлыгын ачу) | 1 | |
| | | Нинди ул Агыйдел кызы? (Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим» повестенда яшьлек, мәхәббәт һәм пейзаж параллельлеге) | 1 | |
| | | Күңелеңә сандугач керсә... (Лирик әсәрләрдә пейзажның үзенчәлеге: Н. Арслановның «Яз» шигыре) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | Әдәби әсәрдә сәнгати алымнар. Портрет (6 сәгать) | Сәнгати алым буларак әдәби әсәрдә портрет бирелеше | 1 | Уку: текстны сәнгатьле уку.<br>Уку әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү, укылган әсәр турында сөйләшүдә катнашу.<br>Әдәби әсәр тексты белән эш: әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын күрсәтү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әсәр героена бәя: автор сурәтләвенә нигезләнеп, телдән, геройның портретын тасвирлау.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү |
| | | Гасырлар аша күз салып (Тарихи әсәрләрдә портрет бирү үзенчәлеге (Н. Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәре мисалында) | 1 | |
| | | Бердәмлекне җиңәрлек көч юк (Н. Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәренең идея-проблематикасы) | 1 | |
| | | Хисләр һәм акыл каршылыгы (Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендә психологик портрет тудыру үзенчәлеге) | 1 | |
| | | Рухи халәтнең тышкы чагылышы нинди? (Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендә чагыштырма портрет) | 1 | |
| | | Үзе уңган, үзе тыйнак — татар кызы<br>(Ш. Җиһангированың «Татар кызы» шигырендә милли портрет бирелеше) | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Әдәби әсәрдә сәнгати алымнар. Әдәби деталь (әйберләр дөньясы) (5 сәгать) | Кулъяулыгым — вәгъдә билгесе (Сәнгати алым буларак әдәби деталь, әйберләр дөньясы) | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Уку әңгәмәсе: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, укылган әсәр турында сөйләшүдә катнашу. Әдәби әсәр тексты белән эш: әсәрнең темасын, идеясен һәм проблемасын билгеләү, әсәр геройларына карата үз мөнәсәбәтеңне анализлау һәм белдерү. Текстны сөйләп бирү: кыскача сөйләү. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү. Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү |
| | | Йөрәк түрендәге хисләр (Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә әдәби детальнең психологик төрләре) | 1 | |
| | | Хәситәме, камчымы?.. (Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә әйберләр дөньясының әсәр идеясен ачудагы роле) | 1 | |
| | | Үткәннәрне чүплеккә салып булмый (Н. Думавиның «Яшь ана» әсәрендә геройларның күңел халәтен ачуда әдәби детальнең әһәмияте) | 1 | |
| | | Сары — сагыш билгесе (Лирик әсәрләрдә әдәби деталь: Х. Туфанның «Каеннар сары иде» шигыре) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | Символизм. Әдәби әсәрдә символларның төрләре (4 сәгать) | Символизм. Әдәби әсәрдә символларның төрләре | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әсәр текстын белү һәм аңлауны ачыклый торган сорауларга җаваплар бирү, текстка таянып, үз фикерләрен нигезләү.<br>Әсәр героена бәя: автор сурәтләвенә нигезләнеп, телдән, геройны тасвирлау.<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү |
| | | Язмыш сынавын һәркем үзенчә кичерә (Ф. Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда кеше язмышы, рухи батырлык мәсьәләсе) | 1 | |
| | | Җилкәнеңне җилләр екса (Ф. Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда герой характерын ачарга ярдәм иткән символлар) | 1 | |
| | | Шигъриятнең серле дөньясы (Шигърияттә символизм: Дәрдмәнднең «Кораб», Роб. Әхмәтҗановның «Гомер китабы» шигырьләре) | 1 | |
| 6 | Психологизм. Әдәби әсәрләрдә психологизм алымнары (4 сәгать) | Психологизм. Әдәби әсәрдә психологизмның төрләре | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын күрсәтү. |
| | | Тән ярасын оныттырырлык моң (Ә. Еникинең «Кем җырлады?» әсәрендә психологизм аша геройның рухи халәтен ачу) | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Күңел кошың күкрәгеңә сыймаса... (Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» әсәрендә геройлар омтылган шәхес иреге) | 1 | Үз карашын формалаштыру һәм дәлилләү.<br>Текстны сөйләү: җентекләп сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: психологизм үзенчәлекләрен ачыклау.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү.<br>Иҗади эш: сочинение язу |
| | | Хыял һәм хакыйкатьнең арасы еракмы? (Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы) | 1 | |
| 7 | Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт (хронотоп). Хронотопик образлар (5 сәгать) | Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт (Г. Исхакыйның «Көз» повестенда урын һәм вакыт бердәмлеге) | 1 | Уку: текстны мәгънәләрен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: исемнең эчтәлек белән бәйләнешен табу, укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.<br>Әсәр героена бәя.<br>Рәсемнәр һәм иллюстрацияләр буенча сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: *хронотоп* төшенчәсен ачыклау |
| | | Гомер көзенең җимешләре татлы булсын дисәң... (Г. Исхакыйның «Көз» әсәрендә геройлар язмышына мөнәсәбәтле хронотопик образлар) | 1 | |
| | | Җырга тиң мәхәббәт (Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестенда хронотоп бирелеше) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Гаилә — тигез хокуклы кешеләр союзы ул (Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар повестенда геройлар язмышын ачарга ярдәм итүче хронотопик образлар) | 1 | |
| | | Лирик әсәрләрдә хронотоп бирелеше (М. Галиевнең «Кичке сурәт» шигыре) | 1 | |
| 8 | Нәтиҗәләр чыгару (1 сәгать) | Үткән материалны кабатлау. Контроль эш. Нәтиҗәләр чыгару. | 1 | Комплекслы кабатлау. Гомумиләштерү, сорауларга җавап бирү. Контроль тест биремнәрен үтәү |

## 8 класс — 34 сәгать (рус телендә белем бирү мәктәпләренә)

| № | Тема | Эчтәлек | Сәгатьләр саны | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | **Халык авыз иҗаты** | | |
| 1 | Халык авыз иҗаты. Дастаннар (4 сәгать) | Халык авыз иҗаты буларак дастаннар. «Идегәй» — тарихи дастан | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Фольклор әсәренең тексты белән эшләү: укыган текстның эчтәлегенә кагылышлы сорауларга җавап бирү, әсәрнең сюжет композиция үзенчәлекләрен бәяләү.<br>Уку әңгәмәсе: укыган әсәр эчтәлегенә нигезләнеп әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне формалаштыру һәм аны нигезли һәм яклый алу, дастан жанрына хас үзенчәлекләрне билгеләү.<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Проект эше: проект эшен башкару өчен кирәкле материалны җыю һәм системага салу, фикер алышу, чыгыш ясау. |
| | | Идел йортның улы Идегәй кем ул? («Идегәй» дастанында образлар системасы) | 1 | |
| | | Әдәм гарибә шул булыр — Кайтып илен тапмаса! («Идегәй» дастанының идеясе һәм аның сәнгатьчә гәүдәләнеше) | 1 | |
| | | Проект эше. «И, Идел йорт, Идел йорт» | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Әдәби әсәрдә сәнгати алымнар** | | | | |
| 2 | Әдәби әсәрдә сәнгати алым. Пейзаж (5 сәгать) | Таш кайчан телгә килә? (Әдәби алым буларак пейзажның әсәрдәге роле) | 1 | Уку: текстны аңлап, сәнгатьле уку.<br>Уку әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әсәрнең темасын һәм проблемасын билгеләү, әсәрнең идеясен формалаштыру.<br>Текстны сөйләү: иҗади сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү |
| | | Җидегән чишмә нәрсә турында җырлый? (Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» романының идеясен ачуда пейзажның роле) | 1 | |
| | | Табигатьнең үз кануннары бар (Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» романында табигать образлары) | 1 | |
| | | Табигать-ананың сулышын тоеп (Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» романында пейзаж сурәтләнеше ярдәмендә татар халкының рухи байлыгын ачу) | 1 | |
| | | Күңелеңә сандугач керсә... (Лирик әсәрләрдә пейзажның үзенчәлеге: Н. Арслановның «Яз» шигыре) | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 3 | Әдәби әсәрдә сәнгати алымнар. Портрет (6 сәгать) | Сәнгати алым буларак әдәби әсәрдә портрет бирелеше | 1 | Уку: текстны сәнгатьле уку.<br>Уку әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү, укылган әсәр турында сөйләшүдә катнашу.<br>Әдәби әсәр тексты белән эш: әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын күрсәтү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әсәр героена бәя: автор сурәтләвенә нигезләнеп, телдән геройның портретын тасвирлау.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү |
| | | Гасырлар аша күз салып (Тарихи әсәрләрдә портрет бирү үзенчәлеге: Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» әсәре мисалында | 1 | |
| | | Бердәмлекне җиңәрлек көч юк (Н. Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәренең идея-проблематикасы) | 1 | |
| | | Хисләр һәм акыл каршылыгы (Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендә психологик портрет тудыру үзенчәлеге) | 1 | |
| | | Рухи халәтнең тышкы чагылышы нинди? (Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендә чагыштырма портрет) | 1 | |
| | | Үзе уңган, үзе тыйнак — татар кызы (Ш. Җиһангированың «Татар кызы» шигырендә милли портрет бирелеше) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Әдәби әсәрдә сәнгати алымнар. Әдәби деталь (әйберләр дөньясы) (5 сәгать) | Кульяулыгым — вәгъдә билгесе (Сәнгати алым буларак әдәби деталь, әйберләр дөньясы) | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Уку әңгәмәсе: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, укылган әсәр турында сөйләшүдә катнашу. Әдәби әсәр тексты белән эш: әсәрнең темасын, идеясен һәм проблемасын билгеләү, әсәр геройларына карата үз мөнәсәбәтеңне анализлау һәм белдерү. Текстны сөйләп бирү: кыскача сөйләү. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү. Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү |
| | | Йөрәк түрендәге хисләр (Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә әдәби детальнең психологик төрләре) | 1 | |
| | | Хәситәме, камчымы?.. (Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә әйберләр дөньясының әсәр идеясен ачудагы роле) | 1 | |
| | | Сары — сагыш билгесе (Лирик әсәрләрдә әдәби деталь: Х. Туфанның «Каеннар сары иде» шигыре) | 1 | |
| | | Үткәннәрне кабатлау. Тикшерү эше | 1 | |
| 5 | Символизм. Әдәби әсәрдә символларның төрләре (4 сәгать) | Символизм. Әдәби әсәрдә символларның төрләре | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Әдәби әсәрнең тексты белән эшләү: әсәр текстын белү һәм аңлауны ачыклый торган сорауларга җаваплар бирү, текстка таянып, үз фикерләрен нигезләү. Әсәр героена бәя: автор сурәтләвенә нигезләнеп, телдән геройны тасвирлау. |
| | | Язмыш сынавын һәркем үзенчә кичерә (Ф. Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда кеше язмышы, рухи батырлык мәсьәләсе) | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Җилкәнеңне җилләр екса (Ф. Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда герой характерын ачарга ярдәм иткән символлар) | 1 | Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Шигъриятнең серле дөньясы (Шигърияттә символизм: Дәрдмәнднең «Кораб» шигыре) | 1 | |
| 6 | Психологизм. Әдәби әсәрләрдә психологизм алымнары (4 сәгать) | Психологизм. Әдәби әсәрдә психологизмның төрләре | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү.<br>Үз карашын формалаштыру һәм дәлилләү.<br>Текстны сөйләү: җентекләп сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: психологизм үзенчәлекләрен ачыклау.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү.<br>Иҗади эш: сочинение язу |
| | | Тән ярасын оныттырырлык моң (Ә. Еникинең «Кем җырлады?» әсәрендә психологизм аша геройның рухи халәтен ачу) | 1 | |
| | | Күңел кошың күкрәгеңә сыймаса... (Г. Ибраһимоның «Яшь йөрәкләр» әсәрендә геройлар омтылган шәхес ирегe) | 1 | |
| | | Хыял һәм хакыйкатьнең арасы еракмы? (Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романының идеясе) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7 | Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт (хронотоп). Хронотопик образлар (5 сәгать) | Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт (Г. Исхакыйның «Көз» повестенда урын һәм вакыт бердәмлеге) | 1 | Уку: текстны мәгънәләрен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: исемнең эчтәлек белән бәйләнешен табу, укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.<br>Әсәр героена бәя.<br>Рәсемнәр һәм иллюстрацияләр буенча сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: *хронотоп* төшенчәсен ачыклау |
| | | Гомер көзенең җимешләре татлы булсын дисәң... (Г. Исхакыйның «Көз» әсәрендә геройлар язмышына мөнәсәбәтле хронотопик образлар) | 1 | |
| | | Җырга тиң мәхәббәт (Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестенда хронотоп бирелеше) | 1 | |
| | | Гаилә — тигез хокуклы кешеләр союзы ул (Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар повестенда геройлар язмышын ачарга ярдәм итүче хронотопик образлар) | 1 | |
| | | Лирик әсәрләрдә хронотоп бирелеше (М. Галиевнең «Кичке сурәт» шигыре) | 1 | |
| 8 | Нәтиҗәләр чыгару (1 сәгать) | Үткән материалны кабатлау.<br>Контроль эш. Нәтиҗәләр чыгару | 1 | Комплекслы кабатлау.<br>Гомумиләштерү, сорауларга җаваплар бирү.<br>Контроль тест биремнәрен үтәү. |

## ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

8 нче сыйныф дәреслеге үзенең эчтәлеге белән алдагы еллар дәреслекләреннән аерылып тора. Ул башка елларда кабул ителгәнчә халык авыз иҗаты әсәре — «Идегәй» дастаны белән башланып китсә дә, калган темалар бер үзәккә тупланган. Бу уку елында укучылар әдәби әсәр тудыруда төрле сәнгати алымнарның әһәмиятен өйрәнәчәкләр. Шул максаттан чыгып, дәреслектә алты тема урын алган һәм ул темалар гадидән катлаулыга юнәлтелгән. Иң элек, укучылар әдәби әсәрдә сәнгати алым буларак пейзаж, портрет, әйберләр дөньясы белән танышсалар, соңрак, психологизм, символлар һәм хронотоп кебек катлаулырак алымнарны үзләштерергә тиеш булалар.

8 нче сыйныфта укучыларның әдәби белемнәре ягыннан әзерлек дәрәҗәләре шактый зур икәнен исәпкә алып, әдәби әсәрне автор тарафыннан тудырылган сәнгать әсәре буларак кабул итүләренә һәм, әсәр иҗат иткәндә, тормыш моделен кабат тергезү өчен, язучының, үз максатына туры китереп, нинди сәнгати алымнар куллануын аңлауларына ирешү бурычы куела.

Укучыларның алган белемнәренә таянып, әдәби әсәрнең образлы фикерләү нәтиҗәсе булуын, әсәрдәге һәр нәрсәнең (вакыйгаларның урыны, вакыты, геройларның эчке кичерешләре, тышкы кыяфәте, андагы аерым детальләр, табигатьнең тасвирланышы) язучының укучыга җиткерәсе фикерен һәм әсәр идеясен ачып бирергә хезмәт итәргә тиеш була.

Шулай ук дәресләрдә мөһим бер шарт: укытучы бу дәрестә үтелә торган материал белән генә түгел, үткән һәм алда үтеләчәк материалны да күздә тотарга тиеш. Әйтик, әсәрдә пейзаж бирелеше, аның вазифасы турында сөйләшкәндә, вакыйгаларның урыны, вакыты, геройларның портреты, эчке кичерешләренә дә игътибар бирелсә, укучы әсәрдәге сәнгати алымнарны аерым-аерым итеп түгел, әсәрне барлыкка китерүче бербөтен буларак күз алдына китерергә өйрәнәчәк.

Дәреслектә укылырга тиешле әсәр күләме, сораулар һәм биремнәр ике төрле тәкъдим ителә. Бу — укучыларның телне

белү дәрәҗәләрен күздә тотып эшләнде. Әсәрнең кыскартылган өлешен генә уку да дәреснең максатына ирешүдә авырлык тудырмаячак.

Дәреслектә сүзлек башка сыйныфларныкыннан аерылып тора. Укучы аңламаска мөмкин булган сүзнең гадирәк синонимы җәя эчендә курсив белән күрсәтелде, рус теленә тәрҗемәсе бирелмәде. Бу — укыла торган әсәрнең күләме арту белән дә бәйле. Дәреслектәге милли-мәдәни һәм тарихи характердагы комментарийлар әдәби әсәрләрне уку барышында тәкъдим ителеп бара. Анда әдәби текстта очрый торган, теге яки бу сәбәпләр аркасында укучыларга таныш булмаган аерым сүзләр, милли-мәдәни компонентлы төшенчәләр урын ала. Сүз беренче чиратта архаизмнар, тарихи сүзләр, татар халкының һәм гомумән Россиянең ерак үткәнендә булган төшенчәләр һәм күренешләр турында бара. Комментарийлар укучыларны төрле сәнгать төрләре әсәрләре белән таныштыру максатыннан да тәкъдим ителә. Милли-мәдәни компонент дәреслектәге иллюстрацияләрдә сурәтләнгән киемдә, бизәнү әйберләрендә, көнкүрештә, йортларның бизәлешендә, интерьерда чагылыш таба. Ул шулай ук игътибар үзәгенә алынырга тиешле өлкә булып санала.

Сүзләр белән эшләү, сүз байлыгын арттыру максатыннан әдәби текстларда очраган фразеологизмнарга, канатлы сүзләргә, образлы гыйбарәләргә аңлатма махсус рубрикада бирелә. Дәреслектә урын алган рубрикалар белән танышу укучыларның дөньяга карашларын, белемнәрен киңәйтә.

Өстәмә мәгълүмат буларак китерелгән материалны ничек, дәреснең кайсы өлешендә файдалану укытучы ихтыярында. Бу бигрәк тә «Шәхесләребез», «Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан» рубрикаларына, «Бу кызыклы», «Файдалы фикер» тамгасы астында күрсәтелгән мәгълүматларга карый.

Зур теманы үзләштерү алдыннан бирелгән сорау өйрәнеләчәк өлкәгә кызыксыну уятуны, укучыны җиңелрәк итеп аңа якынайтуны күздә тота. Теманы өйрәнеп бетергәннән соң куелган сорау укучы үзләштерергә тиешле иң мөһим нәрсәгә игътибарны юнәлтә. «Нәтиҗә ясыйбыз» рубрикасы әлеге мөһим нәрсәне кабат каскача гына хәтергә салып куярга ярдәм итә.

Дәреслектәге уку материалы өлешчә видеодәресләр форматында да тәкъдим ителә. 8 нче сыйныф өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында урнаштырылган видеороликларның эчтәлеге федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә, һәм алар федераль белем бирү программалары нигезендә эшләнгән. Видеодәресләрнең төп максаты — укучыларны яңа материал белән таныштыру, аны презентация яки анимация чаралары ярдәмендә аңлату. Бу видеоязмалардан дәресләрдә дә, дистанцион укытуда укучының уку материалын мөстәкыйль үзләштерүе барышында да файдаланырга мөмкин. Шулай ук укучылар белән дәрестән тыш эшләгәндә дә аларны уңышлы кулланып була.

Әлеге видеодәресләр һәм шулай ук туган (татар) телдәге әдәбиятны уку-укыту барышында кулланыла торган норматив документлар, федераль эш программалары, дәреслекләрнең электрон вариантлары, методик әсбаплар, медиаматериаллар, татар балалар әдәбияты антологиясе белән «Мәгърифәт» медиаплатформасында (https://magrifat.antat.ru) танышып була.

Методик ярдәмлектә татар һәм рус телендә белем бирә торган мәктәпләр өчен уртак темалар эчендә зәңгәр төс белән бирелгән өлешләр бары татар телендә белем алучы укучылар белән эшләүче укытучыларга гына карый. Мондый урыннар күп түгел. Дәрестә һәр укучы мөмкинлегеннән һәм әсәрнең күпме өлеше белән таныш булуыннан чыгып эшли. Мәсәлән, геройга бәяләмә биргәндә, тел байлыгы җитмәгән укучыга аның 2—3 сыйфатын атару җитә. Ә әзерлекле укучы аның эш-гамәлләренә бәя биреп, тулы картинаны ача ала. Һәр укытучы укучыларның мөмкинлеген, аларның нәрсәгә сәләтле икәнен үзе белә һәм шул мөмкинлектән, алар үзләштерергә тиешле күләмнән чыгып таләп куя.

Әдәби әсәрне өйрәнгәндә, сәнгати алымнарның вазифасын ачыклауга өстенлек бирелсә дә, аның тәрбияви, әхлакый кыйммәтен, чор, халкыбыз, туган җиребез тарихы белән бәйләнешен, рус һәм башка халыклар әдәбияты үсеше белән булган бәйләнешләргә дә игътибар кимергә тиеш түгел.

## ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕНЕҢ ҮРНӘКЛӘРЕ

Методик ярдәмлектә китерелгән дәрес үрнәкләре укытучыга бары юнәлеш бирү һәм бу дәрестә игътибардан читтә калмаска тиешле төп моментларны искәртүне генә максат итә, ләкин дәрестә әлеге үрнәкләрдәгечә генә эш итеп булмый, чөнки сыйныфтагы укучыларның гомум һәм шәхси мөмкинлекләре исәпкә алынырга тиеш. Әсәрне уку, сүзлек белән эшләү, сорауларга җавап бирү, әңгәмәнең ни рәвешле үткәрелүе укытучы ихтыярында. Өстәмә сорау-биремнәр төзегәндә, әңгәмәне үзе сайлаган темага оештырганда, укытучы үзенең тәҗрибәсенә таяна. Шуңа күрә дәрес үрнәкләрендә бу өлешкә киң тукталмадык.

**Тема**: Халык авыз иҗаты. Дастан.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — гражданлык бурычларын үтәүгә һәм хокукларын гамәлгә ашыруга әзер булу, башка кешеләрнең хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен хөрмәт итү; татар халкының тарихына, аның рухи мирасына сак караш һәм хөрмәт тәрбияләү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, чишү юлларын билгеләү, үзеңә һәм башкаларга карата ачык булу; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; үз фикерләрен әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — халык авыз иҗаты жанры буларак дастан һәм аның төрләре, тарихи дастаннар төшенчәләрен үзләштерү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 5—17.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

1. Исәнләшү.

2. Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Уку елын башлап җибәрүче дәрес булганлыктан, укучылар дәреслек белән таныштырыла. Дәреслек авторларының укучыга мөрәҗәгатенә игътибар итү бу уку елында әдәбият дәресләренең эчтәлеген аңларга ярдәм итәр. Узган уку елында нәрсәләр өйрәнүләрен искә төшереп, быел бу белемнәрнең тагын да тирәнәйтелеп, яңа белемнәр өстәлүе турында әйтелә.

Татар әдәбиятының гаять бай булуы, ерак тарихны һәм бүгенге тормышыбызны чагылдырган әсәрләрдә дә халыкның акылы, тәҗрибәсе тупланганлыгын телгә алып, халык авыз иҗаты язма әдәбиятыбызның чишмә башы, һәрьяклап аның нигезе икәнлеге искә төшерелә. Укучыларның узган сыйныфларда халык авыз иҗатыннан кайсы әсәрләрне өйрәнүләре белән кызыксынып, әңгәмә оештырыла.

Электрон тактада халык авыз иҗаты жанрларын күрсәткән схема булдырып, укучылардан халык авыз иҗатының кайсы жанры аларга әле таныш түгеллеген ачыкларга мөмкин. Дастан жанры белән таныш булмауларын әйтәчәкләр.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта сөйләгәннәргә нигезләнеп, бу дәрестә халык авыз иҗатының тагын бер жанры — дастаннар турында сөйләшәчәкләре ачыклана. Дәреснең төп максаты белән таныштырыла.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дастан халык авыз иҗатының башка жанрлары әкият, бәет, легенда, риваятьләр белән янәшә куелып карала, охшаш һәм аермалы яклары күрсәтелә. Дастан төшенчәсенә аңлатма биргәндә, һәр өлеш тәфсилләп аңлатыла:

Героик эчтәлек — батырлыкка дан җырлау, аерым кеше яки кешеләрнең үз идеалларын яклап көрәшү тарихын сөйләү. Романтик рух — бөек омтылышлар, аларның җиңеп чы-

гуын сурәтләү, геройларның автор идеалы җирлегендә, чынбарлыктан аерып, югары күтәрелүе, сыйфатларның арттырылу, сурәтлелекнең камиллегенә омтылу. Эпик әсәр — вакыйгаларны, геройлар язмышын, эш-гамәлләрен хикәяләп сөйләп бирә.

*Дастанның нинди төрләре бар? Алар бер-берсеннән нинди билгеләре белән аерыла?* Һәр төргә мисал китергәч, кыскача гына төп герой тасвирлана. Әйтик, Алыплар турында дастан герое алып Ак Күбәкнең (Көбәк язылышы да очрый) кешелексез Кидән (Кодән) хан, аның улы Маңгыш һәм аның сугышчыларына каршы көрәше һәм җиңүгә ирешүе турында. Мәхәббәт дастанына мисал итеп, «Бүз егет» эчтәлеген тәкъдим итәргә мөмкин. Дастанда Бүз егетнең шаһ (патша) кызы Карачәчсылуга карата булган фаҗигалы мәхәббәте турында сөйләнә. Геройлар бер-берсен төштә күреп гашыйк булалар. Күп кенә каршылыкларны җиңеп, дүрт ел буе бер-берсен эзләгәннән соң, төп герой Бүз егет сөеклесен таба. Ләкин кызның атасы аны башка хан улына кияүгә биререргә тели һәм Бүз егетне үтерттерә. Сөйгәненең үлемен кичерә алмыйча, Карачәчсылу да үз-үзен үтерә.

Тарихи дастан үзенчәлекләре турында «Идегәй» дастанын өйрәнү барышында сөйләшәчәкләре әйтелә.

Дәреслекне файдаланып, түбәндәге таблицаны тутыралар:

| Дастан — .... (*аерым халыкның тарихына, мифологик ышануларына нигезләнгән героик эчтәлекле, романтик рухлы, эпик әсәр.)* | | |
|---|---|---|
| Алыплар турында дастаннар | Мәхәббәт дастаннары | Тарихи дастаннар |
| *Үз ыруын, халкын явыз көчләрдән, төрле дошманнан саклаучы алыплар турында сөйләнә. Мисаллары: «Мешәк Алып», «Кара Күңел», «Ак Күбәк»* | *Геройлары мәхәббәт һәм бәхет өчен көрәшүче гашыйк затлар. Мәсәлән: «Таһир-Зөһрә», «Бүз егет», «Йосыф китабы» һ. б.* | *Билгеле бер чор, тарихи вакыйгалар реаль географик җирлектә сурәтләнә. Аның төп геройлары да — тарихи шәхесләр. Мәсәлән: «Җик Мәргән», «Чура Батыр», «Идегәй» һ. б.* |

Татар телендә белем бирүче мәктәп укучыларына дәреслектәге өстәмә мәгълүмат та бирелә.

«Идегәй» дастаны белән таныштыруны дәреслектәге *Явызлык кылу яхшы нәтиҗәләргә китерә аламы?* дигән сорауга игътибарны юнәлтеп, укучыларның бу сорауга җавапларын тыңлаудан башлыйбыз. «Идегәй» дастанында әлеге сорауга җавап бар. Дастан белән танышкач, җавап та тулырак ачылыр дигән фикер белән «Идегәй» әсәре белән танышу башлана. Сыйныфта дастанның бер өлеше укыла. (*Дәреслекнең 8 нче бите, «Аны миңа тапшыргыл» дигән җөмлә белән туктыйбыз.*) Татар телен авыр аңлый торган укучылар белән әсәрне кычкырып уку, бергәләп, аңлашылмаган урыннарны аңлатып уку аеруча мөһим.

Укыган өзектән укучыларның нәрсә аңлаулары белән кызыксынып, җаваплар алгач, дәреслектәге картага игътибар биреп, әсәрнең иҗат ителү вакытын, кайсы тарихи чорны сурәтләвен, халык тормышындагы ролен ачыклап китәбез. Әсәр борынгы болгар бабаларыбызның Чыңгыз хан нәселе хакимлек иткән Алтын Урда составында яшәгән чорында иҗат ителгән дип исәпләнә. (*Бу урында дәреслектәге картага да игътибар итү һәм Алтын Урда дәүләте турында кыскача гына мәгълүмат бирү дә кирәк. Ул әлеге дәүләтнең зур тарихын аңларга ярдәм итәр.)* Дастанның авторы билгеле түгел. Ул Сарай шәһәрендә яшәгән болгар шагыйре тарафыннан иҗат ителгән һәм, киң таралыш алып, төрле вариантлары туган, камилләшкән дип уйларга була. Дастанда монголлар төзегән Алтын Урда дәүләтендәге хакимлек өчен көрәш, дәүләтнең җимерелүенә китергән сәбәпләр сурәтләнә. Ул Алтын Урда дәүләтенең җимерелү чорын тасвирлый. Дастан кешелекне һәрвакыт борчып торган сорауларга җавап эзли:

1. *Нәрсә яхшы, нәрсә яман? Яманлыкның сәбәбе нәрсәдә?* (Бу юнәлеш А.Г. Яхин дәреслегендә[1] дә карала.)

2. Дастан халык күңелендәге азатлык идеалын гәүдәлән-

---

[1] Яхин А. Г. Әдәбият: Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләренең 9 нчы сыйныфы өчен дәреслек. — Казан : Мәгариф, 2007. — 407 б.

дерә. Идегәй — үз халкының азатлыгы өчен көрәшүче герой. Бу юнәлеш дастанга бәя бирүчеләрнең күбесенә хас.

Дастанның төп кыйммәте — халык рухына туры килүендә, аның идеалларын гәүдәләндерүендә, кешелекнең һәр чорына хас булган проблемаларны (гаделлек, ирек) күтәрүендә. Шуңа ул үлемсез дастан булып яши.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу дәрестә укучы үзләштереп калырга тиешле төп сорауларга җаваплар табу.

*Халык авыз иҗатының нинди жанры белән таныштык? Нәрсә ул дастан? Тематик яктан дастаннар ничә төрле була, ниндиләр? «Идегәй» дастаны турында нәрсәләр белдең? Ни өчен «Идегәй» дастаны тарихи дастан дип карала?*

**VI. Өй эше бирү.**

Дәреслекнең 13 битендәге 1, 2 сорауларга җавап бирергә.

*Туктамыш хан Аксак Тимергә Төкле Аякны (лачынны) бирерме?* соравына җавап әзерләп килергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Идел йортның улы Идегәй кем ул? («Идегәй» дастанында образлар системасы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — дастан геройларының гамәлләрен бәяләү аша әхлак сыйфатларын тәрбияләү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; куелган уку бурычын чишү өчен, кирәкле җитешмәгән мәгълүматны ачыклау, объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, нәтиҗә чыгару; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — тарихи дастан «Идегәй»нең эчтәлеген белү, образлар системасын анализлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары

өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 5—17.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

1. Исәнләшү.
2. Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өйгә бирелгән эшләрне тикшерү, укучыларның җавапларын тыңлау. *Туктамыш хан Аксак Тимергә Төкле Аякны (лачынны) бирерме?* дигән сорауга җаваплар төрле (төрле булмаска да мөмкин).

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

*Дастанда вакыйга ничек дәвам итә икән? Дастан исеменә үк чыгарылган Идегәй язмышына бу вакыйга ничек бәйләнгән? Кем ул Идегәй?* дигән сораулар куелып, бу дәрестә Идегәй турында сөйләшәчәкләре ачыклана. Дәреснең төп максаты белән таныштырыла.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дастанның эчтәлеге белән танышуны дәвам итеп, дәреслектәге өлеше тулысы белән сыйныфта укыла. Дастан тексты аңлау өчен катлаулы, аңлатмалар сорый, шул сәбәпле сыйныфта бергәләп уку үзен аклый. Уку барышында вакыйгаларны һәм геройларның үзара мөнәсәбәтләрен, бу мөнәсәбәтләрнең сәбәпләрен аңлатып бару кирәк. Дастан теле укучы өчен катлаулы, вакыйгалар һәм аның геройларының кичерешләре шулай ук укучыга аңлатып бирүне таләп итә. Дастанны дәреслектә шактый кыскартып бирүнең дә сәбәбе шул. Әсәрне укып чыккач, геройлар барлап чыгыла. Укучылар вакыйгаларны һәм геройларны кабат әйтеп уза. Бу вакыйгаларга мөнәсәбәтле Идегәй язмышы линиясе аерым игътибарга алып барылырга тиеш.

Идегәй — Тутамыш хан башын чаптырган Котлыкыя би улы, ул Җантимер гаиләсендә алтынчы бала булып Кобыгыл

иseme белән үсә. Аның турында әсәрдәге өзек укыла: (*Җантимернең алты угыл... // Ялгызга — ясак (бу очракта: канун, яклаучы) булды.*) Идегәй турындагы мәгълүматка алга таба да игътибар итеп барыла.

Дастанның башка геройларына да игътибар ителә. *Аларның кайсылары тарихи шәхесләр дип уйлыйсыз?* дигән сорау куеп, җаваплар тыңлана. Әсәрдәге тарихи шәхесләр, һәм тарихи чынбарлыкка туры килгән географик җирлек, шул чорның тарихи вакыйгалары турында сөйләшү үткәрелә.

Күрсәтелгән QR-код аша кереп, Алтын Урда дәүләте һәм аның хакимнәре турында язма белән танышырга мөмкин. Бу урында Идегәйнең тарихи шәхес булуы хакында укытучы үзе дә бераз мәгълүмат биреп китә ала.

### Өстәмә мәгълүмат

Тормышта якты эз калдырган шәхесләр, халык күңеленә тирән үтеп кереп, лаеклы урын алалар. Кайберләре изге зат дәрәҗәсенә күтәрелә, алар турында халык телендә җыр-бәетләр, дастан-кыйссалар барлыкка килә.

Идегәй — төрки-татар халыклары иҗатында әһәмиятле урын алган һәм киң шигъри гәүдәләнеш тапкан каһарман, ихтирам яулаган тарихи шәхес. Бу шәхес турында нугай, Идел буе, Кырым һәм Себер татарлары, башкорт, каракалпак, казакъ, үзбәк, төрекмән, Алтай төркиләрендә легенда-риваятьләр, әкият-хикәятләр, мәкаль-әйтемнәр, күләмле дастан-кыйссалар иҗат ителгән.

*Хикмәт нәрсәдә соң? Кем ул Идегәй? Ни өчен бер-берсеннән берничә мең чакрым ераклыкта яшәгән халыклар аңа карата бер үк дәрәҗәдә тирән ихтирам саклыйлар?*

Тарихчы Әбелгази (1603—1663) сүзләренә караганда, Идегәй — чыгышы ягыннан мангыт (төркиләшкән монгол), ягъни ак мангыт кабиләсеннән. 1352 елда Котлыкыя би гаиләсендә дөньяга килгән. Әбелгазидан элегрәк язган тарихчы Әбдерразак Сәмәрканди Идегәйне Тимер Мәлик ханның баш әмире Балтычак (яки Балынчак) улы дип исәпли. Туктамыш хан белән сугышта Тимер Мәлик үлә, Балтычак әсирлеккә

эләгә, буйсынмаган өчен башы чабыла. Аның Идегәй атлы улы кала һәм, үсеп, тәҗрибәле яугир морза булып әверелә.

Идегәйнең балачагын сурәтләгән фактлар безгә килеп җитмәгән, әмма төрки халыклар иҗатында киң таралган күп риваять-легендаларга караганда, аның кечкенәдән үк тапкыр, үткен телле, үзсүзле, куркусыз булганлыгы күренә.

«Идегәй» дастаны, башка төрки дастаннар белән чагыштырганда, тарихи чынбарлыкка якынрак. Геройның (Идегәй) балачагы Туктамыш хан даирәсе, тарихта мәгълүм кайбер әмир морзалар арасында үтә.

Тарихи шәхес буларак, Идегәйнең исеме чыганакларда 1376—1377 еллар вакыйгаларына нисбәтле искә алына башлый. Бу вакытта Туктамыш хан Алтын Урда тәхете өчен сугышлар алып бара. Әмма алар уңышлы булмый. Нәкъ шунда аңа Идегәйнең ярдәме зур була. (Идегәйдә Туктамышның бер кызы кияүдә булган дигән фикер дә бар.) Аксак Тимер өч тапкыр зур гаскәр бирә һәм 1378 елда Туктамыш Алтын Урда тәхетенә утыра. Тәхеткә утыргач, Алтын Урданың бердәнбер хуҗасы булу теләге туа, әмма аңа Мамай комачаулый. 1380 елда Калка елгасы буенда алар арасында орыш була. Җиңелүгә дучар ителгән Мамай гаскәре качып китә. Качып китүче Мамай үзе дә Генуя сәүдәгәрләре тарафыннан хыянәтчел рәвештә үтерелә. Димәк, Туктамыш ханга бу бик кулай булып, ул тулы хокуклы хөкемдар булып кала. 1382 елда Мәскәүне яулап ала һәм җиңелмәс даны чыккан Аксак Тимергә каршы яу арты яу чаба. Идегәй белән мөнәсәбәте дә катлаулана.

Гарәп тарихчысы Ибн Гарәбшаһ (1388—1450) 1400—1411 елларда, Идегәйнең даны иң югары ноктага җиткән вакытта, аны үз күзе белән күргән була һәм аның турында түбәндәгеләрне язып калдыра: «Идегәй урта буйлы, каратут йөзле, тыгыз бәдәнле, куркусыз һәм куркыныч карашлы, шул ук вакытта мөлаем елмаюлы, искиткеч сизгер, акыллы тапкыр кеше була. Укыган вә дәрәҗәле кешеләрне ярата. Дәрвишләр, фәкыйрь вә дингә ышанучы кешеләр белән бик якын мөнәсәбәттә тора, алар белән ифрат гади рәвештә, уенкөлке сүзләр белән сөйләшә торган була. Ислам шәригатенә тирән ихтирам белән карый, һәрдаим ураза тота, төннәрен намаз укырга тора.

Туктамыш ханны яратмаса да, ул Алтын Урдадан китәргә җыенмый. Нык, көчле холкы белән зур дәрәҗәгә ирешә: Туктамыш ханның баш әмире була. Хан күп эшләрен аның белән киңәшеп хәл итә.

Идегәй үзенең һәрьяклап ханнан өстен торганлыгын белә, әмма Алтын Урдадагы йоланың катгый таләбе — Чыңгыз хан нәселеннән булмаган шәхеснең тәхеткә утыра алмавы — аңа хан булу мөмкинлеге бирмәвен ул яхшы таный. Бу урынга дәгъва белдерми дә, ләкин аның үз планнары булуы да күренә. Бу — Туктамыш ханны тәхетеннән төшереп, аның урынына үз тәрбиясендә үскән, Чыңгыз хан нәселеннән булган Тимер-Котлыкны утырту. Тимер-Котлык бик яшь булу сәбәпле, ул аны гел саклап йөртә. Хәтта Аксак Тимер янына качкан вакытта да аны үзеннән алданрак җибәрә.

Яуда җиңелеп, Туктамыш качканнан соң да Идегәй Аксак Тимергә иярми. Ул үзенең төп максатын тормышка ашырырга керешә: 1391 елда Мангыт олысына кайтып, аның морзасы, хөкемдары була. Мангыт олысыннан чиксез зур далаларның хуҗасы Нугай Урдасы үсеп чыга (Бу мәгълүматлар дастанны җентекләп өйрәнгән әдәбият галиме Ф. Урманче хезмәтләреннән алынды.)

Алга таба дастан геройлары һәм андагы вакыйгалар аша дастанның тарихи җирлеге дәлилләнә. Укучылар укытучы ярдәме белән дәфтәрләрендә түбәндәге таблицаны булдыра (бу мәгълүматларны укучы хәтерендә калдыру өчен, укытучы үзе теләгән алымнан файдаланырга мөмкин).

| Дастандагы тарихи шәхесләр | Дастанны реаль чынбарлык белән бәйләүче башка чыганаклар | |
|---|---|---|
| 1 | 2 | **3** |
| **Туктамыш** (?— 1406) — 1308 елдан башлап хакимлек иткән Алтын Урда ханы. **Аксак Тимер** (1336— 1405) (Әмир Бырлас, | Җирле атамалар: **Алтын Урда** — 1224 елдан оеша башлап, XV гасыр урталарына кадәр үз көчен саклап яшәгән дәүләт. | Тарихи вакыйгалар: **1378 елда** Туктамыш Алтын Урда тәхетенә утыра. |

| 1 | 2 | 3 |
| --- | --- | --- |
| Шаһ Тимер) — (1336—1405) —Урта Азия дәүләт эшлеклесе, полководец, 1370 елдан — әмир.<br>**Котлыкыя** би — нугайларның нәсел башы булган мангыт ыруыннан.<br>**Чыңгыз хан** (1155—1227) — Монгол империясенең ханы, Урта Азиягә, Көнчыгыш Европага яулап алу походлары оештырган.<br><br>**Идегәй** — 1419 елда Алтын Урда сарай аристократиясенә каршы сугышта үтерелгән, тарихта билгеле шәхес, халыкның легендар батыры.<br>**Кадыйрбирде** — Туктамыш хан улы, 1419 елда үтерелә.<br>**Норадын** — Идегәйнең улы. Тарихи документларда Нуретдин буларак билгеле, 1419 елда үтерелә һ. б. | **Ак Түбә** — елга һәм түбә исеме. Алтын Урда чорында Иделдән алып **Сырдәрьяга** кадәр булган җирләр **Ак Түбә һәм Ак Урда** дип йөртелә.<br>**Сарай, Сәмәрканд** һ. б. шәһәрләре;<br>**Алтын Таш** — Сарай шәһәрендәге хан бистәсе;<br>**Идел, Җаек** елгалары һ. б. | **1391 елда** Аксак Тимер белән Туктамыш хан арасында зур сугыш була.<br>**1395 елда** Туктамыш хан Алтын Урдадан качып китә һ. б. |

Идегәй образы турында сөйләшкәндә, дастанга нигезләнеп, күренекле рәссамнарыбызның берсе булган Байназар Әлминов сурәтләгән Идегәй образына да игътибар итү һәм рәссам Идегәйнең нинди сыйфатларын күрсәтә алуы турында әңгәмә үткәрү дә отышлы. Шул нигездә укучыларны рәссамның үзе белән дә таныштырып үтү мөмкинлеге ачыла.

Дәреслектәге Идегәйгә мөнәсәбәтле сорауларга җавап табабыз. Идегәй дә — башкалар кебек үк каршылыклы герой.

Әмма автор аны идеаллаштыра. Идегәй гадел, намуслы, горур, батыр, сизгер һәм акыллы, туган иле өчен үлемгә дә әзер шәхес буларак тасвирлана. Укучылар Идегәйнең уңай һәм тискәре сыйфатларын да әйтсеннәр. Автор аның хаталарын аклау юлын таба. Идегәй сугыш көл иткән шәһәрне торгыза. Гаделлек белән идарә итә, илгә кот кундыра. Әсәрдән бу өзекне дә укытабыз (Идегәй образына характеристика язасы барлыгын истә тотып, һәр укучы дәфтәрендә язма булдыра.) Димәк, дастанда Идегәй образы аша халыкның намуслы, гади кеше мәнфәгатьләрен кайгыртучы хөкемдар идеалы тормышка ашырыла. «Халык хакыйкать өчен көрәшүчеләрнең хата-кимчелекләрен дә гафу итә» дигән фикер уздырыла. Бу — әсәрнең тагын бер кыйммәте. Әлеге нәтиҗәгә дәлилләргә таянып, ышандыру юлы белән килергә кирәк. Өлешләргә бүлеп, аерым сораулар бирү, әңгәмә кору да яхшы нәтиҗә бирер.

Алда сөйләнгәннәргә нигезләнеп, «Идегәй» дастанының төрки халыклар арасында киң таралган булуы әйтелә, гасырларны үтеп безнең көннәргә кадәр килеп җитүенең сәбәпләре ачыклана.

Идеологик карашларга туры килмәү сәбәпле, дастан совет хакимияте вакытында халык күзеннән юк ителә. Әмма халык үзенең Идегәй кебек геройларын, халык акылын туплаган кыйммәтле әсәрләрен күңел түрендә саклый, һәм алар кабат яңаралар. Идегәй образының яңадан сәхнәгә кайтуы да шуны раслый.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу дәрестә укучы үзләштереп калырга тиешле төп сорауларга җаваплар табу.

Дастан сюжетын эзлекле итеп искә төшереп чыгу. Дастандагы вакыйгаларны барлау. Идегәй образына киңрәк тукталып, аның гамәлләренә бәя бирү.

«Идегәй» дастанындагы башка тарихи шәхесләр аларның гамәлләрен бәяләү.

**VI. Өйгә эш бирү.**

«И Идел-йорт...» өзеген ятларга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Адәм гарибә шул булыр —
Кайтып илен тапмаса! («Идегәй» дастанының идеясе һәм аның сәнгатьчә гәүдәләнеше).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянып эш итү; әсәрдәге геройлар арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның нәтиҗәсен аңлап әхлакый нәтиҗә ясау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, башкаларның хисләрен һәм үз хисләреңне аеру, атау һәм алар белән идарә итү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү, аралашу шартларына һәм максатларына бәйле рәвештә эмоцияләрне белдерү, үз фикерләрен әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — «Идегәй» дастанының идеясен аңлау, сәнгатьчә эшләнешен бәяләү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д.М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 5—17.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә. (Укучылар саны күп булганда, яттан сөйләүнең бер өлешен проект яклау дәресенә калдырырга мөмкин.)

2. Дастан: *Идел-йортны дау алды,*
*Яу өстенә яу килде,*
*Идегәй әйткән көн килде.*
*Хан сарае камалды.*
*Кырым, Казан, Аҗдаркан*
*Башлы-башлы ил булды,*
*Алтын Урда таралды*, — дигән юллар белән тәмамлана. *Ни өчен шундый зур дәүләт таркала? Дастанда аның сәбәпләре ачыкланганмы?* кебек сораулар белән укучыларны уйланырга этәрәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы сөйләшүгә нигезләнеп, дәреснең максаты ачыклана.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәресне алда бирелгән эзлеклелектә дәвам итү, телне бик үк яхшы белмәгән укучылар белән эшләүдә авырлык тудырса, эшне дәреслектәге 3—9 нчы сорауларга җавап табу тәртибендә алып барырга мөмкин.

Укучыларның дастан эчтәлеген белүләре һәм тарихи фактлар белән дә танышлыкларына нигезләнеп (*бу алдагы дәресләрдә әзерләнде*), әлеге дәрестә әсәрнең төп идеясен һәм аның сәнгатьчә бирелешен ачуга керелә.

Моның өчен схематик рәвештә генә дастанның вакыйгалары искә төшерелә. Аксак Тимер, Туктамышка хат язып, ау лачынын сорый. Туктамыш аны аксак аяклы дип хурлый, аңа: «Сычкан типкән бидаяк/Сиңа булсын, Шаһ Тимер!» — ди. Туктамыш ханның ау кошларын тәрбияләүче би Котлыкыя лачын балаларын Аксак Тимергә бирә, Туктамыш бинең һәм нәселенең башын чаптыра һ. б. Шул рәвешле вакыйгаларны туплап чыгабыз һәм бергәләп нәтиҗә ясыйбыз. Нәтиҗә: әсәр сәбәп — нәтиҗә рәвешендә берләшкән вакыйгалар җыелмасы.

Хәзер вакыйгаларны шул яссылыкта карыйбыз. Бирелгән сорауларга җавап табу әсәрнең идеясен ачарга ярдәм итә.

— *Туктамыш һәм Аксак Тимер арасында нидән каршылык килеп туа? Аның сәбәбе нинди?* (Туктамыш хан Аксак Тимергә данлыклы ау лачынын бирергә теләми. Туктамыш хан, Чыңгыз нәселе, зур дәүләт ханы булуы белән мактанып, Аксак Тимерне комсызлыкта гаепләп хурлый. Өзекне укыйбыз: «Ул хатында бу диде: [...] Сигез йортка сыймадың, / Тугыз йортны куймадың, /Сычкан типкән бидаяк /Сиңа булсын, Шаһ Тимер!»)

— *Аксак Тимер ни өчен лачынны үзендә булырга тиеш дип саный?* (Ул Туктамышны хан тәхетенә үзе утырткан, аңа буйсынуын тели, бу тарихи факт хакында дастанда әйтелмәсә дә. Аксак Тимер тирә-ягында үзеннән өстенрәк, аңа буйсынмаган хакимнәр булуын теләми. Димәк, икесе дә үзен хаклы саный.)

— *Туктамыш — Котлыкыя каршылыгының сәбәбе нинди?* (Туктамыш Котлыкыяны лачын балаларын Аксак Тимергә бирүдә — хыянәттә гаепли. Котлыкыя Туктамышны илне таратуда, дәүләтнең дәрәҗәсе, байлыгы бетүдә, кешеләрен бәхетсез итүдә — идарә итә белмәүдә гаепли. *Туктамыш — Идегәй каршылыгы.* Сәбәбе: Туктамыш Идегәйнең атасы Котлыкыя бинең башын чаптыра.)

Эчке каршылыклар:

1. Туктамыш җиңелмәс, һәммәсен үзенә буйсындырган хаким булырга уйлый. Моның өчен явызлыклардан да баш тартмый, яу чаба, илләрне, халыкларны тарката. Әмма ул илен ярата, дәүләтен киңәйтергә тели.

Үзен тәхеткә утырткан Аксак Тимер белән исәпләшми, тәхет тирәсендә үк кан дошманнары эш йөрткәнен сизми.

2. Җантимер Котлыкыя би улы Идегәйне саклап калып, үз улын үлемгә бирә (улына начарлык кыла). Котлыкыяга биргән вәгъдәсенә тугры кала.

3. Идегәй туган җирен ярата, аңа иминлек тели, әмма читкә кача, ил өстенә яу белән килә.

Норадын әтисен ярата, әмма Туктамыш хан сараенда ишеткән гайбәткә ышанып, аны сукыр итә. (Норадын Тукта-

мышның игезәк кызларының берсен сөя. Ә кыз, этисе өчен үч алып, ялганга бара: «Мин синең этиеңнән йөкле, бала көтәм», — дип белдерә. Бу дәреслектә юк. Укытучы искәртеп кенә китә ала.)

Укучылардан *Бу каршылыкларда кем гаепле?* дигән сорауга җавап эзләтелә. (1. *Туктамыш — Аксак Тимер каршылыгы*. Икесе дә хаклы. Туктамыш Аксак Тимернең бөтен нәрсәгә хуҗа булырга омтылуын, комсызлыгын күтәрә алмый. Горурлыгына кагыла. Аксак Тимер Туктамышны үзенә буйсынырга тиеш дип саный. Ул аны тәхеткә утырткан.

2. *Туктамыш — Котлыкыя каршылыгы*. Икесе дә хаклы. Котлыкыя Туктамышны идарә итә белмәүдә гаепли, илгә лаек хан түгел дип фикерли. Шул сәбәпле үзенең хыянәтен аклый. Туктамыш фикеренчә, Котлыкыя ханга хыянәт итә, дошманына сатыла. Башка каршылыклар да шушы схемага нигезләнә. Бу мөнәсәбәтләр фикер алышып, әсәрдән өзекләр укып ачыклана. Һәр укучы вакыйгага мөнәсәбәтле үз фикерен әйтсен, дәлилләсен. Әмма нәтиҗә бер: әсәрдә һәркем үзен хаклы санап, үзен аклап эшләгән яманлык икенче яманлыкка сәбәп була. Ул зурая, үсә һәм куәтле дәүләтне җир белән тигезли, дан яулаган хакимнәрнең башын кистерә. Хәзер беренче дәрес башында куелган сорауга укучыларның җавапларын искә төшерүләрен сорыйк. *Явызлык кылу яхшы нәтиҗәләргә китерә аламы?* дигән сорауга дастан эчтәлегенә нигезләнеп җавап бирелә.)

Әсәрнең төп идеясе — яманлыкны үстермәскә, үч алуны беренче максат итмәскә, хискә бирелеп, үз горурлыгыңны яклау юлына басканчы, акыл белән аның нәтиҗәсен күрә белү кирәк.

Өзекләрне укыганда, дастанның сәнгати ягына игътибар ителә. Кабатлаулар, чагыштыру, гипербола (Идегәйне тасвирлаганда, бик ачык мисалларын күрәбез) әсәр тукымасындагы вазифасын билгелибез. Ритмик тигезлеге, теленең матурлыгы, афоризмнарга байлыгы турында мисалларны укыганда ук аңлатабыз. Авторның үз геройларына мөнәсәбәтен күрсәткән урыннар да, хикәяләүче һәм бәя бирүче буларак чыгыш ясавы да мисаллар белән дәлилләнә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреснең темасына әйләнеп кайтып, Туган ил төшенчәсенең кеше өчен никадәр газиз булуын ачыклаудан башлау дөрес булыр. Иң бәхетсез кеше — Туган илен югалткан кеше. Димәк, Туган җирен саклау, аның алдында үз бурычын үтәү, аны барлык шәхси мәнфәгатьләрдән өстен кую — һәркемнең изге бурычы. Бу нәтиҗәгә килү өчен, геройларның шәхси мөнәсәбәтләре тудырган вакыйгаларның зур дәүләтнең җимерелүенә китерүен тагын бер кат искә төшерү кирәк. Дәресне дастандагы:

*Идел-йортны дау алды,*
*Яу өстенә яу килде,*
*Идегәй әйткән көн килде.*
*Хан сарае камалды.*
*Кырым, Казан, Аҗдаркан*
*Башлы-башлы ил булды,*
*Алтын Урда таралды,*

— дигән юллар белән башлаган идек. Әйе, зур дәүләт таркала, тарих та шуны раслый, әмма аерым-аерым ханлыклар да озак яшәми. «Аерылганны — аю, бүленгәнне бүре ашар» ди, халык. Бу очракта да шулай була. Шуннан чыгып нәтиҗә ясала: Дастан «явызлык һичкайчан да яхшылык тудыра алмый» дигән идеяне дәлилли.

Әсәр катлаулы, укытучы аны төрле яклап ача ала, әмма Идегәйгә авторның булган уңай карашы, аны гади халык бәхетен кайгыртучы буларак күрсәтүенә игътибарлы булу кирәк. Әсәр Идегәй образы аша кешенең Туган иленә, халкына мәхәббәтен ача. Әлеге фикергә нигезләнеп, укучыларга проект эше эшләргә тәкъдим ителә.

**VI. Өй эше бирү.**

«И Идел-йорт, Идел-йорт» темасына проект эше башкарырга.

Укытучы проект эшеннән нәрсә көтелгәнне аңлатып бирә. Моның өчен ике геройның — Идегәйнең һәм Туктамыш ханның — Идел-йортка мөнәсәбәтен ачыклау яхшы. Идегәйнең мөнәсәбәтен 10 сорауга җавап бирү аша ачу мөмкин. Туктамыш ханның да илдән киткәндәге тулгавы бар. Аның белән

танышып китү отышлы булыр. Ул дәреслектә юк, шуңа түбәндә китерәбез:

*Әй байтагым, байтагым (халкым),*
*Сине алдырдым мин тагын,*
*Дошман талар килгән соң,*
*Әл-аман бул миннән соң!..*
*Башлы, башлы башлы урда,*
*Башта синнән аерылдым;*
*Байтагы эчеп бетермәс*
*Бал капчыктан аерылдым,*
*Әл-аман бул миннән соң!*
*Сулап булат игәгән (кылыч кайраган)*
*Алыбымнан (сугышчы) аерылдым;*
*Күтәрә бүе сум алтын (тулысынча саф алтын)*
*Күрекле тәгаемнан (тәхетемнән) аерылдым...*

Ике өзекнең аермасын табыйк. Идегәй өчен туган җир — кендек каны тамган урын. Туктамыш та бу җирне ярата, үзеннән соң да аңа иминлек тели. Әмма ул аны тәхет, дан алган, акча суктырган урын буларак күзаллый, байлыгыннан аерылуга борчыла.

Туган илне ихлас ярату шунда туган, үскән, нәселе белән береккән кешеләргә генә хас икәнлеге дәлилләнә. Читтән килгәннәр аны байлыгы, үзенә китергән файдасына карап кына бәяли. Бу — әсәрнең тагын бер бик әһәмиятле кыйммәте.

Проект эше эшләгәндә укучылар туган җирне төрле яклап ача алалар. Аның тарихы, икътисади, мәдәни байлыклары турында сөйләргә дә мөмкин.

Проект эшен шул нигездә төркемнәрдә башкару мөмкинлеге дә бар. Аны сыйныфташлары алдында якларга әзерләнергә кирәклеген әйтелә (Проект эшенә алдан әзерләнергә вакыт калсын өчен, эшне алдагы дәресләрдә үк биреп куярга мөмкин).

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** «И Идел йорт, Идел йорт» (Проект эшен яклау).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган җирнең газизлеген аңлау, аның тарихы, хәзергесе һәм киләчәге турында ачык фикере булу, туган җир белән горурлану, туган җир киләчәгендә үз шәхесен күрү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — конкрет мәсьәләләрне хәл итү барышында командалы (парларда, төркемнәрдә, күмәк) һәм индивидуаль эшнең өстенлекләрен аңлау һәм файдалану, куелган бурычны хәл иткәндә, үзара хезмәттәшлекнең төркем формаларын куллану зарурлыгын аңлау, иптәшләренең җавапларын бәяләү; әдәбиятта өйрәнү объектының үзенчәлекләрен, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен һәм объектларның үзара бәйлелеген билгеләүдә мөстәкыйль төзелгән план буенча зур булмаган тикшеренү үткәрү, тикшеренү барышында алынган мәгълүматның кулланырлык һәм ышанычлы булуына бәя бирү; үткәрелгән проект нәтиҗәләрен башкалар алдында тәкъдим итү, презентация бурычларын һәм аудитория үзенчәлекләрен исәпкә алып, чыгыш форматын мөстәкыйль сайлау, аңа ярашлы иллюстратив материаллар кулланып, телдән һәм язма текстлар төзү.

*Предмет нәтиҗәләр* — проект яклау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 5—17.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Идел йорт турында сөйләшү үткәрү. Идел буенда яшәгән борынгы бабаларыбыз тоткан дәүләтләр, аларның мәдәни,

икътисади тормышыннан мәгълүмат бирү. Хәзерге Татарстан Республикасының уңышлары турында хәбәрләшеп, укучыларның чыгышларына күчелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Укучыларның чыгышлары тыңлана. Ул фикер алышу, үзара сораулар бирү белән бәйләнеп бара.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Чыгышларга нигезләнеп, укучылар нинди яңалык, мәгълүмат алулары белән уртаклашалар. Сорауларга җаваплар бирәләр.

**VI. Өй эше бирү.**

Дастан турында алган белемнәрне ныгытырга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Таш кайчан телгә килә? (Әдәби алым буларак пейзажның әсәрдәге роле).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — экологик культура дәрәҗәсен күтәрү, экология мәсьәләләренең глобаль характерын һәм аларны чишү юлларын аңлау; табигать матурлыгына ихлас соклану, аның рухны баету сәләтен тану.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, чишү юлларын билгеләү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; әдәби күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү; үз фикерләрен әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — әдәби әсәрнең сәнгатьчә эшләнеш үзенчәлеге буларак, пейзажның мөмкинлекләрен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 18—33.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучыга өч пейзаж картинасы тәкъдим ителә ала. Аларның бер-берсеннән аерылып торырлык төрле булуы шарт. Укучы рәсемнәрнең уртак ягын табып, пейзаж икәнлеген әйтәчәк. Шунда ук рәсемдәге пейзажларның ниндитойгылар уятуын да ачыклау яхшы. Бу — укучыларга табигать күренеше белән кешенең хисләре арасындагы бәйләнешне аңларга ярдәм итә.



Аккош күле.
Рәссам: Гайфуллин Айрат
https://www.liveinternet.ru/users/truskovalent/post372200784



Тугызынчы валл.
Рәссам: Иван Константинович Айвазовский
https://veryimportantlot.com/ru/news/obchestvo-i-lyudi/devyatyj-val-kartina-ivana-konstantinovicha-ajvazovskogo



Рәссам:
Николай Константинович Рерих
https://www.livemaster.ru/topic/2744387-gory-na-polotnah-izvestnyh-russkih-hudozhnikov

Алдагы этаптан чыгып, дәреснең темасы, максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

*Нәрсә соң ул пейзаж? Сүзләр ярдәмендә пейзажны тасвирлап бирү мөмкинме?* дигән сорауга бергәләп җавап табыла. Шул ук рәсемнәргә кире кайтып яки башка рәсем ярдәмендә укучылар рәссам ясаган картинаны сүзләр ярдәмендә тасвирлап бирәләр. Укучыларның рәсемдәге һәр детальгә игътибар биреп, төгәл тасвирлауларына ирешү максат итеп куела. Моның өчен рәсемне махсус берничә квадратка бүлеп карау һәм һәр өлештә нинди детальләр күрергә мөмкин икәнлеген билгеләп чыгарга була. Укучылар сөйләменнән соң нәтиҗә ясала: димәк, сүзләр ярдәмендә дә пейзаж күренешләрен тасвирлап бирергә мөмкин. *Әдәби әсәрдә пейзаж тасвирланган урыннар белән очрашканыгыз бармы? Мондый сурәтләү алымы кирәк микән? Әллә пейзаж тудыру буяулар ярдәмендә генә, рәссамнар өчен генә хас нәрсәме?* кебек сорауларга җавап табыла. Бу урында укучыларның пейзаж лирикасы төшенчәсе белән таныш булулары ярдәм итәр. Фикерне дәлилләп ныгытып кую өчен, төрле әдәби әсәрләрдән (өзекләр дәреслектә дә бар) пейзаж тасвирланган урыннары укып, фикер алышу үткәрелә. Әлеге мисалларны карап чыккан соң, укытучы, дәреслек материалына нигезләнеп, әдәби әсәрдә пейзажның вазифасы турында аңлатып китә.

Пейзажның төрләренә мисаллар тәкъдим итеп, укучылардан аның кайсы төргә караганлыгын билгеләтергә мөмкин.

Пейзажның геройның эчке дөньясын ачуга ярдәм итүенә мисал итеп, И. Газиның укучыларга таныш булган «Онытылмас еллар» әсәреннән өзек китерергә мөмкин. Укучылар

әсәрне искә төшерәләр һәм Хәлимнең кичерешләре белән автор сурәтләгән пейзаждагы уртаклыкны табалар.

*«Икенче көнне иртән Хәлим үзләренең ишегалдына керде дә күңеле тулып карап торды. Бакча да күңелгә ят. Алмагач төпләре тулы сап-сары яфрак. Ботаклар ялангач, әллә кайдан кинәт-кинәт исеп куя торган салкын җил аларны рәхимсез бөгә. Неп-нечкә ботакның очында көчкә эләгеп тора торган бердәнбер яшел яфрак күбәләк шикелле талпына иде. Кая киткән бу алмагачларның яфракка күмелеп, йодрык-йодрык хорошавкалар авырлыгыннан ботаклары сыгылып төшеп, кешеләрне куандырып утырган матур, күркәм чаклары?*

*Чүмәлә-чүмәлә булып торган карлыган куаклары яныннан узып барганда, Хәлим кинәт тукталды: ботаклар арасында, самавыр «түбәтәе» шикелле, ниндидер кош оясы күренеп тора иде. Яңгыр астында ул инде каралган, җил аны селкетә, туздыра... Мамыклары очып беткән, тупас кыллары гына калган... Җәйли матур, төзек оя хәзер бөтенләй җимерек. Ә бит бу ояда тормыш кайнаган... Әниләре, тырышып-тырышып, корт ташыган... Үскәннәр дә кайсы кая таралышып киткәннәр... Кайда йөриләр икән ул кошлар хәзер? Ата-аналары белән бергә микән, әллә аларны да тормыш төрле якка атты микән?»*

Бакча — Хәлимнең күңел халәте, анда күңелсез көз, күңелне сөендерерлек бер ямь дә юк. Усал җил. Яфраклары саргаеп коелып беткән бакча — Хәлимнәр гаиләсенең бетүе. Агачтагы бердәнбер яшел яфрак — Хәлим үзе. Кош оясы — Хәлимнәрнең гаилә оясы. Бу — пейзаж бирелешендәге иң күренеп торган детальләр генә. Укучылар белән шуларны табып, пейзажның кешенең рухи халәтен, язмышын ничек төгәл аңларга ярдәм итүен дәлилләргә мөмкин.

Укучыларның әзерлегеннән чыгып, дәреслектәге материалга нигезләнеп, әдәби төрләрдә пейзаж бирелешенең үзенчәлекләренә тәфсиллерәк тукталырга була.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу дәрестә алган белемнәрне хәтердә кадыру өчен кабат темага әйләнеп кайту кирәк.

*Әдәби әсәрдә пейзаж төшенчәсе нәрсәне аңлата?*

*Әсәрдә пейзажның вазифасы нинди*? һ.б. сорауларга җавап табыла.

**VI. Өй эше бирү.**

Дәреслектән Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» әсәрен (24—32 нче битләр) укырга. Эчтәлеген сөйләү өчен план төзергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Җидегән чишмә нәрсә турында җырлый? (Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» романының идеясен ачуда пейзажның роле).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — экологик культура дәрәҗәсен күтәрү, экология мәсьәләләренең глобаль характерын һәм аларны чишү юлларын аңлау, табигать белән хозурлана белү, табигатьнең кеше тормышындагы әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, эшчәнлек нәтиҗәләренә ирешү (ирешмәү) сәбәпләрен исәпкә алу, алган тәҗрибәгә бәя бирү, билгеле бер ситуациядә уңай якны таба белү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, куелган уку бурычын чишү өчен, кирәкле җитешмәгән мәгълүматны ачыклау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — әсәрнең эчтәлеген белү, идеясен, проблемасын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 18—32.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Укучылардан табигать күренешләрен аеруча матур тасвирлаган язучыларны искә төшерүләрен сорарга, аларның нинди әсәрләрен хәтерләүләре белән кызыксынырга мөмкин. Пейзаж күренешен сурәтләгән, укучыга таныш булган берничә өзек тәкъдим итеп, ул өзекләр турында фикер алышу үткәрергә була. *Кем язган, нинди әсәр, әсәрдә нинди вакыйга белән янәшә кулланылган, вазифасы нинди?* кебек сораулар фикерләшүне оештырганда ярдәм итә ала.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Әңгәмәгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алга таба пейзажның әдәби әсәрләрдә бирелешен Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» әсәре үрнәгендә караячакларын әйтеп, әсәр турында беркадәр мәгълүмат китерелә. Әдипнең туган җир, халык язмышы, туган телебез, гореф-гадәтләребезне саклау мәсьәләсендә күп хезмәт куйган шәхес булуы күрсәтелә.

Әсәр туган як табигатен саклау мәсьәләсен күтәрә, шул ук вакытта туган җир табигате кешенең рухи дөньясы, әхлакый кыйммәтләр, милли яшәешебез белән тыгыз бәйләнештә бирелә. «Җидегән чишмә» әсәренең язылу тарихын Ютазы районы «Ак чишмә» колхозы белән бәйләп карыйлар. Бу якларда Гомәр Бәширов берничә тапкыр эшлекле сәфәрдә була. Ык буендагы халыкның тормышын өйрәнә, үткәннәр белән кызыксына «Ак чишмә» колхозына кергән Салкын чишмә авылындагы бик бай тугайның сөреп юкка чыгарылуыннан да халык зарланмый калмагандыр. Әсәрдәге Алтынбикә тугае язмышы да шуннан алынган булырга тиеш. Татарстанда Җидегән чишмә Лениногорск районында урнашкан (сылтама буенча мәгълүмат бар).




https://ya.ru/video/preview/4388335907624576379

Гомәр Бәшировның туган ягы — Арча районы Яңа Сала авылында, язучының туган нигезеннән ерак булмаган чишмәне авыл халкы Җидегән чишмә дип йөртә.

Дәреслектән Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» романыннан өзек белән танышу. Дәреслектән 21—24 нче битләрне укып, пейзаж тасвирланган урыннар табыла һәм аларның әсәрдәге вазифасы билгеләнә. Укылган өзектә беренче җөмлә (*Тышта игенченең җелегенә үтә, ашлыкны черетә торган бәйләнчек вак яңгыр ява иде)* пейзажны сурәтли. *Бу пейзаж ярдәмендә автор нәрсәгә ишарәли?* (Пейзаж Гайнанның күңел халәтенә янәшә куела.) *Без аны кайдан аңлап алабыз?* (Алдагы тексттан аңлашыла: Башында — буталчыклык, күңелендә — бушлык. Кәефе нәкъ әнә шул томанмы, вак яңгырмы каплап торган шыксыз пычрак һава төсле — өметсез.)

Укылган өлештән пейзаж бирелгән урыннарны табып, аларның әсәргә нинди мәгънә өстәүләрен ачыклау укучыларга әсәрдә пейзажның вазифасын аңларга ярдәм итә.

«*Бабасы исән чагын күреп калган әнә ул карт юкәләр, мәһабәт каеннар да Гайнанның бабасы янына килүен хуп күреп утыралар. Бу яшь егетнең ялкынлы уйларын, йөрәк тибешен аңлыйлар кебек. Менә бит! Аның бабасы да кай-*

*чандыр шушы юлдан йөргән, шушы басуларда ашлык чәчкән, болыннарда печән чапкан. Бу җирләргә, бу урман белән болыннарга безнең улларыбыз, оныкларыбыз хуҗа булыр дигән»*.

Пейзаж сурәтләнеше аша туган җирнең буыннар арасындагы бәйләнешне саклавы, туган җирдәге һәр нәрсәдә узган буыннарның хатирәсе саклануы, үткәннәрне белгән, аны хөрмәт иткән шәхеснең генә киләчәге өметле була, дигән фикергә киленә.

*«Тау-тау болытлар, берсен берсе кысрыклап куыша-куыша, тыелгысыз бер агым булып, Урал тауларына таба агылалар; иген кырлары, болыннар өстеннән аларның ала-кола күләгәләре чабыша иде* (шулай ук Гайнанның эчке халәтендәге төрлелек — ала-колалык. Аның да башында бертуктаусыз уйлар агыла, ул үзенең укырга керә алмавы өчен борчыла. Шул ук вакытта үзенең хезмәт юлын туган җирендә башлап җибәрү аның күңелен беркадәр тынычландыра, ул умарталыкны, Минһаҗ картны ихлас якын итә. Шуңа аның күңелендә төрле уйлар, каршылыклы хисләр туа.)

*Уңга борылып умарталыкка күтәрелер алдыннан, Җидегән чишмә тавышы яңадан йөрәк сагышын кузгатты. Бер-берсеннән ерак түгел җиде тамырдан бәреп чыккан җиде чишмә. Борын-борын заманнарның бер шагыйрь җанлы кешесе бу могҗизага сокланып карап торган да җиде туганны, җидегән йолдызга тиңләп, «Җидегән чишмә» дип атаган»*.

Әсәрдә пейзаж кешеләрнең рухи дөньясын ача: кеше табигать белән хозурлана, күңеленә ләззәт ала (табигать могҗизасы — бер тамырдан типкән җиде чишмәне шигъри исем белән Җидегән чишмә дип атый). Ә күңелендә укырга керә алмавы сәбәпле авыр уйлар яшәгәнлектән, Гайнан чишмәнең тавышыннан үз күңеленә аваздашлык — йөрәк сагышы тоя.

Әлеге эзлеклелектә өзектәге пейзаж күренешләре турында сөйләшү уздырып, нәтиҗә ясауга киләбез. Укылган өзектә геройларның рухи кичерешләрен, табигать белән бәйләнешен пейзаж күренешләре аша белдерү авторга әсәр идеясен ачарга ярдәм итә. Кеше үзе дә — табигать баласы. Аның

тормышы, рухи дөньясы туган җире, аның табигате белән тыгыз бәйләнгән.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта дәреслектә бирелгән сораулар ярдәм итә ала.

**VI. Өй эше бирү.**

«Туган як чишмәләре» дигән темага (укытучы аңлатып бирә) яки Г.Бәширов иҗаты турында чыгыш әзерләргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Табигатьнең үз кануннары бар (Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» романында табигать образлары).[1]

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — экологик проблемаларны күтәргән әдәби әсәрләр белән танышканда формалашкан карашларга да нигезләнеп, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерүче гамәлләрне кире кагу; табигатьне саклауның әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби күренешләрне өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау; фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү, аралашу шартларына һәм максатларына бәйле рәвештә эмоцияләрне белдерү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — образлар системасын, әсәрдә күтәрелгән проблеманы аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары

---

[1] Бу тема рус телендә белем бирүче мәктәпләр өчен генә тәкъдим ителә.

өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 18 — 32.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Әсәрдәге табигать күренешләре, геройлар өчен аеруча әһәмиятле истәлекле табигать һәйкәлләре (Җидегән җишмә, Алтынбикә тугае) турында искә төшерелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Бу дәрестә укучылар әсәрдә тасвирланган табигать күренешләренең һәрберсенә игътибар итәргә, автор әйтергә теләгән фикерне тотып алырга өйрәнәләр.

«Җидегән чишмә» — табигать могҗизасы, шагыйрь җанлы кеше шул могҗизага сокланып, җиде җирдән тибеп чыккан чишмәне җидегән йолдызга тиңли. Табигатьне аңлау, аның белән соклана белү шагыйрь җанлы, саф күңелле, соклану сәләтенә ия кешеләргә хас икән. Табигатьне саклаучылар да изге күңелле була.

Автор яшәештә һәрнәрсә үзара бәйләнешле дип дәлилли, әмма табигать аерым гына яши алмый. Ул кешеләр белән дә тыгыз бәйләнеш саклый. Гайнан, Сәет, Камил Дусаев образларына, аларның күңел дөньясының сафлыгына игътибар ителә. Ул әсәрдәге вакыйгалар белән дәлилләнә.

Кешеләр табигатьне саклый да, аңа зыян да сала алалар.

Фәритнең тракторы белән караманы йолкып алу вакыйгасы тикшерелә. Әсәрдә агачны йолкып алу кош ояларын туздыру, табигать хозурлыгын җимерү генә түгел, ул кешеләрнең хәтерен йолкуга тиң итеп бәяләнә.

Кыр казларының күл белән хушлашулары күренеше дә укып анализлана. Табигатьнең төгәл үз кануннары барлыгы, аны бозуның кеше өчен дә фаҗигагә китерүе нигезләнә. Тормышчан мисаллар белән нәтиҗә ясала.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу — дәрестә алган белемнәрне хәтердә калыру өчен кабатлап үтелә. Укылган өлештәге геройлар атала, аларга кыскача бәя бирелә. Нинди вакыйгалар белән танышулары турында сөйләтелә. Герой кичерешләре белән табигать күренешләренең тәңгәллеге ачаклана. Әсәрнең проблемасы кабатлап әйтелә.

**VI. Өй эше бирү.**

Укучыга әсәрнең үзе теләгән өлешен тәфсилле итеп сөйләргә яки «Табигатьнең гүзәл мизгеле» дигән кечкенә тасвирлама инша язарга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Табигать-ананың сулышын тоеп (Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» романында пейзаж сурәтләнеше ярдәмендә татар халкының рухи байлыгын ачу).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — табигый, технологик һәм иҗтимагый мохитнең үзара бәйләнеше шартларында гражданин һәм кулланучы буларак үз ролен аңлау; күңеле саф, хисләре бай кеше дөньяны да матурлавын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, эшчәнлек нәтиҗәләренә ирешү (ирешмәү) сәбәпләрен исәпкә алу, алган тәҗрибәгә бәя бирү, билгеле бер ситуациядә уңай якны таба белү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби күренешләрне өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» романында пейзажның вазифасын ачу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 18—40.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *Рухи байлык нәрсә ул?* дигән сорауга җавап табарга кирәк.

Укучыларның *рухи* сүзен ничек аңлауларын сорап, җаваплар тыңлангач, укытучы үзе аңлатып китә.

Рухи — кешенең эчке дөньясы, күңел кичерешләре, хисләре, матди булмаган кыйммәт. Ни өчен аны *байлык, кыйммәт* сүзләре ярдәмендә ачыклыйбыз соң? Ул матди нәрсәләр кебек сатып алынмый, нәрсәдәндер җитештерелми. Ул — тәрбия нәтиҗәсе: читтән алган тәрбия (гаилә, мәктәп һ.б.), үз-үзеңне тәрбияләү, нәрсә яхшы, нәрсә яман икәнен аера белү. Кешенең рухи дөньясы ярата, кичерә, кызгана, теләктәшлек, хөрмәт итә, хәтерли белү һ.б. бик күп кыйммәтләрне үз эченә ала. Рухи байлык — ул кеше өчен хас булган һәм аны бәяли торган иң зур кыйммәт. Әгәр кешенең рухы (эчке дөньясы) тәрбияләнмәгән булса, аның күңелендә явызлык, көнчеллек, башкаларны түбәнсетү, матурлыкка соклана, аны бәяли алмау кебек тискәре сыйфатлар урнаша.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Әңгәмәгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Рус телендә белем бирүче мәктәпләр текстның үзләренә таныш өлеше белән генә эшли.

*Г. Бәшировның без укыган әсәрендә кайсы геройларның рухи дөньясын ачуга автор ныграк игътибар иткән?* ди-

гән сорауны ачыклыйбыз. Моның өчен эчтәлекне искә төшерү кирәк булыр. Геройның рухи дөньясын аның гамәлләре, күңел кичерешләре күрсәтә. Укучылар Сәет, Гайнан, Камил Дусаев, Гайшә-Малайша исемнәрен атарлар. Шулай ук Фәрит, Сөембикә һәм Рабига апалар да искә алына.

Алга таба укучыларны төркемнәргә бүлеп, аларга һәр геройның рухи дөньясы әсәрдә ничек ачылуын тасвирлау эшен йөкләргә була. Укучылар үзләренә бирелгән геройның рухи дөньясын бәяләргә ярдәм итә алырлык аларның эш-гамәлләрен, уй-кичерешләрен билгеләп чыгалар, фикерләрен әсәргә таянып нигезлиләр. Ахырдан укытучы нәтиҗә ясый. Төркемнәрнең җавапларын тыңлаганнан соң, Фәрит, Сөембикә һәм Рабига апаларга чагыштырма бәя бирү дә рухи кыйммәткә мөнәсәбәтне ачарга ярдәм итә. Ялгыз карама авыл халкы өчен матди байлык кына түгел, ул — хәтер, хатирә, сугыш кырыннан кайтмый калганнарның истәлеге, төсе дә. Әсәрдә пейзаж геройның рухи халәтен аңлатып бирүгә ярдәм иткән урыннарын табып укып, аларның нинди геройны кайсы яклап ачуын сөйләү эше белән дәресне дәвам итәргә мөмкин.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*1. Укылган өзекләрдә сезгә кайсы геройның рухи дөньясы аеруча ошады?*

*2. Гайнанны сез нинди егет буларак хәтерегездә калдырдыгыз?*

*3. Гайнанның рухи хәзинәсендә татар халкына хас нинди сыйфатлар урын ала?*

Дәреслекнең 40 нчы битендәге сорауларга җавап бирү белән дәвам ителә.

**VI. Өй эше бирү.**

Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» әсәрен укып килергә.

Дәреслекнең 40 нчы битендәге 7 нче сорауның беремен үтәргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Нинди ул Агыйдел кызы? (Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» повестенда яшьлек, мәхәббәт һәм пейзаж параллельлеге).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — хәтер, хатирәләрнең күңел байлыгы икәнен аңлау, үкенмәслек итеп яшәргә өйрәнү, уйлап эшләү кирәклегенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, эшчәнлек нәтиҗәләренә ирешү (ирешмәү) сәбәпләрен исәпкә алу, алган тәҗрибәгә бәя бирү, билгеле бер ситуациядә уңай якны таба белү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби күренешләрне өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим» әсәрендә пейзажның ролен ачу, әсәрнең төп фикерен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 40—58.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә. *Әсәр нәрсә турында?* дигән сорауга җавап табыла (Әсәр Әнис исемле геройның яшьлек хатирәләре хакында.)

2. *Дөнья — режиссёрсыз һәм тамашачысыз спектакльме икән әллә? дигән сорау куя герой. Сез ничек уйлыйсыз*? (Укучыларның җаваплары тыңлана.)

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әсәрдән өзек укыла:

*Яшьлек тә, мәхәббәт тә үзе туры килгән чор һавасын сулап яши. Революция, реакция, сугыш, тынычлык — һәркайсы аларга үз эчтәлеген бирә, үз мөһерен суга (тамгасын сала). Тик ни генә булмасын, соңыннан һәркем бер үк ачышны ясый: —*

*Алып китте еллар яшьлегемне,*
*Бәрабәргә акыл бирде.*
*Алыгыз, еллар, биргән акылыгызны,*
*Кайтарыгыз Яшьлегемне кире!*
*Бу фикер нинди нәтиҗә ясарга ярдәм итә?*

(Кеше, кайсы чорда гына яшәсә дә, яшьлеген сагына, мөмкин булса, бар нәрсәсен биреп, ул аны һичшиксез кире кайтарыр иде.)

Әсәрнең төп герое Әнис тә яшьлеген сагына, үткәндәге матур хатирәләрдә яши. Ләкин бу хатирәләре үкенечләр белән бәйле.

Алга таба, Әнис турында сөйләшү алып барыла. Укылган өзектән чыгып, укучыларның *аның холкын, күңелендә нинди хисләр яшәвен, тормышыннан канәгатьме, әллә мөмкин булса нәрсәләрне дә үзгәртер идеме? Әгәр үзгәртергә теләсә, ни өчен дип уйлыйсыз?* кебек сорауларга җавапларын тыңлагач, укытучы Әнис күңелендәге тирән яшерелгән үкенеч тойгысының беренче мәхәббәте булган Фәһимәне югалтуы, аның белән бергә булмаулары бары үзенең ялгышы икәнлеген аңлаудан икәнлеген әйтә. Аның яшьлегенең иң матур мизгелен кат-кат кайтып уйлавын, анализлавын, бу вакыттагы тәҗрибәсезлеге, акыл җитмәвенә үкенүен аңлата. Форсаттан файдаланып, үткәннәргә үкенмәслек итеп яшәү турында кыска гына сөйләшү үткәрергә мөмкин. Бу урында Әниснең тормыш тәҗрибәсе дә ярдәм итәр дип, кабат Әнис образына кайтабыз.

Әсәрдә Әнис үзенең хата һәм үкенүләре, үткәннәр белән яшәве турында ачыктан-ачык сөйләми. Аның күңел халәте гел табигать тасвирланышы аша бирелә. Укучылар белән шул параллельлекне күзәтеп, Әниснең яшьлегендәге хаталарын барлап нәтиҗә ясала.

*Әнис тормышны ничек күз алдына китерә? Моның белән ул нинди фикер җиткерә дип уйлыйсыз?* Шул өзек (*41 нче бит: Мәңгелек декорация....)* укытыла, җаваплар тыңлана.

Әнис тормышны мәңгелек агышы буларак бәяли, вакыт кеше язмышына төзәтүләр кертми, битараф, аны бары күзәтә генә. (*Шулай да миңа кемдер салкын, ваемсыз, шәфкатьсез күзләре белән карап, күзәтеп торадыр кебек.*)

*Шулай бит, күзләр* ***көндез кечкенәрәк нәрсәләрне күбрәк күрсә, төнлә ераграк, олырак әйберләрне шәйли****. Җирдә офык чикләгән, һава зәңгәрлеге каплаган араларны узып, төнлә кешенең карашы* ***Галәм киңлекләренә чыга****.*

Бу өзектәге «*көндез кечкенәрәк нәрсәләрне күбрәк күрсә, төнлә ераграк, олырак әйберләрне шәйли*» дигән фикердә *көн* һәм *төн* каршылыгының мәгънәсе аңлатып кителә. Көн — кеше гомеренең яшьлек, тәҗрибәсез, вак нәрсәләр белән вакыт уздырган, төн — акыл туплаган, тормышка фәлсәфи караш ташлаган вакыт. Әнис үткәннәр турында төнлә уйлана.

Әниснең имәнне тасвирлаган өзекне укып нәтиҗә ясала: укучылар үз фикерләрен әйтә, укытучы тулыландыра, юнәлеш бирә.

Нәтиҗә ясарга түбәндәге фикер ярдәм итә: *Хәзер инде әйтә алмыйː, көядәнме, әллә шул ярадanмы күбрәк җәфа чиккәндер имән. Менә бит кайчак изге ният белән нинди кызыклар да ясап куябыз без; уйланырсың шул, иптәш.* Әнис Фәһимә күңеленә уйламый салган яралары турында шундый нәтиҗә ясый да, каеннар турында сөйләп, үзенең яраткан кешесе күңеленә салган яраларын каеннарга балта белән чокып ясалган яраларга тиңли. Шул ясалган яралар белән Фәһимә дә аның күңелендә мәңге уелып калганлыгын әйтә.

Кеше язмышын (һәм үзенекен дә) яз көне шытып чыккан үлән белән чагыштыра (Б.42– 43).

Яшьлекнең, беренче мәхәббәт хисенең матурлыгын Агыйдел буеның матурлыгы аша аңлата (Б.43– 44).

Фәһимәнең матурлыгын да табигать матурлыгы белән үреп күз алдына китерә: *Ах, художник булсам! Бу сынны ясар өчен, майлы буяулар сайламас идем мин, җиңел аква-*

*рель сайлар идем. Җиңел, якты, шатлыклы! Бар бит дөньяда гүзәллек! Күзләр. Алардан мәхәббәт сибелә... Яшел куак, яфраклар аркылы узган кояш яктысыннан аз гына чагылып кысылган коңгырт күзләр. Җирдә мөмкин булган иң матур сүзне әйтергә ымсынган ягымлы юка иреннәр. Мин ярата торган озынчарак йөз. Күкрәкләренә төшкән, игътибар итterә торган, күзләре төсле үк коңгырт толым. Агыйдел кызы! Менә син нинди! Яфраклар арасында үзең сөялгән шомырт белән, куак белән, әрәмә белән, Агыйдел белән бербөтенлек хасил итеп басып торасың син.*

Шул эзлеклелек белән Әнис кичерешләре һәм табигать күренешләре арасындагы янәшәлек карап чыгыла. Учакның, җырның мәхәббәт хисләрен гәүдәләндерүенә дә игътибар бирү кирәк.

Дәрестә шулай ук, Әниснең соңлап аңлаган хаталарын таныган урыннары бар. Ул аның яшьлек тәҗрибәсезлеге икәнен белә, башкалар шундый хата ясамасын өчен искәртә. Әсәрдәге шул өлешләрне укучылардан таптыру һәм бәя бирү, нәтиҗә ясау кирәк. Иң элек ул үзендә игътибарсызлык, аралашу осталыгы җитмәүне таный:

*— Агач җитте инде. Бүтән кисмәскә була. — Мин кискән агачларны син дә ташыдыңмы? — дидем мин, моңарчы аны күрмәвемә гаҗәпләнеп. — Әйе. Шулай диде кыз. «Син бит агачларны гына күрәсең, ә кешеләрне — юк» дип өстәргә тиеш булган, ахрысы, ул, тик әйтмәде.*

Икенче очрак аның иң зур ялгышы, тормышын икенче юлга керткән хатасы, беренче мәхәббәтен югалтуының сәбәбе. Ул аны Фәһимә сүзләре аша бәяли. (*Син үзең өчен изге дип саналырга тиеш әйберләрне белмисең, аларны кадерли белмисең... Син беркайчан да яңадан табылмаячак иң зур нәрсәләреңне югалтырсың, дип куркам мин. Син бернәрсәнең дә кадерен белмисең. Кадерен», — дияргә теләгәндер Фәһимә ул минутларда (Б. 52—53).*

Әниснең Фәһимә белән булган бу сөйләшүен тулысынча укып анализлау әсәрне өйрәнүне тормышка якынайтырга, укучыларга тәрбия бирү чарасы буларак та файдаланылырга тиеш.

8, 9 нчы сораулар сыйныфта әңгәмә өчен.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**
Дәреслектәге 1 — 4 нче һәм 7 нче сорауларга җавап табу.

**VI. Өй эше бирү.**
Әсәрнең эчтәлеген кыскача сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**
1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Күңеленә сандугач керсә... (Лирик әсәрләрдә пейзажның үзенчәлеге: Нури Арслановның «Яз» шигыре).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — дөньяны танып белү чарасы буларак, тел һәм уку культурасына ия булу; матурлыкка мәхәббәт уяну, табигатьне тоя, җан аша үткәрә алу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, чишү юлларын билгеләү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү; фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү, аралашу шартларына һәм максатларына бәйле рәвештә эмоцияләрне белдерү.

*Предмет нәтиҗәләр* — шигъри әсәрдә пейзажның ролен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 58—60.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**
Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**
1. Өй эше тикшерелә.

2. Укучыларның пейзаж лирикасы белән таныш булуларына нигезләнеп, әңгәмә үткәрелә. Аңа хас билгеләр искә төшерелә. *Шигърият тә пейзажны сурәтләү объекты итеп куллана, бу очракта пейзаж нинди вазифа үти икән?*

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Сорауга җавап табу Нури Арслановның «Яз» шигыре белән танышудан башлана. Шигырьне сыйныфта башта укытучы үзе, яки сәнгатьле уку үрнәге күрсәтерлек укучы укый, тагын берничә укучыдан укытырга һәм һәр укучыга эчтән генә үзенә укып чыгу мөмкинлеге бирергә кирәк.

Алга таба шигырьне ике өлешкә бүләргә тәкъдим ителә. Укучылар ни өчен шулай бүлүләрен аңлаталар. Беренче өлештә табигать тасвирлана, икенче өлештә — лирик геройның хисләре.

*Лирик герой күңелендәге нинди хисләр белән уртаклаша?* (Ул гашыйк, шул сәбәпле борчуларга күңелендә урын юк, ул хәятның (тормышның) тәмен тоя, аны җаны-тәне белән сөя.)

*Шагыйрь нәрсә әйтергә тели, шигырьдәге төп фикер нидән гыйбарәт?* (Гашыйк хәлендәге кеше тормышны ярата, дөньяны матур итеп күрә.)

Шигырьнең максаты табигать матурлыгын сөйләү генә түгел, ә табигатьне гашыйк кеше күзлегеннән карап тасвирлау буларак аңлашыла. Лирик герой күңеле мәхәббәт белән тулган, аның өчен бөтен дөнья матур.

*Шигырьне укыганда, сездә нинди хисләр уянды?* (Анда тасвирланган матурлык күз алдына килә, шул матурлык эчендә аны тоя, аннан ләззәтләнә алучы, тормышыннан канәгатьлек кичерүче лирик геройны тоясың, үзеңне дә шул матурлык алдында хис итәсең. Күңел матурлык һәм җиңеллек белән тула.)

Шигырьне тагын бер тапкыр ярым тавыш белән укып чыгарга вакыт бирелә.

Шигырьдәге образлылык анализлана. Пейзажның төре билгеләнә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектәге сорауларга нигезләнеп оештыру мөмкин.

Бу дәрестә әдәби әсәрдә сәнгати алым буларак пейзаж кулланылышы темасы йомгаклап куела. Дәреслектәге нәтиҗә ясау өчен бирелгән сорауга һәр укучы җавап бирә алырга тиеш.

**VI. Өй эше бирү.**

Нури Арслановның «Яз» шигырен сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Сәнгати алым буларак әдәби әсәрләрдә портрет бирелеше.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әйләнә-тирәдәге һәрнәрсәгә дә, кешеләргә дә игътибарлы һәм күзәтүчән булу, күргәннәргә нигезләнеп, нәтиҗә ясау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, контекстны исәпкә алу һәм уку мәсьәләсен чишү барышында килеп чыгарга мөмкин кыенлыкларны алдан күрү, чишелешне үзгәрүчән шартларга яраклаштыру; төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру; үз фикерләрен әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — әдәби әсәрдә, сәнгати алым буларак, портрет бирелешенең вазифасын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 61—98.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Укучыларга фоторәсем (портрет), рәссам ясаган портрет, әдәби әсәрдән портретны сурәтләгән өзек тәкъдим итәргә һәм аларны нәрсә берләштерүен ачыклау аша яңа темага чыгарга мөмкин. Укучылар бу дәрестә әдәби әсәрдә портрет турында сөйләшәчәкләрен әйтәләр.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы тулысынча тәкъдим ителеп, максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

*Нәрсә соң ул портрет?* дигән сорау куелып, укучыларның җаваплары тыңлана. Бу очракта рус әдәбияты һәм рәсем сәнгате дәресләреннән алган белемнәре дә ярдәмгә килә.

Иң гади аңлатма түбәндәгечә була ала: портрет — кешенең беренче карашка ук күренә торган тышкы кыяфәте. Латин теленнән алынган сүз, нигезендә *өскә калкыту, табып алу, ачып бирү* (извлекать на поверхность, обнаруживать, выявлять*)* фигыльләре ята. Димәк, портрет нәрсәнедер ачып бирә, аңлата икән.

*Портреттан нәрсәне аңларга, аның ярдәмендә нәрсәне ачыкларга була дип уйлыйсыз?* Үз фикерләрен дәрес башында тәкъдим ителгән портретларга нигезләнеп әйтә алалар. Укучыларның җаваплары тыңлана.

Алга таба дәреслек материалына нигезләнеп, сәнгати алым буларак әдәби әсәрләрдә портрет бирелеше турында сөйләшүгә күчелә. Әдәби әсәрләрдән алынган өзекләр белән үреп алып барганда, укучылар белән бергә эшләргә һәм теманы аларның үзләреннән ачтырырга була. Ахырдан бергәләп нәтиҗә ясала. Портретның төрләре һәм әсәрдәге вазифасы билгеләнә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Нәрсә ул портрет?*

*Әдәби әсәрдә герой портреты укучыга ничек җиткерелә?* (Бер урында тәфсилләп сөйләнә, яки кабат-кабат кайтып, төрле урында тулыландырыла. Мәсәлән, Ф. Әмирханның «Хәят» әсәрендә автор Хәят портретына кабат-кабат кайта.)

*Әдәби әсәрләрдә портретның нинди төрләре бар?*

*Автор нинди максат белән укучының игътибарын геройның портретына юнәлтә?* кебек сораулар ярдәм итәр.

**VI. Өй эше бирү.**

Н. Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәренең дәреслектән 61—76 нчы битләрен укырга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Тарихи әсәрләрдә портрет бирү үзенчәлеге.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — халкыбызның үткәненә хөрмәт белән карау, туган җирне саклау һәркемнең изге бурычы икәнен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — әсәрне тарихи роман буларак анализлый белү, геройларга бәя бирү, тарихи әсәрдә портрет тудыру үзенчәлеген аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 61—98.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Әдәби әсәрдә портрет темасы буенча беренче дәрес материалы искә төшерелә. *Портрет геройны кайсы яклардан характерлый?* дигән сорауга җавап бирелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы тулысынча тәкъдим ителеп, максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

*Иң элек, нинди әсәр тарихи әсәр дип бәяләнә алыр?* Укучыларның фикерләре тыңлана. Дәреслекнең 76 нчы битендәге тарихи роман төшенчәсен укып укытучы тулыландыра, шәрехләп аңлата. *Н. Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәрен тарихи роман дип бәяли алырбызмы*? Әлеге сорауга җавап бирү өчен әсәрдән дәлилләр эзлибез. «Итил суы ака торур» әсәрендә тарихи вакыйга — Болгар дәүләте оешу һәм ислам дине кабул ителү үзәктә тора. Бу — булган хәл. Автор шуңа бәйле Алмыш хан образын бирә, бу чорга хас тарихи чынбарлыкны торгызу омтылышы ясый. Романда төрки кабиләләр белән бәйле йолалар, шул чорда кулланылган тарихи сүзләр күпләп урын ала. Әлбәттә, әсәр документаль вакыйгаларга гына нигезләнә алмый, автор, булган тарихи чыганакларга таянып, романда аларны үз фантазиясендә туган вакыйгалар, образлар белән баета. Шуңа күрә әсәрне тарихи роман жанрына карый дип әйтә алабыз. Әсәрнең укылган өлешендә әлеге фикерләрне дәлилләрлек мисалларны укучылар үзләре табып анализлап баралар.

Чор һәм аңа тәңгәл әдәби геройларны гәүдәләндерү язучыдан тарихи материалны өйрәнүне таләп итә.

«Итил суы ака торур» әсәрендәге төп образларны шул яктан тикшерәбез. Портрет тудыру өчен, геройның эш-гамәлләре, тарихи вакыйгалардагы урыны, авторның бу геройга

мөнәсәбәте, аның аша укучыга җиткереләсе фикер әһәмиятле роль уйный.

*Ничек уйлыйсыз, кешенең тышкы кыяфәте аның эчке кичерешләре белән бәйлеме?* дигән сорау куела. Җаваплар төрле булырга мөмкин. Реаль тормышта хисләрен бик эчкә яшерүче, аны тышка чыгармаска тырышучы кешеләр дә бар. Ләкин әдәби әсәрдә портрет сурәтләнеше героенең эчке халәтен чагылдыруның бер чарасы санала. Портрет геройны төрле яклап ача. *Тарихи әсәрдә портрет бирелешендә нинди үзенчәлек булыр дип уйлыйсыз?* (Тарихи әсәрдә тарихи шәхесләр мөмкин кадәр реаль гәүдәләндерелә, әгәр инде бик борынгы чор сурәтләнсә, реаль портрет бирү мөмкин булмаса, герой портреты аның эш-гамәлләре, тарихтагы урыныннан чыгып сурәтләнә.)

*Н. Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәрендә геройларның портреты белән аларның эчке кичерешләре арасында тәңгәллек бармы?*

(Әйтик, Тотыш. Ул — Күрән бинең улы, әмма әсир (тотык) итеп алынган кол кыздан туган бала. Автор аны шул үзенчәлегеннән чыгып тасвирлый. Холкындагы сыйфатлары, эчке каршылыгы, күңел кичерешләре аның портретында да чагылыш таба.)

*Капкада би углы Тотыш күренде. Атасы кебек ул таза, эре сөякле иде. Тик аңа караганда ул буйга тәбәнәгрәк, иңбашка киңрәк. Борын асты әле аның яңа гына караеп (каралып) килә. Бүгенге көндә караңгы чырайлы булу язык (гөнаһ) саналса да, алсу иреннәре кысылган, матур кара кашлары җыерылган. Җылый-җылый күз төпләре кызарып беткән. Ул кайгылы, ул ачулы, ул ярсулы иде. Сул кулына яшел төстәге язгы йолык байрагын тоткан, уң кулына үзенең сөеклесен — Йолдыз-кашканы җитәкләгән. Бүген ул туй башчысы санала. Аксакаллар кебек, ул да бүген баштанаяк актан киенгән. Биленә аның көмеш аеллы киң каеш буылган, муенына көмеш чылбыр белән ыруның сакчысы — кечкенә алтын бүре башы тагылган.*

Әлеге өзектә Тотышның портретын шул чор йола гадәтләре, киеме, киемнең өстәмә атрибутлары да тулыландыра. Тарихи портрет физик сыйфатлар, йөз-тән төзелеше белән

генә түгел, чорга хас кием-салым, бизәнү әйберләре, корал һәм башка нәрсәләр белән дә баетыла.

Әсәрдә Утташ кам, Койтым бикә, Алмыш хан, Алмыш хан батырларының портретлары бирелгән өзекләр укып, аларның әсәрдәге урыны, авторның аларга салган мәгънә йөге белән янәшә куеп бәяләнә. Әйтик, кол дәрәҗәсеннән бикәгә, соңрак бөтен ыру белән идарәне үз кулына алган илбашы булган Койтым бикәнең портретын автор көчле шәхес буларак гәүдәләндерә.

*Әсәрдә автор кемнәрнең портретын бирүгә игътибар иткән?* (Тотыш, Күрән би, Алмыш хан, Алмыш ханның батырлары (Чәкән алпагыт, Будрач сукман, Корыч-Тимер). Шулай ук Утташ кам, Ямгырчы бине тасвирлаган урыннар бар.) Алмыш ханның тарихи шәхес булуы ассызыклана. (Алмыш хан турында мәгълүматны укучылар үзләре дә тулыландыра алалар (дәреслектәге биремне үтәп килделәр).

Әсәрдәге төп вакыйгаларда катнашкан геройларны телгә алып, алар белән бәйле вакыйгалар һәм бу геройларның әсәрдәге роле билгеләнә. Нәтиҗә ясала: автор әсәрдәге төп геройларның портретын бирүгә күбрәк игътибар итә.

Портрет бирелешен төп ике вакыйга (Йолык туе, Алмыш ханның калан сорап яу белән килүе) ярдәмендә ачу мөмкин.

Күрән би белән Утташ кам әңгәмәсендә аларны авторның ничек сурәтләвенә нигезләнеп, әсәрдә портрет бирелешенең геройның эчке дөньясын ачудагы роленә, портрет тудыруда язучы кулланган чараларга игътибар ителә. Әлеге өзекне алып, тәфсилле анализ ясарга мөмкин. Анализ вакытында тарихи әсәрдә портрет тудыру үзенчәлегенә (шул чор кешесенең киемнәре, йолага мөнәсәбәтле хисләре, һ.б), образлылыкка игътибар бирү сорала. Тарихи герой шул чор мохитен тулыландыра һәм тарихи җирлектә бирелә.

*— Эш чыкты, би... кияү! — дип кычкырды ул, чәрелдек тавыш белән. — Ниндидер явызлар изге наратны... бөтен ыругның изге сакчысын, яклаучысын мыскыллаганнар! Тәүбә! Тәүбә! Изге аланны бозганнар, би! Изге Кайраккайның йөзенә төкергәннәр! Тәүбә! Тәүбә!*

*— Кемнәр?! Кайчан?! — диде би, коты алынып.*

*— Кемнәр, имеш! — дип чәрелдәде Утташ кам, күз яшьләренә буылып, бизгәк тоткандагы сыман калтыранып. — Килмешәк Койтым кырнакның (кол хатын-кыз) игелексез Тотышыннан башка кемнең шуңа кулы барсын?!*

*Би ап-ак булды. Шуннан соң ул бурлаттай кызарынды, еш-еш тын алып, йокысы качып бетмәгән усал күзләреннән куркыныч очкыннар чәчрәтеп, урыныннан торды да җөнтәс шәрә кулын ашыкмыйча гына алга сузды, бабасының сакалыннан учлап тотты.*

*— Аңлатыбрак сөйлә! — диде ул.*

*Өлкән камның тары бөртегедәй елтыр күзләре чәчрәп чыгардай булып акаеп калды. Кайнарлыгы, ачуы-ярсуы шундук юкка чыкты, бөтен явызлыгы, бергә җыелып, кинәт каядыр эчкә төшеп китте. Теле томлыгып, беравык эндәшә алмый торгач, ул этенә-төртенә:*

*— Б-б-бүген иртән б-б-барсам... — диде.*

Шулай ук Тотышның Алмыш хан белән булган көрәшендә һәр сугышчының портреты сурәтләнгән өлешне дә аерым тикшерү теманы тирәнтен үзләштерергә ярдәм итә.

Әсәрдәге портрет бирелеше геройның рухи халәте, социаль хәле белән турыдан-туры бәйләнешле була.

**Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Тарихи әсәр, тарихи герой портретын тудыруда нинди үзенчәлекләр күзәтелүен искә төшерергә. әсәрдә бирелгән геройларның тарихи чор белән бәйләнешен ачарга ярдәм иткән сораулар белән үтелгән тема ныгытыла.

**VI. Өй эше бирү.**

Н. Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәрен укып бетерергә. Дәреслектә 76 — 91 (98) нче битләр

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Бердәмлекне җиңәрлек көч юк (Нурихан Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәренең идея-проблематикасы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — гражданлык бурычларын үтәүгә һәм хокукларын гамәлгә ашыруга әзер булу; бер-

дәмлекнең зур көч икәнлеген аңлау, шәхси максатларны ил, халык таләбеннән өстен куймаска өйрәнү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — яңа шартлар һәм үзгәрешле ситуацияләр, билгеләнгән хаталар, килеп чыккан кыенлыклар нигезендә эшчәнлеккә төзәтмәләр кертү, нәтиҗәнең максат һәм шартларга туры килүен бәяләү, уку мәсьәләсен куя белү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау; уку диалогы барышында фикер алышуда төп тема буенча сораулар бирү.

*Предмет нәтиҗәләр* — романның эчтәлеген белү, идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 61—98.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *Тарихи әсәрнең әһәмияте нәрсәдә?* дигән сорауны ачыклау дәрескә кызыксыну уятырга ярдәм итә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Укылган өзеккә нигезләнеп, вакыйгалар хәтергә төшерелә, аларның әсәрдәге вазифасы билгеләнә:

Яз килә — кешеләр күңеленә яңа өметләр уята.

Йолык туе — күңелдәге өметләрне тормышка ашыру өчен җирлек, йола үтәү — яшәү рәвеше, ышанулар, эчке тәртипләрне ача.

Ямгырчы би килү — кабиләләр арасындагы тарихи бәйләнешләр, берләшүгә омтылыш ясау һ.б.

Алмыш хан гаскәре килү — таркаулыкның нәтиҗәсен, Алмышның гаделлек саклавын (көче булса да, башта ук яу белән басып керми, Күрән би ягы куйган шартларга риза була, Тотышны үтерергә мөмкинлек бирми, гомерен саклап кала, калан түләгән очракта тынычлык белән китә) күрсәтә.

Алмыш хан турында сөйләшү үткәргәндә, аның үз гаскәренең көченә ышануы, әмма явызлыкны йөгәнли белүен дә искә алырга кирәк. Тотышны үтерергә юл куймавы да тирән мәгънәгә ия: ул батырлыкны үтерүче түгел. Ул батырларны хуплый, үз янына туплый.

Татар телендә белем алучы мәктәпләр белән Алмыш хан һәм Тотыш арасында бердәмлек турындагы әңгәмәсе дә анализлана. Аның бердәм дәүләт булдыру теләге һәм бу дәүләтне нык итүче бердәм идея (ислам дине) булырга тиешлеген дә күрүе бәяләнә.

*Итил-Чулманга йөзләгән, меңләгән елга, инеш коя. Ул елгаларның, инешләрнең күбесе тавык атлап чыгарлык сай гына, тар гына. Аерым-аерым аксалар, алар беркайчан да диңгезгә барып җитә алмаячаклар: корып-кибеп бетәчәкләр. Бөек Итил аларның барысын бергә җыйган. Шуңа күрә дә ул көчле, куәтле. Аны җиңә алырлык бернинди көч юк дөньяда! Итил-Чулман буендагы вак ырулар да, бергә кушылып, Болгар тирәсенә тупланып, менә шундый көчкә ия булырга тиешләр.* Бу өзекне укучылар табып укый.

Әсәр исеменә игътибар итеп, Итил-Иделнең борынгы бабаларыбыз җире булуын, әсәрдә шул тормыш бөтен каршылыклары белән гәүдәләнеш алуы ассызыклана.

Ни өчен әсәрнең исеменә Итил исеменең чыгарылуы да дәллилләнә.

Итил ваграк елга-инешләрне үзенә җыя, шул рәвешле бердәм дәүләт, бердәмлек символы булып килә.

Итил елгасы мең еллар элек тә шулай тыныч кына аккан, хәзер дә шулай, халык та шулай тынычлыгын, бөеклеген саклаcа, мәңге яшәячәк.

Итил сулары аккан кебек, вакыт та туктамый ага, гасырларны гасырлар алыштыра.

Итил елгасы кыя (каршылык) төбен кагып торган кебек, халыкларның ирекка омтылышы да беркайчан туктамый. (Халык җыры белән беренче дәрестә танышканнар иде.)

Шулай ук Койтым бикәгә дә бәя бирелә, аның да шәхси мәнфәгатьләренә караганда ил, халык язмышы өчен ныграк уйлануы күрсәтелә. Баштарак анда үч алу тойгысы көчлерәк булса да, соңыннан ул акыл белән гамәл кыла. Алмыш белән туганлашырга ризалыгын бирә. Койтым бикәнең үз мәнфәгатьләреннән ыру-кабилә, халык теләген өстен күрүе ассызыклана.

Әсәрдәге вакыйгаларга нигезләнеп, бөек шәхесләрнең җәмгыятьтәге роле, ил башының халык белән бердәмлеге, кеше язмышы, аның бәхеткә хокукы, бердәмлекне саклап торырлык идеаллар берлеге, иман, кыйбла бер булу, туган җир, ата-ана, халык алдында бурычыңны үтәү кебек проблемаларга игътибар бирелә.

Әсәрдә чор мохитен тудырган йола, гореф-гадәтләр, хәтта яу күренешләрен дә тасвирлап, автор укучыга тәэсирлелеген арттыра. Реалистик һәм романтик сурәт чаралары, Тотышның мәхәббәт тарихы мавыктыргыч сюжет сызыгы тудыра. Тарихи чынбарлык һәм автор уйдырмасы булган вакыйгаларны укучылар белән барлап чыгу, аларның үзара керешеп, кабат торгызылган тарихи тормыш моделе тудырганлыгын ачыклый.

Тарихи әсәр үткәнне күзалларга, тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

Болгар ханлыгы оешу һәм ислам дине кабул ителү — тарихта булган реаль вакыйгалар. Романда халкыбыз тарафыннан гасырлар буе зурланган әхлакый кыйммәтләр урын ала: бердәмлек, татулык, гаделлек, кунакчыллык, рухи көч, ирек. Автор ата-аналар авторитетын сурәтли, гаилә башлыгы саналган ир-атларның гына дәүләт эшләренә катнаша алуын, җәмгыятьтә үз сүзен әйтү мөмкинлеген билгели. Шулай ук хатын-кызның дәрәҗәсен күрсәтә. Ырулар үзара тату, дус, бердәм булып яшәргә тиеш дип раслана, шул очракта алар көчле булачак, дошманга каршы тора алачак. Дошманга баш имәгән, рухи ирекен саклап кала алган ырулар данлана, моны автор казаяк һәм акбүре ырулары мисалында күрсәтә:

болгарларга буйсынып калган казаяклар, дошман хакимлегеннән качып китеп, үзбаш яшәп яткан акбүреләрне үзләреннән өстен күрә, алардан таяныч эзли. Романда ил, халык мәнфәгатьләре һәрвакыт алга куела, кешеләр ил азатлыгы өчен гомерләрен дә кызганмаска тиеш, дигән фикер үткәрелә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектәге 1, 2 нче сорауларга җавап бирелә.

Романның идеясе кабат искә төшерелә, нигезләнә. Тарихи әсәрләрдә портрет сурәтләүнең үзенчәлеге һәм нинди максаттан файдаланылуы ачыклана.

**VI. Өй эше бирү.**

Алмыш ханга яки Тотышка характеристика язарга.

Алмыш хан һәм Тотышка чагыштырма характеристика язарга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Хисләр һәм акыл каршылыгы (Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендә психологик портрет тудыру үзенчәлеге).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрләрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянып эш итү; һәр эшне уйлап, нәтиҗәсен күзаллап эшләргә өйрәнү; холкыңның начар сыйфатларын үзгәртә белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, әдәби геройларның үзара мөнәсәбәтләре турында уйланып, башка кешегә, аның фикеренә аңлы рәвештә карау, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү; әңгәмәдә катнашу, аралашу шартларына һәм максатларына бәйле рәвештә эмоцияләрне белдерү.

*Предмет нәтиҗәләр* — әсәрнең эчтәлеген белү, геройларга бәя бирү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 99—121.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *Геройның тышкы сыйфатларын тасвирламаган сурәтләү портрет дип атала аламы?* Укучылар портрет-кичереш һәм психологик портретны атаячаклар. Портрет-кичереш һәм психологик портрет төшенчәләре ачыклап үтелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әсәрдән 101—102 нче битләрдән («*Атын күргәнмен, арбасын күргәнмен, алмасын күргәнмен...*» дигән җөмлә белән башлап, «*Ә теге алма һаман кулымда*» дип тәмамланган) өзекне укырга мөмкин.

*Укылган өзектә алма сатучының кызы турында кем тасвирлап бирә? Әгәр аның турында Госман сөйләсә, ул башкачарак тасвирлый алыр идеме?* (Әйе, һәркем кешене үзе күргән, күрергә теләгән якларына игътибар итә, шулай тасвирлап та бирә.)

Алга таба әсәрдә сюжет корылышына игътибар итеп, вакыйгаларның Айдарның истәлек дәфтәрендә тасвирланганлыгын билгелибез. Әсәрдә хикәяләүче дә Айдар икәнлеге һәм анда геройларга бирелгән бәя дә, аларның портреты да Айдар кичерешләре аша тапшырылганлыгы аңлашыла. Димәк, әсәрдә портрет-кичереш һәм психологик портретлар

урын алган. Айдарның истәлек дәфтәрен авторга биргән хәрби врач ханымның портреты автор тарафыннан тасвирлана. Тагын бер урында Вәсилә Ниса түти сурәтләвендә бирелә:

*— Чәчен тарап утыра, чәче биленә төшкән... Хатны укыгач, бөтенләй аптырап калды, чәчен дә үрмәкче була, хат та язасы бар. Ишекле-түрле йөгереп йөри кызың. Ә үзенең биле сыгылып тора, буе-сыны коеп куйган төсле. Кашау килешә икән тагын үзенә: ике бите алма төсле булып кызарды. Күтәрелеп карамый да үзе, шулай да күреп торам: сөрмәле күзләреннән дәрт ява.*

*Әсәрдә Айдар, төрле вакыйгаларны сөйләгәндә, кемнәрнең портретын сурәтли?* (Алма сатучының, Вәсиләнең, Госманның, үзенең һәм Мамалай авылы егетләренең (чишмә буендагы очрашуда.))

Шул эзлеклелектә әлеге геройларга Айдарның мөнәсәбәтен, Айдар белән аларны нәрсә бәйләвен ачыклап, портрет бирелеше дә бәяләп барыла.

Моның өчен «Йөзек кашы» әсәрендәге вакыйгаларны эзлекле рәвештә хәтергә төшерү кирәк.

Айдар Вәсилә портретын берничә урында бирә. Әсәр башында ул аны шактый тәфсилләп сурәтли. Соңрак Сабантуйда, ул шахтадан кайткач, чишмә буенда күрешүләре, Вәсилә кияүгә чыгар алдыннан, Вәсиләне урлап киткән туй көнендә.

Алга таба Айдар һәм Вәсилә мөнәсәбәтләренә игътибар ителә. Алар арасындагы эчкерсез матур мәхәббәт тарихы күңелсез тәмамлана.

*Вәсилә белән Айдарның бәхетсезлегендә кем гаепле?* Укучыларның җаваплары тыңлана. Күпчелек Госманның гаебен билгеләсә, Айдарның да ялгышларын күрсәтәчәкләр.

*Айдарның ялгышы нәрсәдә?* Укучыларның җаваплары тыңлана, нәтиҗә ясала.

Сюжет сызыгы буенча барып, Айдарның гамәлләрен тикшерү, шуның аша укучыларга тәрбия бирү максатына килено. Уйламый эшләү, акыл белән түгел, хисләр белән генә яшәү, җаваплылык хисен югалту, үзең турында гына уйлау кешенең язмышын җимерә. Иң аянычлысы: мондый холыклы кешеләр янәшәсендәгеләрне дә бәхетсез итә.

Әйе, Айдар гаделсезлекләрне усаллык белән җиңәргә тырыша. Аңа начарлык эшләүчеләр кебек үк гаделсезлек эшли. Кыйный, сугыша, Госманның да битенә камчы белән суга. Туй вакытында да тәрәзә вата, Вәсилә белән аңлашуны да кирәк тапмый. Бернәрсә аңлатмыйча Вәсиләне ялгыз калдырып чыгып китә. Айдарның иң зур хатасы — эшләгәнче уйламый, бу — аның холкы. Ул хаталарын таный, әмма нәтиҗә ясамый.

Айдар чиста күңелле, ул Госманның күңелендә йөргән көнчелек һәм явызлыкны да күрми. Аны авылдашы һәм балачак дусты дип саный.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслекнең 121 нче битендәге 1, 2, 5 нче сорауларны файдаланырга була.

**VI. Өй эше бирү.**

Айдарга хат яки бәяләмә язарга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Рухи халәтнең тышкы чагылышы нинди? (Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендә чагыштырма портрет бирелеше).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — үз-үзеңне тоту һәм гамәлләреңне, шулай ук башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышы һәм гамәлләрен аларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, әхлакый һәм хокукый нормалар позициясеннән бәяләргә әзер булу; авырлыкларны җиңеп чыга алырлык көчле ихтыярлы, кешеләргә һәм илгә файдалы шәхес булу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру; әңгәмәдә катнашу, фикерләрне кабул итү һәм

тәгъбирләү, аралашу шартларына һәм максатларына бәйле рәвештә эмоцияләрне белдерү.

*Предмет нәтиҗәләр* — әсәрнең идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 99 –121.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *Кеше күңеле карарман, — ди халык. Бу гыйбарәнең мәгънәсен ничек аңларга? Кешенең эчке дөньясы бик катлаулы, аны аңлап, бәяләп бетереп булмый. Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендәге кайсы геройларның күңел пәрдәсен күтәреп карарга теләр идегез?* сорауларына укучыларның җавабы тыңлана.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алдагы дәрестә Айдар турында сөйләшенгәнлектән, бу дәрестә Госман һәм Вәсилә образларына тукталына. Геройларның күңел дөньясы алар кылган гамәлләр аша бәяләнә.

*Айдар Госман турында нәрсәләр сөйли?*

Укчыларның җаваплары тыңлана.

Айдар Госманны укучыга балачак дусты буларак таныштыра. Айдар белән Госман балачактан дуслар, авылдашлар. Алар әсәрдә алма сатучы килгәндә дә, Мамалай авылындагы җыенда да, Айдарга Вәсиләне урлаганда да бергә.

*Госман нинди гамәлләр кыла соң?*

Алда әйтелгән өч вакыйгада да Госман Айдарга әшәкелек эшли. Алма сатучының кызы Айдарга алма ыргтуын кире

кага, Мамалайда ат чабыштырганда Айдарның атына суга, кыз урлаганда Вәсиләнең йөзеген урлап, аны Айдарга тугры булмауда гаепли, аларның бәхетен җимерә.

*Госманның күңелендә ниләр яшеренгән соң?*

Госман — көнчел. Бу аның бала вакытында ук чагыла (Алма сатучының кызы алманы сиңа ташламады ди, Айдар сорагач та, Мамалайга туганы Ниса түтиләргә барырга ризалашмый һ.б.): үч саклый, кырыс, дуслыкка хыянәт итә, нахак яла яга, кешеләрнең бәхетсезлегеннән тәм таба.

Айдар белән Госманның соңгы очрашуы сугыш кырында була. Госман гомерен саклап калу максатыннан, дошман алдында тез чүгә, бирелүен белдерә. Айдар бу түбәнлекне күтәрә алмый, аның аяк астына гранатасын ыргыта, Госман шул граната шартлаудан һәлак була. Язучы, дуслыкка хыянәт иткән — иленә дә хыянәт итә, дип раслый.

Госман күңелендә явызлык туплаган, кара эчле герой буларак ачыла.

Айдар тормышта күп хаталар, начар гамәлләр эшли. Айдар — гадел, тәвәккәл, кызу канлы, уйламыйча эшләп ташлый, акылы арттан йөри, беркатлылык та бар, эш сөя, куйган максатына ирешү өчен, авырлыклар алдында югалып калмый, вәгъдәсендә тора.

Бу өлештә дәреслектәге 10 нчы сорау нигезендә фикер алышу үткәрелә.

*Айдар белән Госман образына әсәрдә күп урын бирелгән, ә Вәсилә турында нинди фикергә килеп була?* Аның эчкерсез, нык ихтыярлы, тәвәккәл, мәхәббәтенә тугры икәнлеген дәлилләргә мөмкин. Айдар калдырып киткәч, аның тормышы нинди юнәлеш алганлыгын автор искәрмәсенә нигезләнеп аңларга мөмкин. Укучыларга шул өлешкә кабат кайтып, Вәсиләнең хәрби врач булганлыгын аңлауларына ирешү кирәк. Укытучы дәреслеккә кермәгән өлешне дә укучыларга тәкъдим итә. Автор белән әңгәмәсендә Вәсилә мондый фикер әйтә:

*«Айдардан аерылып калуым белән мин баштанаяк бәхетсез идем һәм шул бәхетсез көйгә, бүтән кешеләрдән калышмыйча, атлап килдем. Җиңел булды дип уйлыйсызмы? Һич түгел. Яисә менә еллар буена эзләп йөреп тә, соңыннан аның турында шушы дәфтәрдән башканы таба алмау*

*җиңел дип уйлыйсызмы? Әгәр шулай уйласагыз, нык ялгышасыз. Шәхси бәхетсезлек булды, бар, киләчәктә дә булыр. Мәсьәлә анда түгел, мәсьәлә — әнә шул аерым бәхетсезлекләрне ерып чыга алуда, үзеңдә шуларны ерып чыга алырлык көч, ихтыяр булдыруда. Бәхет — әнә шул ул*».

Әлегә өзек укучыларга үзләрендә дә ихтыяр көче булдырырга, авырлыклар алдында югалып калмаска өйрәнергә этәргеч булырга, шәхес тәрбияләргә ярдәм итә.

Әсәрнең ни өчен «Йөзек кашы» дип аталуын укучылар үзләре аңлатып бирә. Укытучы йөзек кашының мәгънәсен тирәнәйтеп, нәтиҗә ясый.

Йөзек — хатын-кызның зиннәте. Госман шул зиннәтне, үзенә сиздермичә генә, Вәсиләнең кулыннан салдырып ала. Ул аның йөзеген генә түгел, кыз балага хас булган сафлыгына кул суза.

Әсәрдә сурәтләнгән портрет-чагыштыруларның геройның рухи дөньясын ачуда ничек ярдәм итүе мисаллар ярдәмендә анализлана.

Пейзаж бирелешен дә күзәтеп, аның әсәрдәге ролен ачыклап китү дә урынлы булыр.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслекнең 121 нче битендәге 4, 7, 8, 9 нчы сорауларга җаваплар тыңлана.

**VI. Өй эше бирү.**

Фатих Хөсни иҗаты турында зур булмаган чыгыш әзерләргә яки Айдар һәм Госманга чагыштырма бәя бирергә (язма рәвештә).

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Үзе уңган, үзе тыйнак — татар кызы (Шәмсия Җиһангированың «Татар кызы» шигырендә милли портрет бирелеше).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — милли тәңгәллек тойгысына ия булу, үз милләтеңә хөрмәт саклау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — лирик әсәрдә портрет бирү үзенчәлеген аңлау, шигырьне анализлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 122.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *Татар кызына (гомумән татар халкына) хас нинди матур сыйфатларны әйтә аласыз?*

*Татар кызының портретын ничек ясар идегез? Телдән тасвирлап бирегез.*

Укучыларның җаваплары тыңлана.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы әңгәмәгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Шигырь сыйныфта укыла. *Шигырьдә портрет сурәтләнгәнме? Кемне сурәтли? Ул аерым кызның портретымы?* Шигырьдә татар кызының гомуми портреты икәнлеге аңлашыла.

*Гомумиләштерелгән портрет ничек туа?* Бу вакытта төрле рәссамнарның татар кызын гәүдәләндергән картиналарындагы уртак сыйфатларны табып, гомумиләштерелгән

нәтиҗә ясарга була. Тормышта да тышкы билгеләренә карап, аның нинди милләттән икәнен билгеләү мөмкин. Димәк, һәр милләт вәкиленең гомуми, шул милләткә хас матур, аны бизи торган сыйфатлары бар.





Рәссам, график, театр декораторы, педагог Павел Беньковның «Татар кызы» («Мәхкүм кәләш») картинасы

Татар кызыларына хас билгеләрне гомумиләштереп биргән рәсем.

*Шәмсия Җиһангирова «Татар кызы» шигырендә татар халкына хас нинди матур сыйфатларны калку итеп бирә?* (Тышкы һәм эчке матурлык.)

Алга таба дәреслектәге сорауларга нигезләнеп, шигырьнең эчтәлеге, автор әйтергә теләгән төп фикер билгеләнә. Эчке һәм тышкы матурлыкның бердәмлеге кешене матурлый. Тыйнаклык, күңел сафлыгы, горурлык (үз бәһаңне белү, түбәнсенмәү) кебек сыйфатлар тышкы матурлык буларак та чагылыш таба.

Шигырь эчтәлегенә нигезләнеп тәрбия бирелә. Милли үзенчәлекләр, аларны саклауның әһәмияте турында әңгәмә үткәрү кирәк.

Татар кызының портретын тудыруда кулланылган чаралар барлана. Портрет тудыруда чагыштыруларның үзен-

чәлеге аңлатыла. Әйтик, толымнарны авыл юлы белән чагыштыру һ. б.

Кыскача Шәмсия Җиһангирова иҗаты белән таныштырыла.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Җыелма портрет тудыру өчен, автор халкыбызның нинди сыйфатларына игътибар иткән?*

Авторның татар кызына шәхси мөнәсәбәте чагылган шигырь юлларын табып укыгыз.

Татар кызының тышкы матурлыгын тасвирлау өчен кулланылган чагыштыруларны табыгыз.

**VI. Өй эше бирү.**

Ш. Җиһангированың «Татар кызы» шигырен ятларга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Кульъяулыгым — вәгъдә билгесе (Сәнгати алым буларак әдәби деталь, әйберләр дөньясы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — дөньяны танып белү чарасы буларак, тел һәм уку культурасына ия булу; игътибарлылык, күзәтүчәнлек, эчке тоемлау сыйфатлары арту.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, контекстны исәпкә алу һәм уку мәсьәләсен чишү барышында килеп чыгарга мөмкин кыенлыкларны алдан күрү, чишелешне үзгәрүчән шартларга яраклаштыру; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — әдәби әсәрләрдә деталь, әйберләр дөньясы төшенчәсен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Ка-

зан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 124—125.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2.







Әйтик, төрле рәсемнәр куеп, бу очракта өйнең эчке күренеше, һәр әйбернең аерым бер мәгълүмат бирүе ачыклана. Һәр рәсемне игътибар белән карап, укучылар нәтиҗә ясый, ни өчен бу нәтиҗәгә килүләрен дәлилләп бирә. Алар өй эчендәге әйберләргә нигезләнүләрен әйтәчәк. Әлеге рәсемнәрдән, мәсәлән, өйнең нинди максатта, кайсы чорда, кемгә хезмәт итүен, анда яшәүчеләрнең нәрсә белән шөгыльләнүен белергә мөмкин икәнлеген аңлашыла.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Әңгәмәгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әдәби әсәрләрдә дә төрле әйберләр тасвирлана, атап кителә, автор укучының игътибарын аерым әйберләргә ныграк юнәлтә. Әдәби әсәрдә аларның үз вазифасы була, аларга билгеле бер мәгънә салына. (*Дәреслек нигезендә укытучы теманы аңлата.*)

Әсәрләрдән алынган аерым өзекләрне укып, авторның нинди әйбергә игътибар итүе, аның нинди вазифа башкаруы карала.

Әдәби әсәрдә әйбер белдергән туры мәгънә үзгәреп, мәгънә йөге киңәергә һәм әйбер киңрәк күчерелмә мәгънә дә белдерергә мөмкин. Мәсәлән, кулъяулык, йөзек — вәгъдә билгесе.

Татар әдәбиятында яулык, төрле кошлар, чәчәк, гомумән, үсемлекләр, агачлар, йөзек, кош каурые, икмәк, хат һ. б еш кулланыла һәм күчерелмә мәгънә алып символга әйләнергә дә мөмкин.

Мәсәлән, Ф. Яруллиның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда Фәүрия Фәниярга менә ничек хат яза: «*Сез анда хәзер шәһәргә увольнениеләргә чыгып йөри башлагансыздыр. Кара аны, әгәр берәр кызга күз салсаң, барып, колагыңны борырмын. Читләргә күз атканыңны шунда ук беләчәкмен. Ничекме? Син бит миңа тылсымлы каурый калдырып киттең. Мин йолкышырга бармаган казның ап-ак каурыен. Ул матчада тора. Мин аңа һәркөн күз төшереп алам. Әлегә каурыең ак, тапсыз. Димәк, сагынасың, мине уйлыйсың. Әгәр мине сагынмасаң, ул каурый саргая башлаячак. Белеп тор.*» Кош каурые бу очракта мәхәббәт сафлыгын символлаштыра.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Әдәби әсәрдә автор ни өчен әйберләр дөньясына мөрәҗәгать итә?*

*Әсәрдә әйберләр, әдәби детальләр ярдәмендә нинди мәгълүматләр белдерергә мөмкин?*

*Татар әдәбиятында аерым мәгънә йөге булган еш кулланылыштагы нинди әйберләрне әйтә аласыз?*

**VI. Өй эше бирү.**

Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрен 141 нче биткә кадәр (*соңгы абзац керми*) укып килергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Йөрәк түрендәге хисләр (Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә әдәби деталь).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — дөньяны танып белү чарасы буларак, тел һәм уку культурасына ия булу; әниләргә мәхәббәт һәм хөрмәт төшенчәләренең асылын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, чишү юлларын билгеләү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — әсәрнең эчтәлеген белү, әсәрдә автор өстәмә мәгънә салган әйберне таба һәм аңлый белү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 126—142.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, ведеоролик (9 сыйныф, 7 нче дәрес)

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Беренче дәрестә Ә. Еникинең тормышы, иҗаты белән танышу һәм «Әйтелмәгән васыять» хикәясен өйрәнә башлау.

Укытучы Ә. Еники иҗаты белән таныштыра.

Әсәрнең укылган өлешенең эчтәлеге искә төшерелә. «Васыять» сүзенең мәгънәсен ачыклаудан башларга мөмкин.

*Васыять — берәүнең үләр алдыннан әйтеп калдырган теләге, үтенече, нәрсәне дә булса мирас итеп тапшыруы.*

Әсәр дала күренешен тасвирлау белән башланып китә. Бу өлешне укып, андагы детальләргә игътибар ителә (дала, кылганнар, җил, моңсулык).

*Акъәби, үзенең җилкапкасына җиткәч, туры читән алачыкка узды. Бу эчтән балчык белән сылаштырылган җир идәнле алачыкта аның барлы-юклы савыт-сабасы да тора, шунда аш-суы да пешә иде. Җирдән аз гына күтәртеп салынган, калай морҗасы туры гына кыектан чыгарылган учагы алдына карчык кизәкләрен бушатты. Казанына өч-дүрт чүмеч су салды да учагына күп кенә итеп чыбык-чабык сындырып тыкты, ут төртеп җибәрде. Чыбыклар күмерләнеп төшкәч, алар өстенә ипләп кенә кизәкләр өештереп куйды.*

*Бирелгән өзекне укыгач, Акъәбинең тормышын ничек күзалдына китерәбез? әдәби әсәрдәге нинди детальләр мондый нәтиҗәгә килергә ярдәм итә?*

Алга таба Акъәби һәм Миңлебай образларын автор ничек тәкъдим итүенә тукталына. *Акъәби кеше исеме микән? Әллә аның башка исеме дә булырга мөмкинме?*

Укучылар Акъәбинең шагыйрь белән сөйләшүен искә төшерә һәм өзекне сыйныфта укыйлар (*Бу өзек электрон китапта аудиоязмада бар.*)

Шагыйрь куйган сорауны укытучы кабатлый:

*Чыннан да, ә ни өчен Акъәби, ни өчен Кара әби түгел? Автор үзенең героена ни өчен шундый исем сайлаган? Ак төс нинди халәт тудыра, нәрсәне аңлата?*

Аклык — сафлык, чисталык, яктылык. Эчкерсез, ярдәмчел, чиста күңелле, игелекле кешеләрне ак күңелле диләр.

Акъәби белән балалары һәм Акъәби белән шагыйрь арасындагы аңлашуга игътибар ителә.

*Ни өчен бу аңлашу бер-берсеннән бик аерыла соң? Шагыйрь белән Акъәби нәрсә турында сөйләшәләр? Аларның фикер уртаклыгы нәрсәдә?* (Халыкның рухи мирасын саклау, кадерен белү кирәклеген аңлауда.)

*Балалары белән Акъәбинең мөнәсәбәте нинди?* (Алар әниләрен яраталар, хөрмәт итәләр, кадерлиләр, дәваларга тырышалар, әмма ана күңелен аңлау, рухи якынлык юк.)

Акъәбинең шәһәрдәге тормышы, кичерешләре турында сөйләшү үткәрелә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Акъәбинең рухи дөньясын тасвирлап бирегез. Укылган өлештән, аның туган җире белән бәйләнешен сурәтләгән урыннарны табып укыгыз.

(Акъәби — гадел хезмәт белән көн күргән, илгә хезмәт итәрлек уллар, кызлар үстергән, гадел, сабыр, кешелекле, гомере буе ак күңелле булып яшәгән карчык. Авылдашларының аңа игелекле мөнәсәбәте дә аның изге күңелле, яхшы кеше булуын күрсәтә. Акъәби туган җирнең кадерен белә, аны ата-бабалар җире буларак хөрмәтли, кадерли. Исәннәрне генә түгел, үлгәннәргә дә хөрмәт саклый. Динен, гореф-гадәтләрен саклый, балаларның да игелекеле, кече күңелле булуларын тели. Авырып киткәч тә, туган нигезен калдырасы килми. Шәһәрдә дә кош-кортларын уйлап ята, аларны сагына.)

*Акъәби балалары турында нәрсәләр уйлый?*

Ул балаларына һич үпкәсен белдерми, әмма кайбер гамәлләрен аңлап бетерергә теләми.

*Нинди гамәлләре белән килешә алмый? Шул урынны табып укыгыз.*

*Акъәбинең рухи дөньясын аңларга ярдәм иткән детальләрне табыгыз. Әсәр эчтәлеген аңларга ярдәм итә алырлык тагын нинди детальләр бар?* (Учак, дала, кылганнар, җил.)

*Аларга автор нинди мәгнә салган дип уйлыйсыз?*

(Ак яулык — Акъәбинең күңел сафлыгы, дала — мәңгелек яшәеш, җил — заман шукымы, вакыт агышы, даладагы җил

иркенә буйсынган кылганнар — Акъәбинең заман ыгы-зыгысына кереп, шул агымга буйсынган балалары.) *Беренче карашка бик тә тыныч, матур дала күренешендә ятып елыйсы килерлек моңсулык, ямансулык та бар. Нәрсәдән соң бу моңсулык?* Бу хакта алдагы дәрестә сөйләшүне дәвам итәрбез.

**VI. Өй эше бирү.**

Дәреслектән 142—156 нчы битләрне укырга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Хәситәме, камчымы?.. (Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә әйберләр дөньясының әсәр идеясен ачудагы роле).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган җир кадерен белү, милли гореф-гадәтләрне хөрмәт итү, ата-ана васыятен кабул итеп алу һәм тайпылышсыз үтәү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерләрен әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — әсәрдә күтәрелгән проблеманы һәм идеяне аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 128—156.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Укучыларның әсәрнең эчтәлеге белән таныш булуларына нигезләнеп сорау куела:

— *Акъәбинең васыяте зурмы? Аны үтәү мөмкинме?*

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар белән булган әңгәмәгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Бу дәрес Акъәбинең күңел кичерешләре, уйлануларын барлау юнәлешендәрәк булыр. Иң элек кыскача гына эчтәлектәге төп вакыйгаларны (Акъәбинең Миңлебай карт белән очрашуы, Акъәбинең авырып китүе, авылдашларының аны озатуы, Акъәби кызы Гөлбикә фатирында, Акъәби больницада, Акъәбине җирләү, Акъәбинең сандыгы килү) билгеләү сорала. Вакыйгаларны санап чыккач (аны план рәвешендә укучылар каршысына тактага куярга да мөмкин) һәр вакыйга тулырак итеп сөйләнә.

Бу вакыйгалар Акъәбинең хатирәләре белән тулыландырыла Килен булып төшүе, балалар үстерүе, аларны әтиләре белән бергәләп «Аслы күл» буена алып барулары, Балкан, Нора тауларын күрсәтүләре, мәктәпкә озатулары, аларны ничек шәһәргә озатулары, сагынып көтеп яшәүләре, бик-бик яраткан оныклары белән үз туган телендә сөйләшә алмаудан күңеле әрнүләре.

Әлеге хатирәләрне әсәрдән алынган өзекләр белән тулыландырып, тәрбияви нәтиҗәләр биреп бару кирәк.

Акъәбинең Миңлебай карт белән очрашуы, Акъәбинең авырып китүе, авылдашларының аны озатуы вакыйгалары авыл халкының үзара бердәмлеген, хәл белешеп, ярдәмләшеп, өлкәннәргә хөрмәт белән яшәвен күрсәтә. Автор Миңлебай карт тормышын тасвирлау аша авылның бик нык үзгәрүен сурәтли: «*Дөньяда чамасыз озак яши торгач, кай-*

*чандыр паровоз тавышын да ишетмәгән бабай тракторын да күрде, автомашинасын да, самолётын да, радиосын да күрде; алар аның авылына һәм өенә килеп керделәр, ләкин картның берсенә дә исе китмәде. Чөнки бу заманның барышына ис китеп өлгерерлек түгел иде*». Әмма авыл кешеләре күңел байлыгын, кешелеклелекләрен саклап яши. Кеше нинди генә шартларда да әдәп-әхлак, кешелеклелеген, халкыбызга хас матур сыйфатларны югалтмаска, онытмаска тиеш, ди автор.

Акъәби кызы Гөлбикә фатирындагы вакыйгаларга нигезләнеп, авыру ана өчен врачлар дәвасы, ашау-эчү муллыгы, җылы һәм чиста урын гына җитми, ә аның җанын аңлау, аның әйтер сүзенә, васыятенә колак салучы да кирәклеге ачыклана. Акъәбинең Шагыйрь белән әңгәмәсе, эчке монологы шуны раслый. Һәр буын үзеннән соңгы буынга рухи мирасын тапшырып киткәндә, исәннәргә дә, инде бу дөньядан киткәннәргә дә хөрмәт саклаганда, гореф-гадәтләрне үтәп яшәгәндә генә, бу халыкның киләчәге була.

Акъәбинең Суфиян тормышына аерым тукталуы да юкка түгел. Бөтен мөмкинлеге булып та анасына тиешле игътибары җитмәгән бала ул.

Акъәби, васыятен җиткерә алмыйча, берүне дә мәшәкатьләми генә больницада чит-ятлар янында җан бирә (*чит куллар аның күзен йомдыра*). Соңгы васыяте дә үтәлми: аны кәфенсез, гробка салып күмәләр.

Автор шәһәрләшкән, тормыш мәшәкатенә бирелгән, күңел ачу, дуслар белән аралашу, ял итүгә вакыт таба алган балаларның әниләренең васыятен тыңларга ярты сәгатьлек вакыт таба алмауларын күрсәтә.

Укучыларга тәрбия бирерлек һәр өзеккә игътибар итеп, соңгы нәтиҗә ясала.

«Васыять» сүзенең мәгънәсен искә төшереп, Акъәбинең балаларына нәрсә васыять итәргә теләве ачыклана. Бу сорауны ачыкларга сандык вакыйгасы да ярдәм итә. Укучыларның фикерләре тыңлана һәм укытучы нәтиҗә ясый.

Васыять ике өлештән тора. Беренчесе — әниләрен мөселманча җирләү. Икенчесе — әниләренең балаларына үз төсе итеп сакларга биреп калдырасы әйберләре. Алар гадәти нәр-

сәләр генә түгел. Тирән мәгънәгә ия бу әйберләр — башкорт халкының рухи хәзинәсе, гореф-гадәтләре, әниләренең хәтирәсе, үткәннәрнең шаһиты, халыкның хәтере. Югалмаска, онытылмаска тиеш нәрсәләр. Акъәби Мария киленгә дә үз төсе булган бөятне атап куя. Димәк, бу мохиткә кергән чит милләт вәкиле дә ул халыкка хөрмәт сакларга тиеш. Әдәби әсәрдә әйберләрнең ролен шулар аша ачу кирәк. Әмма аларның берсен дә ул балаларына җиткерә алмый. Онык кулына бары камчы гына күчә. Димәк, усаллык кына буыннан буынга тапшырыла түгелме?! Калган нәрсәләр театр гардеробына илтеләчәк. Яңа буын үз күңеленә, үз йортына үткәннәрне алып керми; дини йолаларга, гореф-гадәтләргә кайдадыр читтә, музей, театрларда гына яшәргә кала.

Акъәбинең васыяте зурмы? Акъәбинең гомере буе саклаган бу әйберләре зур хәзинә түгел кебек, әмма аларга автор бик олы мәгънә сала. Алар — гади нәрсәләр генә түгел, тулы бер халыкның рухи мирасы. Моннан да зур кыйммәтле васыять була алмый. Гомер буе халкының аклык, сафлык өлгесе булып яшәгән әбинең соңгы юлга да бар йолалар үтәлеп озатыласы килә. Әмма бу үтәлми. Суфиян улы вәгъдә биргән иде бит, югыйсә.

*(–Улым, үтенәм сездән, мине, зинһар, үзебезчә, мөселманча җирли күрегез инде — ди Акъәби. Улы Суфиян, уйлап та тормыйча: — Һи, әсәй, обязательно шулай эшлибез аны! — диде гаҗәеп бер җиңеллек белән.)* Анага карата моннан да зур хыянәт була алырмы?!

Алдагы сөйләшүләргә нигезләнеп, әсәр идеясе укучылардан әйттерелә.

Укучыларныың фикерләренә нигезләнеп, әсәр идеясен ачуда әйберләрнең ролен билгелибез.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Әсәрдә әһәмияткә ия булган әйберләрне атагыз. Аларның әсәрдәге вазифасын әйтегез.*

*Әсәрнең идеясе нинди?*

*Балалар нинди хаталар эшләделәр?*

*Әсәрне укыгач, үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз? Әсәр сезгә алдагы тормышыгыз өчен нинди сабаклар бирде?*

**VI. Өй эше бирү.**

Өй эше укучыларга вариантлап та, барысына бертөрле итеп тә бирелергә мөмкин. Ул сорауларга җавап яки иҗади эш тә була ала. Соңгы дәрестә укучыларга Акъәбинең балаларына ачык хат язарга кушыла.

Н. Думавиның «Яшь ана» әсәрен укып килергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема.** «Яшь ана» хикәясендә геройларның күңел халәтен ачуда әдәби детальнең әһәмияте.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — иҗтимагый һәм табигать фәннәреннән алган белемнәрне әйләнә-тирә мохит өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү; башкаларның күңел кичерешләрен аңлый, уртаклаша белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау, уку мәсьәләсен куя белү, чишү юлларын билгеләү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — хикәянең эчтәлеген белү, геройларга бәя бирү, идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 157—164.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Укучыларның хикәя жанры турындагы белемнәренә нигезләнеп, аңа хас билгеләр ачыклап үтелә. Хикәя катлаулы булмаган вакыйганы сөйли, тормышның бер мизгелен алып тасвирлый, кешенең аерым бер сыйфатын ача.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Сөйләшүгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Укучылар өйдә хикәя белән танышып киләләр. «Хикәя» төшенчәсен искә төшереп, әсәрнең хикәя икәнлеген дәлилләүче билгеләр күрсәтеп анализлана.

Бу очракта Заһидәне яшь әни белән таныштыру.

Бу — Заһидәне яшь әни белән таныштыру алдыннан өйдә чәй әзерләгәнче булган мизгел. Ләкин укучылар хикәядә башка вакыт киңлегенә чыгуны да күрергә тиеш. Бу Хәмид өйләнгәннән алып, Заһидәнең бишенче яше белән киткәнче булган вакыйгалар аша сурәтләнә. Әмма язучы аны үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция) алымы аша, Заһидәнең һәм Хәмиднең хәтер яңартуы рәвешендә бирә. Хәтер яңартуга бакча һәм тарак сәбәпче була. Кыскача шул урыннарны укучылардан сөйләтергә яки укып китәргә кирәк.

Бакча бала күңелендә гел хатирәләр уята. Әнисе белән бергә булган бакча — тыныч, матур тормыш, әмма бакча шул ук вакытта өйрәнелмәгән, таныш булмаган, явызлар булырга мөмкин (бүре фәлән) урын да. Ул Заһидәне шомландыра, куркыта. Шул сурәтләнеше белән ул кызчыкның билгесез язмышына ишарәли.

Тарак — Хәмиднең Заһидәнең әнисенә сөю, вәгъдә бүләге. Әмма ул бүгенге көндә чүплеккә чыгарып ташланган. Хәмид бу сөюне күңеленнән алып ташлаган, ләкин Заһидә өчен аннан да кадерле нәрсә юк, ул аны үзенеке итәчәк.

Энҗе, бриллиантлар белән бизәлгән затлы бүләк — Хәмид агайның тәүге мәхәббәте хатирәсе дә. Димәк, тарак — үткән белән бүгенгене тоташтыручы хәтер, инде бу тормыштан киткән хатынының истәлеге. Бакчада югалып калган таракны Заһидә табып керә. Бу шулай ук онытылып, югалып бара торган хатирәләрне яңарта, үткән белән хәзергене бербөтен итеп

тоташтыручы сабый бала — Заһидә барлыгын искәртә. Димәк, Хәмид ага, үткәннәрдән аерылып, яңа тормыш башлый алмый. Бу тормыш үткәннәрнең дәвамы булырга тиеш. «Хәмид агай Заһидәнең күзләре аша анасын күргән төсле булды, гүя Заһидәнең күзләре аша Заһидәнең әнкәсе карый иделәр!..» дигән юллар нәкъ шуны раслый. Бала — буынның дәвамчысы, үткәнне һәм киләчәкне бәйләп торучы.

Заһидәнең бакчада игътибарын җәлеп иткән күренешләр, тавык, күркә, карлыгачлар тормышның бернигә карамыйча үз агымында булуын аңлата. Алар Заһидәнең әнисе исән вакытта да шулай булган, алга таба да шулай дәвам итәчәк.

Алга таба Заһидәнең кичерешләре, хисләренең тирәнлеген, сабый күңелендәге хатирәләрдә юксыну, сагыну һәм өмет чаткысы яшәвен язучы нинди осталык белән ачуын күрсәтә алу төп максатларның берсе булып тора.

Заһидәнең эчке тоемлавы бик көчле, ул акылы җитмәгән нәрсәләрне, үз язмышына мөнәсәбәтле үзгәрешләрне рухи халәте аша уздыра.

Заһидә тормышында кискен үзгәреш кәтелә. Кызчык үз әнисенең бөтенләй кайтмаска киткәнен (үлемен) аңларга, аны ят, яңа кеше алыштыруын кабул итәргә тиеш. Бу үзгәрешкә ул әзер түгел, әмма аның күңеле нидер сизенә, тирә-ягында бала төшенеп җитә алмаган вакыйгалар баруын эчке бер тоемлау белән сизә (асрауларның аңа мөнәсәбәте, әтисе бүлмәсендә йоклый торган яңа «асрау» барлыкка килү һ. б). Язучы бик кечкенә сабыйның әлеге хәлләргә биргән бәясе, психологик анализы аша шундый нәтиҗәгә алып килә: язмыш кайвакыт кешегә үзгәрешсез кабул ителә торган үз кануннарын куя. Теләсәк-теләмәсәк тә без болар белән килешергә тиеш булабыз.

Язучы укучыны уйландырырлык проблема алдына куя. Күңеле әнисе турындагы хатирәләр белән тулы, өзелеп җитмәгән өмет кылына ябышып кына, эчендә тулып ташкан сагышны тотып торган сабый җаны «мин инде сиңа әнкәй булырмын» дигән яңалыкны ничек кабул итәр? Тулып түгелергә өлгермәгән хәсрәт күңелендә таш булып катмасмы? Бәлки, сабый күңеле эреп китәр, кайгысы, юксынулары таралырга сәбәп булыр.

Язучы тел бизәкләренә, сурәтләү чараларына игътибар бирә: чагыштыру, метафора, символларны иркен куллана. Хикәядә бу уңайдан мисаллар бик күп. Алда телгә алынган тарак, бакча, чәчәк һ.б. Беренче абзацны укып тикшерү генә дә моны дәлилләү була алачак. Язучының бала күңел халәтен ачу осталыгын да (укучылар әле бу төшенчәне белмәсәләр дә психологизмга игътибар иттерү яхшы) аерып күрсәтү кирәк. Бу күңел сафлыгы, һәрнәрсә белән кызыксынучанлык, эчке халәтенең тиз үзгәреп торуы (уенга бирелә, хәсрәтләнеп тә ала, куркып та куя) һ. б. укучыларның үзләреннән күрсәттерелеп, мисаллар белән дәлилләнергә тиеш.

Үткәнгә кире кайту (ретроспекция) алымы белән таныштырып, аның хикәядә бирелешен күзәтәбез.

*Үткәнгә кире кайтып сурәтләү алымы авторга нинди мөмкинлекләр ача*? Шушы сорауга җавап биреп, аның әсәрдәге әһәмиятен күрсәтелә.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне дәвам итәргә, Заһидәнең киләчәк язмышын ничек күзаллауларын дәлилләп сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Сары — сагыш билгесе (Лирик әсәрләрдә әдәби деталь: Хәсән Туфанның «Каеннар сары иде» шигыре).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — гражданлык бурычларын үтәүгә һәм хокукларын гамәлгә ашыруга әзер булу; тарихи вакыйгаларның шәхес язмышына тәэсирен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәпнәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, куелган уку бурычын чишү өчен, кирәкле җитешмәгән мәгълүматны ачыклау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерләрен әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — лирик әсәрне анализлый белү, әдәби детальнең фикер җиткерүдәге ролен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 164—166.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *Ак төсне сафлык, пакьлек, күңел чисталыгы дип билгеләгән идек, сары төс нинди мәгънәгә ия булырга мөмкин?* Укучылар үз фикерләрен әйтә. Укытучы авторның бу төс аша нәрсә белдерергә теләвен текст эчтәлеге ярдәмендә белеп булганлыгын искәртә. *Х. Туфанның «Каеннар сары иде» шигырендә сары төс һәм башка әдәби детальләр нинди мәгънә алды икән?* дигән сорау куеп, шигырь белән танышуга күчелә.

**III Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Шигырьне аңлау җиңел булсын өчен, аның ни сәбәпле репрессия корбаны булуы һәм төткынлык чорына игътибарны юнәлтеп, кыскача гына шагыйрьнең тормыш юлын искә төшереп китү файдалы.

Совет властен таркатырга теләүдә, илбашы Сталинга каршы сәяси эш алып баруда гаепләп, Х. Туфанны 1940 нчы елның 18 октябрендә кулга алалар. Аны Черек күл төрмәсенә ябалар. Өендә дә тентү уздыралар. Күп кенә кулъязмаларын, китапханәсендәге китапларын алып китәләр. Калганнарына да йозак салына. 1942 елның 2 мартында суд карары аны үлемгә хөкем итә, бер ай буе үлем камерасында утырган-

нан соң, карарның ун ел төрмә һәм гомерлек сөрген белән алыштырылуын хәбәр итәләр.

Бу елларда Х. Туфанның гаиләсе дә тынычлык күрми. Тормыш иптәше Луиза ханым «халык дошманы хатыны» дип эштән куыла. Ул чәч толымнарын кисеп сата, кан бирә. Үзләренең яшәү шартлары искиткеч авыр булуга карамастан, иренә ярдәм итә. Әтисе кулга алынганда 40 көнлек кенә булып калган Идегәй исемле улы җиде генә ай яшәп үлә.

1953 елда И. В.Сталин вафат булганнан соң, репрессияләнгәннәрнең эшен кабат карау мөмкинлеге туа.

1956 елның 19 мартында Х. Туфан да тулы реабилитация ала, аның бер гаебе дә булмавы танылa. 21 июнь көнендә аңа тиешле документларны бирәләр, һәм ул туган якларына кайта ала. Х. Туфан, акланып, Казанга кайтканда, хатыны Луиза да вафат булганлыктан, әтисен кызы Гөлгенә генә каршы ала. Укучыларга таныш «Кайсыгызның кулы җылы?» шигыре искә төшерелә.

(*Шигырьне тәкъдим итәргә берәр укучы алдан әзерләнеп килергә мөмкин.*)

Күрсәтелгән QR-код аша кереп, Х. Туфанның тормыш юлын чагылдырган фотолар белән танышырга мөмкин.

«Каеннар сары иде» шигыре укып анализлана. Лирик геройның хисләре билгеләнә: борчылу, кызгану, әрнү.

Хиснең сәбәбе: «Кайгының ни сүз икәнен белмәгән сабый бала»ның сагыну сагышлардан ал йөзе саргаю, күзенең зәңгәрләрен яшьләре юу.

Бала нилектән шундый авыр хәлдә: әтисен сагына, хат көтә, «әннәсе»нең дә күңеле тыныч түгеллеген, өйгә хәсрәт кергәнлеген сизә.

Шигырьдәге шушы вакыйгалар Х. Туфан язмышы белән янәшә куеп бәяләнә.

Лирик геройның кичерешләрен ачарга ярдәм иткән детальләргә игътибар ителә.

**Көз** иде... Җирнең шушындый Күңелсез чагы иде; Астралар, гөлләр **кыраулы**, Каеннар **сары** иде... — табигать күренешендәге детальләр.

**Хат** (китермиләр) — хәбәр булмау.

*Шкафта — кызыл пичәтле.*

*Нindидер бүтән йозак,* — димәк, әтисе сугышта гына түгел, тентүдән соң салынган башка йозак. Балага аннан китап алып бирү мөмкинлеге юк.

Сары төс сагыш, сагыну, борчылуны белдерә.

Лирик герой әлеге детальләр аша әтисеннән аерылган, авыр шартларда калып, елап арыган баласы өчен сызлануын сөйли.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектәге сорауларга җаваплар бирелә.

Үткәннәрне (әдәби әсәрдә пейзаж, портрет, әдәби деталь: әйберләр дөньясы темалары) искә төшереп, нәтиҗә ясала.

**III. Өй эше бирү.**

1. Шигырьне сәнгатьле итеп укырга, әдәби детальләрнең мәгънәсен ачыклап әйтә белергә.

2. Дәреслектә күрсәтелгән QR-код аша кереп, Х. Туфан турындагы фильмны карарга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Символизм. Әдәби әсәрдә символларның төрләре.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — күзәтүчәнлек, тоемлау, фаразлау сәләте арту.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, тәкъдим ителгән мәсьәләне исәпкә алып, карала торган әдәби фактларда һәм текстны күзәтүләрдә закончалыкларны һәм каршылыкларны ачыклау, төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү; уку диалогы барышында фикер алышуда төп тема буенча сораулар бирү.

*Предмет нәтиҗәләр* — символ төшенчәсен, әдәби әсәрдә аның әһәмиятен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 4—5.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *Сез нинди символлар беләсез?* Укучыларга дәүләт символларын, Татарстан Республикасындагы төрле районнарның эмблемаларын тәкъдим итәргә, мәгънәләрен ачыкларга мөмкин.

*Әдәбиятта да символлар кулланыла аламы? Ничек, нинди максат белән файдалану мөмкин дип уйлыйсыз?*

Әлеге сорауларга укучыларның фикерләре тыңлана.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Укытучы дәреслектәге материалны мисаллар белән тулыландырып, теманы аңлата. Әдәбиятта традицион символлар (*ай, кулъяулык, йөзек, чәчәк, сандугач һ.б*) билгеле бер автор иҗатында кулланылган символлар, бер үк образга төрле автор төрле мәгънә бирергә мөмкин булуы һәм чор, иҗтимагый вакыйгаларга бәйле символларга игътибар итү кирәк. Мәсәлән, XX гасыр башындагы иҗтимагый вакыйгалар *таң, диңгез, кораб* образларының үзенчәлекле символик мәгънә алуын, 30 нчы еллар әдәбиятында шәхес культы белән бәйле *җил* образы шымчы, доносчы буларак кулланылуын мисалга алырга мөмкин. Укучыларга таныш әсәрләргә мөрәҗәгать итү уңышлырак. Мәсәлән, Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» әсәрендә — Җидегән чишмә, Алтынбикә тугае, Н. Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәрендә — яз, Ф. Хөснинең

«Йөзек кашы» повестенда — йөзек, Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә — учак, Р. Мөхәммәдиевнең «Беренче умырзая» повестенда умырзая, чишмә образлары символ мәгънәсен ачарга ярдәм итә ала. Әлеге әсәрләр белән укучылар таныш булганлыктан, теманы ачуда үзләре үк катнаша алалар. Әдәбиятта символлар куллануның әһәмияте, аларның әсәр тукымасындагы роле турында сөйләшеп нәтиҗә ясала.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Нәрсә ул символ?*

*Әдәбиятта символлар ни өчен кулланыла?*

*Традицион символларга мисаллар китерегез.*

*Иҗтимагый чор тудырган нинди символларны атый аласыз?* кебек сорауларга җавап бирү.

**VI. Өй эше бирү.**

8—17 нче битләр укып килергә (8—29 нчы битләр укып килергә).

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Язмыш сынавын һәркем үзенчә кичерә (Фәнис Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда кеше язмышы, рухи батырлык мәсьәләсе).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — гражданлык бурычларын үтәүгә һәм хокукларын гамәлгә ашыруга әзер булу; ихтыяр көче, үз-үзеңә ышаныч, рухи ныклык булдыру.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби күренешләрне өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — эчтәлекне аңлау, автобиографик әсәр үзенчәлекләрен билгеләү, геройларга бәя бирү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 6—29.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә. Укылган өлешнең эчтәлеген кыскача сөйлиләр.

2. *Кеше җиңеп чыга алмаслык авырлык буламы?* соравына нигезләнеп сөйләшү үткәрелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Әңгәмәгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Фәнис Яруллинның тормышы, иҗатына күзәтү ясау. Бу урында дәреслектә күрсәтелгән QR-код яки башка чыганаклар ярдәмендә укучылар өйдә әзерләнеп килә алалар. Ф. Яруллинның дәреслектә бирелгән көндәлегеннән өзек белән дә таныштырып китү файдалы.

Укучыларның әсәрнең бер өлеше белән таныш булуларын искә алып, 1–3 нче сорауларга җавап табыла.

Алга таба Фәнияр һәм Фәүрия турында да тулырак итеп укучылардан сөйләтелә. Фәниярнең әнисе Гөлсәйдә апаның кичерешләрен дә укучыларның үзләре аша кичереп сөйләүләренә ирешү яхшы.

Әсәрнең әлеге өч героеның борчылу һәм өметләрен укучылар үз сүзләре белән сөйләсеннәр һәм бу геройларга карата күңелләрендә туган хисләр белән уртаклашсыннар. Шул очракта аларга геройларның психологик кичерешләрен дә аңларга күпкә җиңелрәк булачак.

Геройларның күңел кичерешләрен аңлату өчен, болында почтальон Линуза килгән өзекне кычкырып укырга һәм Гөл-

сәйдә, Фәүрия һәм Линузаның күңел халәтен тасвирлап бирү кирәк (әгәр укучылар үзләренә генә авыррак булса, укытучы ярдәмгә килә). Рус телендә белем бирә торган мәктәпләрдә бу өлеш җентеклебрәк анализлана.

Әсәрдә геройларның күңел кичерешләре тасвирланган урыннарны укып, анализлауга вакыт бирелә.

Мәсәлән, Фәүриянең хатын алгач, Фәниярның кичерешләре (19—20 нче битләр), Фәүриянең табип белән сөйләшкәннән соңгы кичерешәләре (20—21нче битләр), Фәниярның табигать белән хозурлангандагы уйланулары (22 нче бит).

**Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Ф. Яруллинның тормыш юлы искә төшерелә.

«Җилкәннәр җилдә сынала» әсәренең герое Фәнияр белән автор язмышындагы уртаклыкка игътибар ителә. Әсәрнең автобиографик әсәр булуы нигезләтелә. Геройлар турында кыскача гына сөйләтелә.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрне укып бетереп килергә. Дәреслектә 29 — 39 битләр.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Җилкәнеңне җилләр екса (Ф. Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда герой характерын ачарга ярдәм иткән символлар).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — гражданлык бурычларын үтәүгә һәм хокукларын гамәлгә ашыруга әзер булу; рухи ныклыкка ия булу, башкаларны бәхетле итәргә сәләтле булу, патриотик хисләр тәрбияләнү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби күренешләрне өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, үз фикерләреңнең һәм башкалар фикерләренең дөреслеге турында гипотеза формалаштыру, үз пози-

цияңне, фикереңне дәлилләү; уку диалогы һәм (яки) дискуссия барышында фикер алышуда төп тема буенча сораулар бирү.

*Предмет нәтиҗәләр* — символларның әсәрдәге ролен билгеләү, әсәр идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 8—39.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *Сез ялгыз гына җилкәнле көймәдә йөзгәндә, давыл чыкты һәм көймәгезне диңгез эченә куа башлады, ди. Бу вакытта сез нәрсә турында уйларга тиеш буласыз? Иң әһәмиятле фикерне генә әйтегез.* (Ничек тә исән калырга. Мин үземә бары үзем генә ярдәм итә алам.) *Түземнәр генә бәхеткә лаек» дигән фикер белән килешәсезме?* сораулары уку мәсьәләсен куярга ярдәм итәр.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әсәрнең эчтәлеге нигезендә укучылар автобиографик повестьның темасын, идеясен билгелиләр, геройларны характерлыйлар һәм аларның прототипларын әйтәләр, тел-сурәтләү чараларын тикшерәләр. Фәнис Яруллинның тормышы һәм әдәби әсәр арасында уртаклыкны күрсәтәләр.

*Фәүрия кабул иткән карар белән сез килешәсезме?* (Үзендә бу авырлыкларны җиңә алырлык көч, ихтыяр юклыгын аңлап, үз вакытында Фәниярга бернәрсә дә вәгъдә итмәве яхшырак.)

Фәниярның больницада яткандагы күңел кичерешләре, рухи халәте укып анализлана. Бик көчле кешеләрнең дә үз-үзенә ышанычын, тормыш мәгънәсен югалткан мәлләре була.

Укучылар Фәниярга күңелендә ышаныч яшәргә көч биргән сәбәпләрне барлыйлар (иҗат белән мавыгу, бу өлкәдә уңышларга ирешү, университетта уку, янәшәсендә аңа ышанган, күңелен үстергән кешеләр булу.)

Фәниярның Илсөягә хисләре турында әңгәмә үткәрү өчен 33—34 нче битләрдәге өзек укыла (*Тормыш бераз эзгә төште. ... Иңнәрне иңгә терәп баручы яр кирәк.*).

Фәнияр кичерешләре каршылыклы: ул үзенең гаилә корырлык сәламәтлеге юк икәнен аңлый, кемгәдер йөк буласы да килми, әмма йөрәге белән нәкъ башкалар кебек үк бәхеткә хакы бар икәнен дә тоя. Аның кайсы фикерен ни өчен куәтләүләрен укучылар үзләре аңлатып бирсеннәр. Һәркем үзенчә хаклы, төзәтү кертелми, бары Фәнияр булып уйларга гына тәкъдим итәргә кирәк.

Аның хисләренең тирәнлеген, өметен күрсәткән өзекләр дә (Илсөя килмәгәндә көтүе, килгәч, эченә сыймаган шатлык хисләре) бергәләп укыла.

Илсөягә Фәниярның бәясе, аңа ышанычы (песнәк белән чагыштыру) күрсәтелә.

Илсөянең Фәниярга килү юлындагы каршылыклар һәм аларның чишелешен бәяләү. (Ана фатихасыннан алда хәл итмәвен ассызыклап, эти-әни сүзенең зурлыгы аңлатыла.) Ахыргы өлешне (*Илсөя мәхәббәттә тугры булган кебек, Фәнияр да үз девизына мәңге тугры калды. Ә девизы аның мондый иде: ....)* сыйныфта укып нәтиҗә ясау.

Илсөя образының прототибы Нурсия ханым турында сөйләшү, аларга куелган һәйкәлнең нинди тирән мәгънәгә ия икәнлеген төшендерү. Бу һәйкәл — ике зур батырлык сыны. Бер яктан, ул олы мәхәббәтне гәүдәләндерсә, икенче яктан, Фәнис Яруллинның язмышына төшкән сынауны лаеклы кичүен, зур иҗат калдыруын һәм Нурсия апаның (гомумән хатын-кызның) тугрылыгын, сабырлыгын, сафлыгын һәм ихтыяр көчен гәүдәләндерә.

Әсәр исеменә чыгарылган җилкән һәм җил образларына символик мәгънә салынган. Җил — тормыш сынавы, каршы-

лыклар символы. Җилкән — кешенең омтылышы, хыяллары. Чынбарлыкта җил җилкәнне хәрәкәткә китерә. Димәк, бер дә каршылыкларсыз гына алга хәрәкәт итү дә булмый. Кеше дә каршылыкларны җиңеп кенә алга бара. Түземнәр генә бәхеткә лаек, ди автор.

Әсәрнең беренче исеме «Җилкәнеңне җилләр екса» дип аталган. Бу очракта әсәрдә өметләре киселгән герой күз алдына килер иде. Ә әсәрнең герое Фәнияр (геройның прототибы булган Фәнис ага да) андый түгел. Автор тормыш каршылыкларында чыныккан, авырлыкларга бирешмәгән, рухи яктан нык, зур ихтыяр көчле герой тудыра. Шуңа әсәр исемен дә «Җилкәннәр җилдә сынала» дип үзгәртә.

Тормышыбыздагы көчле ихтыярлы, сынмас рухлы кешеләргә мисаллар китереп, нәтиҗә ясала. Ил алдына бурычын үтәгәндә сәламәтлеген югалтканнарга дәүләтебезнең ярдәме зур булуы һәм халыкның олы хөрмәтенә лаек икәнлекләрен күрсәтеп, патриотик тәрбия бирелә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектәге 5—8 нче ( 5—11 нче) сорауларга нигезләнергә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Фәниярга характеристика яки Илсөягә ачык хат язарга.

Әсәрнең соңгы абзацын ятларга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Шигъриятнең серле дөньясы (Шигърияттә символизм: Дәрдмәнднең «Кораб», Роб. Әхмәтҗановның «Гомер китабы» шигырьләре).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — гражданлык бурычларын үтәүгә һәм хокукларын гамәлгә ашыруга әзер булу; туган ил гаме белән яшәү кирәклеген аңлау, гражданлык һәм патриотик хисләргә ия булу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйлә-

нешләре урнаштыру, үз фикерләреңнең һәм башкалар фикерләренең дөреслеге турында гипотеза формалаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү, әдәби белем алуда сорауларны танып белүне тикшерену коралы буларак куллану; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — лирик әсәрдә символ куллану үзенчәлеге, лирик әсәргә анализ ясау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 41—44.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Кыскача гына XX гасырдагы иҗтимагый вакыйгалар, аларның кешенең рухи халәтенә, әдәби барышка тәэсире турында кереш сүз әйтелә. Иҗтимагый шартларның әдәбиятка йогынтысы аның образлар системасына да тәэсир иткәнлеген искә төшерәбез. (Символлар темасына керешкәндә XX гасыр башы белән бәйләп бу хакта сүз булган иде.)

Узган дәрестә җилкән символы тормыш авырлыкларын җиңгән геройны гәүдәләндерүен ачыклаган идек. *Ә XX гасыр башында кораб образы нәрсәне гәүдәләндерүче символ булырга мөмкин дип уйлыйсыз?*

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта сөйләгәннәргә нигезләнеп, дәреснең максатлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Кыскача гына Дәрдмәнднең тормышы, XX гасыр башындагы сәяси вакыйгаларга мөнәсәбәте ачыклап кителә. XX йөз

башы татар шигъриятендә Дәрдмәнд — бер үк иҗтимагый-сәяси шартларда иҗат мәйданына аяк баскан чордашларыннан әсәрләренең идея-тематик эчтәлеге белән дә, тел-өслүбе ягыннан да аерылып торучы шагыйрь буларак ачыла.

«Кораб» шигыре укыла. Шигырьдәге образлылыкка игътибар итеп, анализ ясала.

*Шаулый диңгез...*
*Җил өрәдер...*
*Җилкәнен киргән кораб!*
*Төн вә көндез*
*Ул йөридер:*
*Юл бара ят ил карап...*

Шигырьнең беренче строфасын укыгач, күз алдына нинди картина килүе сөйләтелә.

Калган өлешен дә укып, аның эчтәлеккә нинди яңалык өстәвенә игътибар ителә (җил чыгу, корабны сөрә, юллар, упкын корбаннар сорый һәм «ил корабы» дигән гыйбарә кулланыла).

Шигырь мәгънәсен шәрехләүдә күп вакыт шушы дүртьюллыкка таяналар. Ләкин Дәрдмәнд «Юл бара ят ил карап» дип, фаҗиганың сәбәбен алдарак искәртә. Илләр-җирләр күргән, бәйсезлек, матди һәм рухи ирекнең ни икәнен аңлаган, башка халыклар арасында кимсенмичә, үз дәрәҗәсен белеп эш йөртергә өйрәнгән шагыйрь күңеле халкыбызга читтән мәҗбүри тагылган инкыйлабны кабул итә алмый. Аның күңелен корбан кирәклеге генә борчымый, ә нинди максат һәм нәрсә хакына корбан соралуы уйландыра, ягъни *Илдә барган кан коюлар нәрсә хакына, халык өчен аның әһәмияте булырмы?* Ул үзгәреш заруриятен аңлый, тарихның котылгысыз бер һәлакәткә якынлашуын тоемлый, шул сәбәптән өзелеп-өзелеп сызлана. Күңлендәгесен ачыктан-ачык ярып салуда да мәгънә күрми, белә: буржуазия сыйныфы вәкиле,үзе өчен зар елаучы, инкыйлабны кире кагучы буларак кабул итеп, аны аңламаячаклар һәм тәнкыйть утына тотачаклар. Шуңа Дәрдмәнд күңлендәгесен турыдан-туры түгел, күп урында символлар аша сурәтләүгә, эчке мәгънә йөген арттыруга күчә.

«Кораб» шигырьнең язылу вакыты, бу чорда илдә барган вакыйгаларга бәйләп образларның мәгънәләре ачыклана.

Кораб (ил корабы) — милләт, ил, халык. Корабның юлы дәвамлы. Тик бу вакытта ул ят ил карап юл тота — үз кыйбласына түгел. Бу революцион үзгәрешләрнең чит дәүләтләр үрнәгендә ясалуына да ишарә булып тора

Диңгез шаулавы — тормыш, вакыт агышы; революцион күтәрелеш.

Дулкын — язмыш, тормышны үзгәртүче көч.

Җил — илдәге үзгәрешләр.

Упкын — революцион үзгәрешләр таләп иткән корбаннар.

Шигырьдә ил, милләт язмышының киләчәге билгесез икәнлеге ачыклана.

Дәрдмәнднең милләт өчен, халык өчен борчылып язган шигырьләре символларның күп булуы белән үзенчәлекле.

Кораб образы — ил, милләт символы. XX гасыр башында илдәге сәясәт татар халкы алдына сорау куя: милләт нинди юлдан китәр? Билгесезлек, өметләр акланырмы дигән сорау шагыйрьне борчый. Революция бер яктан азатлык алып килсә, икенче яктан авырлыклар, үлем, күп корбаннар сорый.

Алга таба Роберт Әхмәтҗановның «Гомер китабы» шигырен укып, эчтәлекне дөрес кабул итүләренә ирешергә кирәк.

Гомер китабы — лирик геройның гомер юлы.

*Бу китапның ачтым күпме битен!..*

*Ничә бит бар тагын — әйтү читен* (аның яшәгән һәм алда яшәләчәк гомере.)

*Ал таң, сөт парлары, жылы җилләр* (балачакның матур мизгелләре.) *карап куйды болыт* (узып китә торган вак мәшәкатьләр.)

*Шигырь нәрсә турында? Төп фикере нинди? Автор, фикерен укучыга җиткерү өчен, нинди образларга мөрәҗәгать итә?* кебек сорауларга җавап табу сорала.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектә бирелгән сорауларга җавап табып, укучылар төрле чор шагыйрьләрендә символларның, эчке мәгънә йөгенең ничек кулланылышын күзаллап каларга тиеш булалар.

Дәреслектә 42 нче (44 нче) битләр.

**VI. Өй эше бирү.**

Дәрдмәнднең «Кораб» шигырен ятларга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Психологизм. Әдәби әсәрдә психологизмның төрләре.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — кеше күңелен аңлый белү, күңел халәтеңне башкалар белән уртаклаша алу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, яңа шартлар һәм үзгәрешле ситуацияләр, билгеләнгән хаталар, килеп чыккан кыенлыклар нигезендә эшчәнлеккә төзәтмәләр кертү, нәтиҗәнең максат һәм шартларга туры килүен бәяләү; төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, үз фикерләреңнең һәм башкалар фикерләренең дөреслеге турында гипотеза формалаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; уку диалогы барышында фикер алышуда төп тема буенча сораулар бирү.

*Предмет нәтиҗәләр* — «психологизм» төшенчәсен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 45—47.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.
2. Берничә рәсем куярга мөмкин.

Әлеге рәсемнәрнең укучыларда нинди тәэсирләр уятуы белән кызыксыныла, аларның фикерләре тыңлана.

Тормышыбыздагы һәрбер вакыйга, күренешләр дә, бөтенләй таныш булмаган кеше дә, хәтта бик кечкенә җан иясе дә күңелдә нинди дә булса хис-тойгы уята. Кеше фикерләве хис-кичерешләр белән бер агым тәшкил итә. Ләкин бер үк күренеш, вакыйга төрле кешедә төрле тойгы тудыра. Төп сурәтләү объекты кеше булган әдәбиятта да кешенең хис-кичерешләрен төгәл гәүдәләндерми мөмкин түгел икәнлеге ассызыклана. Укучылар кешенең күңел дөньясын ачу өчен пейзаж, портретның да ярдәме барлыгын инде беләләр. Бу хакта искә төшереп, укылган әсәрдән мисал китерелгәндә бик яхшы. Әдәбиятта геройның күңел дөньясын тагын да тирәнрәк аңларга ярдәм итә торган тагын бер сәнгати алым — психологизм.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреслек материалына нигезләнеп, яңа тема ачыла. Дәреслекнең 46 нчы биттәге схемага карап, һәр очрак өчен әдәби әсәрләрдән мисаллар китерү юлы белән бару да мөмкин. Нәтиҗә ясаганда, әдәбиятта психологизмның роле һәм татар әдәбиятында танылган психологизм остасы булырлык әдипләрне атау кирәк.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Берничә рәсем биреп, анда сурәтләнгән кешеләрнең күңел кичерешләрен тасвирларга тәкъдим итәргә була.

**VI. Өй эше бирү.**

Әмирхан Еникинең «Кем җырлады?» хикәясен укып килергә, геройларның күңел кичерешләренә игътибар итәргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Тән ярасын оныттырырлык моң (Ә. Еникинең «Кем җырлады?» әсәрендә психологизм аша геройның рухи халәтен ачу).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — гражданлык бурычларын үтәүгә һәм хокукларын гамәлгә ашыруга әзер булу; туган ил, үз халкыңның моңы, яраткан кешеләрнең кадерен аңлау, патриотик хисләргә ия булу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби күренешләрне өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, куелган уку бурычын чишү өчен, кирәкле җитешмәгән мәгълүматны ачыклау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — әсәрдә психологизм үзенчәлеген, әсәр идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 47—53.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Бу QR-код ярдәмендә «Сарман буйларында» җырын тыңларга мөмкин. Җырны тыңлагач, сорау куела. *Җыр нәрсә турында? Нинди хисләр уята? Күңеле нинди хисләр белән тулганда кеше бу җырны җырлап җибәрер. Бу җыр сезгә танышмы?* (Таныш, аны «Кем җырлады?» әсәренең герое Таһирә җырлый.)

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Таһирә образына бәйләп, аның кем булуы, әсәрдә тасвирланган чорның кайсы еллар икәнлеге ачыклана (Ватан сугышының дәһшәтле көннәреннән берсе иде.). *Әсәрнең башында вакыйга бара торган урынны тасвирлаган өлешне укыганда күңелдә нинди хисләр туа?* (Әсәрдән өзек укыла.)

(Сугыш дәһшәте авыр кичерешләр уята. Эшелоннардагы кешеләрнең гомере куркыныч астында: санитар поездындагылар үлем белән көрәшә, фронтка баручылар соңгы тапкыр йокы туйдыра, аларның да гомеренең ахыргы көннәре булуы мөмкин.)

*«Бөтен станциясендә ник бер генә тычкан уты җемелдәсен — әйләнә-юнь морҗа эчедәй кап-кара»* дигән юллар ук күңелдә өметсезлек уята.

*Шушы авыр мохит эчендә автор Таһирә җырын бирә. Ни өчен дип уйлыйсыз? Бу урынлымы?* (Җыр — татар халкының мәңгелек юлдашы, аның күңел халәте, шатлыгы, кайгысы, сагыну-сагышы, йөрәгендәге хисләрен әйтеп бирү чарасы, хисләренең тышкы гәүдәләнеше. Ул әсәр башында сурәтләнгән күренешнең фаҗигалылыгын, дәһшәтен ача. Таһирә җыры әсәрнең тәэсирлелеген, үтемлелеген арттыруда ярдәм итә.)

*Ни өчен автор Таһирә җырын «Сарман буйларында» көеннән башлый дип уйлыйсыз?* (Җырда туган җир яме, мәхәббәт, аерылу сагышы, эчке моң бар. Ул Таһирәнең күңел халәтен ача.)

Таһирә җырлаган башка җырларның да мәгънәсе, аларга салынган хисләр ачыклана. Таһирә җырында аерылу сагышының тирәнлеге, бу аерылуның вакытлыча гына да түгел, гомерлеккә булуы сизелеп тора. Анда туган җирдән аерылу, билгесезлек, алда көткән хәсрәт-кайгы чагыла. Таһирә дә алда көткән дәһшәтне күңеле белән тоя. Сөйгәне дә сугышта (ул әле аның үлем белән тартышып ятканын белми), үзе дә ут эченә китеп бара.

Җыр — Таһирәнең күңел кичерешләрен ачарга ярдәм иткән психологизмның бер чагылышы һәм әсәр идеясен уку-

чыга җиткерү чарасы. Ул сугыш афәтенең кешеләр язмышына җимергеч тәэсирен, үлем ачысын, югалтулар сагышын, билгесезлектән сызлануны гәүдәләндерә.

*Таһирә җырын кем ишетә?* (Яралы яшь лейтенант — татар егете ишетә.) Аның хәле турында укучылар сөйләп китә.

*Таһирә җыры яралы егетнең рухи халәтендә нинди үзгәрешләр тудыра тудыра? (*Өзек укыла.*)*

Татар җыры, Таһирә җыры, туган ил җыры егетнең үлем газабын җиңеләйтә. Ул ләззәтле саташуга бирелә. Автор татар егете өчен үз җырын, үз моңын ишетүнең нинди зур көчкә ия булуын, кешенең күңелендә сакланган милли хисләре аны гомер буе юатып, җылытып килүен күрсәтә. Милли тойгы, милли моңның никадәр зур кыйммәт икәнлеген раслый. Егетнең рухи кичерешләрен психологизм алымы аша гәүдәләндереп, җыр образын символ югарылыгына күтәрә. Җыр — үткәннәр белән бәйле, киләчәккә өмет уята, кешеләрне рухи яктан берләштерә, милли бердәмлек тудыра, һәркемгә иң газиз булган Туган ил, туган җир, туган йорт, ата-ана, сөйгән яр, хәтер-хатирәләр булып, кешене бөтен гомере буе озата бара, шатлыкларын, кайгыларын чагылдыра, хәтта үлем газабын да оныттыра. Әсәрдә җыр — халыкның рухи ныклыгы символы.

Әсәрдә автор Таһирә кичерешләрен дә, егетнең рухи халәтен дә турыдан-туры сөйләми. Таһирә кичерешләрен җыр аша ачса, егетнең күңел халәтен ачуда психологизмның бер төре буларак саташу алымын кертә. Егетнең саташулы уйларын җентекләп сурәтләп, автор япь-яшь килеш кабергә керәчәк кешенең туган җирен, әнисен, сөйгән ярын уйлап юануын укучыга җиткерә. Күңелендә шулкадәр матурлык, мәхәббәт яшәгән егетнең бу уйлары аның үлем алды саташуы икәнен аңлау укучыны сызландыра. Анасы һәм сөйгән ярының кичерәсе кайгысы белән тоташа.

Ананың кичерешләрен укучылар үзләре аңлата: ак яулык — саф күңелле карчык, улын көтә, кипкән яфракларны өзә — сагышларны куарга тырыша.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектәге сорауларга нигезләнү мөмкин. Хикәя жанрына хас билгеләрне ачыклау, психологизм алымын кул-

лануның тәэсирлелекне арттырудагы һәм әсәр идеясен ачудагы әһәмиятен аңлауга ирешүне тәэмин итү күздә тотыла.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәр геройларының күңел кичерешләрен җентекләп сөйләргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Күңел кошың күкрәгеңә сыймаса... (Галимҗан Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» әсәрендә геройлар омтылган шәхес иреге).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — җәмгыять, мохит һәм шәхес мөнәсәбәтләрен аңлап кабул итү; тормышта үз урыныңны табу, максатка баруның әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, әдәби белем алуда сорауларны танып белүнең тикшеренү коралы буларак куллану, үз фикерләреңнең һәм башкалар фикерләренең дөреслеге турында гипотеза формалаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — әсәрдә психологизм бирелешен анализлау, «социаль-психологик роман» төшенчәсе белән таныштыру, әсәр идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 53—84.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Дәрескә әзерлек һәм өй эшләренең үтәлеше тикшерелә.

2. *Тумыштан бирелгән зур талант бәхет ачкычы була аламы?* проблемалы соравы нигезендә сөйләшү үткәрү.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Г. Ибраһимовның тормыш юлы белән танышуны видеодәрес материалына нигезләнеп эшләргә мөмкин.

Алга таба «Яшь йөрәкләр» әсәренең укылган өлешенең эчтәлеген хәтергә төшереп, вакыйгалар билгеләп куела. Әсәрдәге геройларны барлап, идеяне ачуда төп геройның әһәмияте зур икәнлеген искә төшереп, дәрестә аларга игътибар юнәлтеләчәге искәртелә һәм төп геройлар — Зыя, Мәрьям образлары үзәккә алына. Җәләш мулла һәм Гәрәй мирза гаиләсендәгеләрнең һәркайсы турында аерым әңгәмә оештырып, аларның да төп геройларны ачыклаудагы роле зур булуы күрсәтелә. Бу геройларның үзара мөнәсәбәтләре, бу мөнәсәбәтләрдәге каршылыклар һәм аларның сәбәпләре ачыла.

Әсәрнең сюжеты XX гасыр башындагы иҗтимагый шартларда көн итүче ике гаилә — Җәләш мулла һәм Гәрәй мирза гаиләләрен сурәтләүгә нигезләнгән. Аларның яшәү рәвеше, өлкәннәр һәм яшьләр арасында килеп туган каршылыклар аша язучы шул чорда җәмгыятьтә һәм кеше аңында барган үзгәрешләрнең тулы картинасын тудыра. Җәләш мулла һәм аның балалары арасындагы «аталар» һәм «балалар» каршылыгы аша искелек һәм яңалык көрәшен гәүдәләндерә. Әсәрдә татар тормышында гасырлар дәвамында сакланып килгән кануннарның һәм Җәләш мулла кебек искелек тарафдарларының милләтнең киләчәге өчен никадәр зарарлы булуын күрсәтергә тели. Иҗтимагый-рухи тормышта туган яңарышның кеше психологиясенә йогынтысы мохит һәм шә-

хес мөнәсәбәтләре аша ачыла. Шул сәбәпле әсәрдә мохит һәм шәхес каршылыгы алгы планга чыгарып сурәтләнә. Геройларның тормышы җәмгыять, мохиткә мөнәсәбәтле генә түгел, ә аларның яратылышына, калебенә, рухына, язмышлары аларны кайсы тарихи дәвергә куюына мөнәсәбәтле дә карала. Автор үзенең геройларын ике каршылык арасына куя. Бер якта, мохит, шул чор татар тормышының кануннары, икенче якта, геройның яратылышыннан ук булган рухияте, табигате. Менә шул ике нәрсәнең бер шәхеснең күңелендә яраша алуы яки киресенчә, каршылыкка керүе аларның язмышын билгеләүдә төп рольне уйный.

Әсәрнең төп герое Зыя язмышында бу каршылык тагын да ачык гәүдәләнә. Зыяның мохите шактый тар. Ул иске карашлы Җәләш мулла гаиләсендә үсә, аның язмышын билгеләүче төп көч — әтисе. Шөһрәт яратучы, тирә-якта дәрәҗәсе һәм байлыгы белән үзенә тиңләшерлек кеше юк дип санаган Җәләш мулла Зыяны бик тар кысаларда, гаилә мохитендә генә тәрбия кыла. Аның аралашкан бердәнбер кешесе дә — күршеләрендәге Гәрәй мирзаның хатыны, «авыллаша алмаган, мондагы һәммә нәрсәне кара, караңгы, ямьсез, артык прастуй вә артык тупас күргән Фатима бикә куенында» гына “Әлфе ләйлә вә ләйлә” әкиятләрен, мәхәббәт романнарын укып кына үскән Мәрьям туташ. Авылдагы яшьтәшләре белән аралашу, алар кебек көндәлек хезмәттә катнашу, күңел ачу Зыя өчен тыелган. Хәтта үзе бик теләсә дә, мулла улы мәхдүм Зыя андый андый ирекккә ия була алмый. Шәригать кануннары, халык күнеккән гадәт-йолалар, тормыш үзе үк моңа каршы килә. Аңа хәтта гади авыл малайлары кебек ат сакларга йөрүләр дә, яшьләр өчен булган кичке уеннар да — һәммәсе тыелган. Боларны ул гадәти кабул итә, әмма төп каршылык — Зыяның музыкага битараф була алмавында. Ул музыкасыз яши алмый, тормышының мәгънәсен бары музыкада гына күрә. Бу — Зыяга тумыштан бирелгән теләк, аның табигый яратылышыннан килгән ихтыяҗ. Аның шул табигате үзе яшәгән мохит белән кискен каршылыкта. Мунчага качып кубыз уйнаса, әтисе кыйнап ташлый, мәдрәсәдә мөдәррисләр җәза бирә, мәдрәсәдән үк тә куалар. Зыяның музыкага булган ихтыяҗын канәгать-

ләндерерлек тә, аңа бәйле хыялларын тормышка ашырылык та мөмкинлекләр татар тормышында була да алмый ди, автор. «Мохит», «җәмгыять» төшенчәләренә бергәләп аңлатма бирелә. Әсәрдә «мохит» сүзенең еш кабатлануына игътибар иттереп, аңа салынган мәгънә ачыклана.

Автор кешенең тумыштан (яратылышыннан) килгән таланты, мөмкинлекләре, эчке омтылышы, нәрсәгәдер ихтыяҗы була дип дәлилли. Бу Зыяның музыкагы омтылышы аша ачыла. (Укучылар аның музыкага булган мөнәсәбәтен әсәр дәвамында билгеләп барсыннар һәм фикерләрен шул өзекләр белән дәлилләсеннәр иде.) Аның язмышы аша талантның ачылуы, аның иясенә рухи канәгатьлек китерүе һәм башкаларга хезмәт итүе өчен тиешле җирлеккә-мохиткә эләгүе кирәк яки ул мохит тудырган каршылыкларны җимереп үзенә юл ярырга, үз-үзен расларга тиешлеген дәлилли. Зыяның омтылышлары мохит, шул чорның кануннары белән каршылыкка керә, артык хисчән, йомшак күңелле Зыяның әлеге каршылыкларны җимерерлек сәләте юк. Бу аның тормышын фаҗигага китерә.

Һәр фикерне әсәрдәге өзекләр белән дәлилләп бару кулай. Бу — укучыларны текст белән эшләргә, тиешенчә игътибар белән укымаган укучыларга да әсәрне аңларга ярдәм итә. Әсәрнең жанры социаль-психологик роман икәнлеген дәлиллибез. М. Хәсәнов «Г. Ибраһимовның тормышы һәм иҗат юлы» китабында «Яшь йөрәкләр» романының жанрын социаль-психологик роман дип билгели. Социаль-психологик романда иҗтимагый әһәмиятле проблемалар геройның тирән психологик кичерешләре аша тасвирлана. (Әсәрдән мисаллар белән дәлилләнә.)

Әсәрдә, гомумән, төп сюжет сызыгының Зыя образы белән бәйләнештә баруына игътибар иттереп, автор идеалының Зыя образында гәүдәләнеше ачыклана.

Укучылар әсәрдә геройларның бирелеше шәхес һәм мохит, җәмгыять мөнәсәбәтләрен ачуга хезмәт итүен, шәхеснең үзе яшәгән мохиттән тулысынча азат була алмавы, әмма ул мохитнең колы булмаска тиешлеген дә аңлап, ата һәм бала арасындагы каршылыкның шәхси каршылык кына түгел, искелек һәм яңалык көрәше икәнлеген дә ачып бирә

алсыннар иде. Моның өчен укытучының ваклап биргән сораулары кирәк булачак.

Әзлекле рәвештә геройларның күңел кичерешләре, психологик халәтен һәм аны тудырган вакыйгаларны күзәтеп бару шул нәтиҗәгә килергә ярдәм итәәр.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта сөйләшүне *Зыя һәм Мәрьям тәрбияләнгән мохитнең үзенчәлеге нәрсәдә? Бу мохиттә тәртипләр кем тарафыннан билгеләнә? Әсәрдә Зыяның музыкага мөнәсәбәтен күрсәткән вакыйгаларны санап чыгыгыз. Зыяның музыкага хирыслыгы һәм таланты бар, әмма ул аңа бәхет китерми, хәтта бәхетсезлек китерә. Сәбәбе нәрсәдә?* кебек сорауларга җавап рәвешендә үткәрергә була.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрнең дәреслектә бирелгән өлешен укып бетерергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Хыял һәм хакыйкатьнең арасы еракмы? (Галимҗан Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романының идеясе).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — табигать биргән талантны күрә, үстерә белү зарурлыгын аңлау, максатларны дөрес билгели белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, үз фикерләреңнең һәм башкалар фикерләренең дөреслеге турында гипотеза формалаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү, мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — геройларның эчке дөньясын, тормыштагы максатларын ачуда психологизм алымының әһәми-

ятен аңлау, психологик анализ ясый белү, әсәрнең идеясен табу, «романтизм», «романтик герой» төшенчәләрен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 83—105.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү.

Укучылар әсәрне укып бетереп килгәннәр. Алар өчен һәр геройның язмышы ачыкланган. Нәтиҗәләр белән кызыксынабыз. Төп геройларга аерым игътибар итеп, ярдәмче геройларны да күздән кичерәбез һәм турыдан-туры дәреснең бүгенге максатына чыгабыз.

*Ни өчен язмышлар шулай тәмамлана? Автор ни әйтергә тели? Әсәрдә нинди проблемалар күтәрелгән? Чишелештән чыгып, әсәрнең идеясе нинди дигән сорауга ничек җавап бирербез?* сорауларын биреп укучыны уйландырабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Актуальләштерү этабындагы сораулар нигезендә дәреснең темасы, максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен чишү.**

Укучыларның әсәр өзеген укып бетерүләрен истә тотып, әсәрдәге башка геройлар турында да әңгәмә дәвам ителә. Җәләш мулла, Сабир, Зыя, Госман, Мәрьям, Фатима бикә, Камилә образлары турында үзләренең фикерләрен әйтәләр.

Укытучы, нәтиҗәгә килү өчен, бу геройларга автор салган мәгънәне ачарга ярдәм итә. Әсәрдә геройларның тормышы аларның теләкләре, сәләтләре һәм мохит (яшәү тирәлеге кануннары) арасындагы каршылыклар аша тасвирлана.

Иң элек, Җәләш мулланың табигате үз нәселе, үз мохитенә тәңгәл түгел. Анда ата-бабаларына хас абруй да, мәшһүрлек тә юк, бары үзен зур куярга омтылу, эгоистлык кына. Беренче бәхетсезлегенең сәбәбе шул. Икенчедән, ул табигатенә салынган эгоистлык, башкалардан үзен өстен булып яшәве өчен мөмкинлекләр ачылмый. Шәһәр мәдрәсәләренең берсендә дәрәҗәле мөдәррис булырга бик теләсә дә, авыл мулласы гына булып яши. Ир уртасы яшенә җитеп, үзе булдыра алмаган абруйны, шөһрәтне балалары аша яуларга теләгәндә, аңа мохит, ягъни уллары һәм шәхси дошманнары каршы чыга. Сабир да, Зыя да ул теләгән шөһрәтләрне китерергә теләми. «Заман вә табигать тәэсиреннәндерме, атаның әмәле белән балаларның гамәле каракаршы килеп бәрелештеләр...» — дип искәртелә бу хакта әсәрнең үзендә. Соңгы өмете булган Зыяны да авылдагы көндәш-дошманнары солдат хезмәтенә озаттыралар. Шулай итеп, Җәләш мулланың табигате, холкы һәм мохит арасындагы көрәш аның файдасына түгел, ә мохитнең җиңүе белән тәмамлана.

Мохит белән каршылыкка керү башка геройлар язмышында төрле финал белән тәмамлана. китерә. Мәрьям, Сабир, Госман, Фатима бикәләрнең мохит белән көрәше нәрсәнедер югалту, корбан итүгә китерә. Укымышлы, сәләтле, нык холыклы Сабир үзе теләмәгән мохиттән азат булу өчен гади җир кешесе булып китә, укымаган, гади кызга өйләнә. Госман, Фатима бикә образларында мохит белән ихтияри ризалашу күрсәтелә, әмма бу аларга һич тә эчке канәгатьлек, күңел тынычлыгы бирми. Мәрьям, ирегеннән мәхрүм ителеп, каторгага сөрелә. Ә менә тормыш максатлары бик чикле, тар булган Камилә өчен үз гаиләсе — тулы бер дөнья, ул шуннан башканы күрми һәм күрергә дә теләми. Г. Ибраһимов мондый мохит колларының җәмгыять үсеше өчен бер файда да бирә алмауларын ассызыклый. Әсәрдә хәтта Сабирлар токан мәсләк тә (юл да) акланмый. Үз-үзеңне алдау, көрәштән качу буларак кына аңлашыла. Язучы фикеренчә, нәкъ менә мохит колына әверелмәгән, табигый яратылышлырына тугры калганнар, үз идеалларына максатчан баручылар гына дөньяны үзгәртергә сәләтле. Димәк,

автор идеалы Зыя обрызында гәүдәләнеш ала. «...Мохит вә табигать! Булар һәркемнең хәятында иң зур рольләрне үзләренә алалар. Без яхшы булу, тырышу, тәрбия ителү, теләк вә ирадә (*омтылу*) хакында сөйлибез. Ләкин бик күп тугрыда, бик күп бәндәләр хакында болар буш сүзләр генә булып кала. Бер адәмнәр мохиткә җиңелү, язмыш агымына буйсыну түгел, мохитнең үзен җиңәләр, язмышны үзләре теләгән якка борып җибәрәләр. Ләкин булар — Тәңренең артык мөстәсна (*башкалардан аерып алынган*) коллары. Алар меңгә, миллионга түгел, ничә йөз миллионнарга бер генә, ничә гасырларда бер мәртәбә бичара адәмнең артык буш хәятына бер яңалык, бер байлык бирү өчен генә җибәреләләр...» — диелә әсәрдә. Димәк, әле Зыялар, Сабирлар теләгән искене кире кагу сәгате алар язмышына язылмаган. Әмма андый «берәү» булачак, «артык буш» хәятны нурландырып җибәрер вакыт үз каһарманын гына көтә ди, автор. Романда чагылыш тапкан милләт язмышы өчен борчылу, рухның ирекә омтылуы, акыл көче һәм рухи азатлыкка ирешү аша милләткә хезмәт итү идеяләре дә шуны раслый.

Зыяның үлеме аның җиңелүе түгел. Ул — калганнарга нәтиҗә ясау өчен этәргеч. Кешенең рухын басып, талантына төрле киртәләр корып, хыял канатларын сындырып, хисләренә богау салып, кол хәлендә яшәргә, аерым кысаларда гына фикерләргә һәм гамәл кылырга мәҗбүр иткән җәмгыять үсешкә ирешә алмый.

Геройларның холкы, теләк-максатларын, эчке һәм тышка каршылыкларын бәяләү аша әсәрнең идеясе, фәлсәфи тирәнлеге ачыла.

Мәрьямнең психологик кичерешләренә, әсәрдә психологизм бирелешенә аерым тукталына.

Әсәр автор хикәяләвенә корылган. Ул күпчелек геройларының эчке халәтен, уй-тойгыларын тирән психологик кичерешләр аша тасвирлый. Аларның портреты, тышкы кыяфәте рухи дөньялары белән бәйләнештә сурәтләнә. Геройларның эчке дөньясын ачуда күңел монологы зур роль уйный. Хат рәвешендә бирелгән күңел монологлары да әсәр тудыруда бер сәнгати алым булып тора.

Табигать пейзажның геройларның күңел халәтен ачуда әһәмияте зур. Романның ахырында бирелгән табигать тасвирланышы әхлакый-фәлсәфи тирәнлеге белән җәлеп итә.

«Романтизм» һәм«романтик герой» төшенчәләре аңлатыла.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Кыска сораулар белән генә әсәрнең темасы (шәхес азатлыгы һәм милли азатлык), идея-проблемасы (мохит коллары иҗтимагый үсешкә этәргеч бирә алмый һ.б.) пафосы (романтик, трагик) ачыклап кителә.

**VI. Өй эше бирү.**

Зыя образына характеристика язарга.

Җәмгыять һәм шәхес темасына кечкенә инша язарга тәкъдим итәргә мөмкин.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт (Гаяз Исхакыйның «Көз» повестенда урын һәм вакыт бердәмлеге).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — максатчанлык, ихтыяр көче булдыру, гамәлне ахыргы нәтиҗәсен уйлап эшләргә өйрәнү, милли яшәеш кануннарына хөрмәт саклау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби күренешләрне өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, үз фикерләреңнең һәм башкалар фикерләренең дөреслеге турында гипотеза формалаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерләрен әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — «хронотоп» төшенчәсен үзләштерү, әсәрдә аның үзенчәлекләрен билгеләү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Ка-

зан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 108—119.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *Һәр вакыйга урын һәм вакыт белән бәйле. Сез бу фикер белән килешәсезме?* соравына укучыларның фикерләре тыңлана. Мисаллар белән дәлилләнә. Әйтик, безнең бүгенге дәресебезнең урыны һәм вакыты булуы һ.б.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы сөйләшүгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Укытучы «хронотоп» төшенчәсе һәм әдәби әсәрләрдә аның үзенчәлеге белән таныштыра. Әдәби хронотоп чынбарлыктагы вакыт һәм урын белән тәңгәл түгел, ул язучы ихтыяры белән тудырыла. Кыскача гына әсәр хронотобын ничек билгеләргә мөмкин икәнлеге ачыклана.

1. Автор әсәр исеменә үк хронотопны чыгара ала (Г. Исхакыйның «Көз», З. Хәкимнең «Кишер басуы» һ.б.).

2. Әсәрдән реаль тарихи шәхесләрнең исемнәре, аларның сурәтләнә торган вакыйгалардагы урыны хронотопны ачыкларга ярдәм итә. Әгәр тарихи шәхес бу вакыйгаларда үзе катнаша икән, димәк, әсәр вакыты аның яшәү елларына туры килә (А. Расихның «Ямашев» трилогиясендә Хөсәен Ямашев һәм башка тарии шәхесләр, Н. Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәрендә Алмыш хан, һ.б.).

3. Шулай ук әсәрнең предмет-образларына, бигрәк тә көнкүреш әйберләренә, кием-салымга, аерым сүзләргә игътибар итү кирәк. Мәсәлән,

Ф. Яруллиның «Җилкәннәр җилдә сынала» әсәреннән өзек: «*Батырлык! Нәрсә соң ул батырлык? Газинурлар,*

*Матросовлар шикелле күкрәгең белән дошман амбразурасын каплаумы, әллә үзең ач чакта соңгы сынык икмәгең белән бүлешүме? Кешеләр төрле-төрле булган кебек, батырлык та күптөрле шул». Газинурлар, Матросовлар шикелле күкрәгең белән дошман амбразурасын каплаумы?»* әлеге өзек вакыйгаларның Бөек Ватан сугышыннан соңрак булуын белдерә, чөнки әлеге сугышта батырлык күрсәткән геройлар телгә алына.

Г. Исхакыйның «Көз» әсәре сыйныфта беркадәр укыла. (Мәсәлән, 109—119 нчы битләр.) Укылган өлештән әсәр хронотобын билгеләүче образ-детальләр табыла. Тормыш тәртипләренә (кыз кешегә театрга ялгыз йөрү тыелу һ.б.) гаиләдәге мөнәсәбәтләргә нигезләнеп, әсәрдә тасвирланган вакыт билгеләнә. «Көз» сүзенең ел фасылы гына түгел, кешеләрнең өлгергән, тормышының җитлеккән чоры буларак та аңлашылуына игътибар бирелә. (*Гөлсем белән Нәфисә инде яшьлек чорын үтеп, гомерләренең көзенә аяк басканнар.*)

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әдәби әсәрдә хронотоп төшенчәсенең үзенчәлеген ачыклау өчен сорауларга җаваплар бирелә. Геройлар язмышы ничек булганлыгы турында фаразлап әңгәмә үткәрелә.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрнең дәреслектәге өлешен укып бетерергә. Дәреслектә 120—139 нчы (145 нче) битләр

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Гомер көзенең җимешләре татлы булсын дисәң... (Гаяз Исхакыйның «Көз» әсәрендә геройлар язмышына мөнәсәбәтле хронотопик образлар).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — кешеләрнең хокукларын, ихтыярларын һәм законлы мәнфәгатьләрен хөрмәт итү; тормышта һәр нәрсә көрәш, тырышлык, гамәл кылу белән яуланганлыгын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, контекстны исәпкә алу һәм уку мәсьәләсен чишү барышында килеп чыгарга мөмкин кыенлыкларны алдан күрү, чишелешне үзгәрүчән шартларга яраклаштыру; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби күренешләрне өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, үз фикерләреңнең һәм башкалар фикерләренең дөреслеге турында гипотеза формалаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерләрен әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — әсәрдәге хронотопларның мәгънәсен ачыклау, перцептуаль хронотоп үзенчәлеген аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 120—145.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү

1. Укып килгән өлешнең эчтәлеге искә төшерелә (эчтәлекне кыскача сөйләү).

2. *Әсәр белән танышкач, күңелегездә нindidер сорау, фикер уянды? Әсәр геройларына кыскача гына бәя биреп, үз мөнәсәбәтегезне белдерегез. Ул геройга карата күңелегездә нинди хис сакланып калды? Бәлки, аларгаа бирәр киңәшегез бардыр*? кебек сорауларга җаваплар тыңлана.

Укучыларның Гөлсемне кызганулары, аңа теләктәшлеге, Нәфисәне хуплаулары өстенлек итәр. Аларның фикерләре тыңлана, ләкин нәтиҗә ясарга ашыкмасак яхшы.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Әңгәмәгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

«Көз» әсәрен өйрәнгәндә, хрононоп бирелешенә игътибар итәргә тиешлекне искә төшереп, сорау куябыз:

*Әсәрдә вакыйгалар эзлеклелеген искә төшерик* (Пароходта Гөлсем белән Нәфисәнең очрашуы, Нәфисәнең яшьлеге, Хәлил белән очрашуы; Гөлсемнең яшьлеге, Хәлил белән очрашуы; пристаньда очрашу, юл чатында аерылышу). Бу вакыйгалардагы урыннарга игътибар ителә.

*Вакыйгаларны чынбарлыктагы тәртибе белән урнаштырырга тәкъдим ителә.* (Гөлсемнең яшьлеге, Хәлил белән очрашуы, Нәфисәнең яшьлеге, Хәлил белән очрашуы; пароходта Гөлсем белән Нәфисәнең очрашуы; пристаньда очрашу, юл чатында аерылышу). *Димәк, автор геройлар язмышын сурәтләүдә реаль вакыт эзлеклелеген сакларга теләми. Ни өчен?*

Автор башта нәтиҗәне күрсәтә, алга таба аның сәбәпләрен ача. Гөлсемнең беренче мәхәббәте булган Паша-Хәлилнең Нәфисәнең ире икәнлеген дә әсәр ахырына кадәр сер итеп саклый. Бу укучыны тагын да ныграк тәэсирләндерә. Тормышта бер ханымның бәхетле, икенчесенең бәхетсез булуы гына түгел, ә аларның юлларына очраган бәхетнең бер үк икәнлеген күрсәтә. Гөлсем Хәлил белән Нәфисәгә караганда күпкә алданрак таныша. Ләкин ул бу бәхетен югалта. Мирза кызы Гөлсемнең кызганыч гаилә тарихын сөйләп чыкканнан соң, автор бу гаилә турында укучыларны да кызыксындырган сорауны Нәфисәдән бирдертә: «Ник соң бу болай? Ник болар уртача гына бәхет берлә тора алмаганнар? Ниләре җитешмәгән, икесе дә укыган, икесе да тәрбия күргән... Икесе дә яшь булган... Икесе дә бай булган... Ник?» Әлеге соруга җавап укучылар белән эзләнә.

Моның өчен автор Нәфисәнең мохитен (пространствосын) ничек сурәтләвен ачыклыйбыз.

Нәфисә сәүдәгәр гаиләсендә туып, мөселманча аң-белем һәм тәрбия ала. Ул укырга-язарга башлап туган телендә өйрәнә, русча да укый, театрларга, төрле кичәләргә йөри. Әмма гаиләдәге кануннарның кырыслыгы Нәфисәгә милли яшәеш кысаларыннан чыгарга мөмкинлек бирелми. Шулай итеп, аның яши торган пространствосы (тирәлеге) тышкы яктан

ачык булып тоелса да, нигездә ул, ябык пространствоны хасил итә.

Нәкъ менә шул катгый кануннар Нәфисәгә тормышта үзен ышанычлы хис итәргә, киләчәгенә аек акыл белән карарга, алга таба үз язмышын үзе билгеләүче, көчле ихтыярлы шәхес булырга ярдәм итә. Кануннарны бозмыйча, әдәп саклап кына, ул үз максатына бара.Үзенең хаклы булуына нык ышануын ул түбәндәгечә сөйли: *«Беркемнән киңәш сорамадым. Беркем берни өйрәтмәде. Уйлап та тормадым. Күңелем ни кушты, шуны эшләдем»*. Һәрнәрсәне бары ул гына хәл итүенә тирән ышаныч белән яшәгән әтисенең планнарын җимереп, үзе яраткан кешегә кияүгә чыгуга ирешә. Ире Хәлил Нәфисәнең күңеленә бик якын милли рухлы булу белән бергә, сәләтле һәм булдыклы доктор да булып чыга. Автор Хәлил белән Нәфисәнең киләчәк турында кайгыртып, балаларына милли мохиттә тәрбия бирергә тырышуларын да сөйли. Хәлил Мәскәү янындагы бер татар авылында «кечкенә генә җирле, сулы, бакчалы бер утар» сатып ала. Нәфисә бу эшнең нәкъ менә балаларга милли тәрбия бирү максатында эшләнүен сөйли.

Гөлсем яшәгән мохит анализлана һәм аның Нәфисәнекеннән аермасы күрсәтелә.

Гөлсем — мирза кызы. Кечкенә вакытта ук аның әнисе үлә. Ул үзе дә урыслашкан, милли тормыш, гореф-гадәтләребездән бик ерагайган ханым булган тутасы карамагында үсә. Җәй көне әбисе янына утарга кайткач, мөселман кануннары буенча яшәүче бу мохит, бу пространство аңа башта чит булып күренә, әмма күңеле белән ул аның үз якын булуын да тоя, ул чит пространствоны үзенеке итеп кабул итмәкче булып, мондагы кануннарга буйсынып яши башлый. Ләкин бу озакка бармый һәм Гөлсем үзе яшәргә күнеккән даирәгә әйләнеп кайтырга мәҗбүр була. Күңеле белән үзенең кыйбласын билгели алмау, гореф-гадәтләреннән аерылу, икенче мохиткә кереп бетмәү, Гөлсемнең үз үзенә ышанычын югалта. Ул үз язмышын үзе хәл итү югарылыгына күтәрелә алмый, язмыш иркенә буйсынып, үзе теләмәгән мохит кысаларында ябылып кала.

Гөлсемнең пространствосына Паша түбәндәге бәяне бирә: *«Тирә-юнегез баткаклык, эчкән суыгыз сазлык суы, сулаган*

*һаваңыз черегән сазлык һавасы, монда гөлгә үсәргә, гөл булып яшәргә имкян юк. Бу тирә-юньдә сез бетәчәксез, сез дә башкалар кебек сазлыкка батачаксыз*».

Паша белән очрашу Гөлсемгә бу мохиттән (пространстводан) котылу мөмкинлеген ача.

Паша белән уртак булган пространство Гөлсемне тулысынча канәгатьләндерә, ул хыял эчендә, чынбарлыктан аерылган башка тормыш белән яши башлый (әсәр өзеген укып бәяләнә). Әмма Гөлсемнең тулысынча анда калырга ихтыяр көче җитми, аның бәхет өчен көрәшергә сәләте юк. Шул рәвешле әсәрнең шул өлешендә перцептуаль хронотоп ачыла.

Паша һәм Гөлсемнең юллары төрле булуларына автор алдарак та искәртә: юлда барганда аларның икесе ике арбада барулары шуңа ишарәли.

Әсәр идеясенең төп ачкычы булган көз хронотобы әсәр исеменә үк чыгарылган. Көз ел фасылы, әмма әсәрдә ул гомер көзен дә гәүдәләндерә дигән идек. Һәр ике героиняның үз көзе. Автор Гөлсемнең тормышын көзге яңгырлы салкын төндә, шыксыз Идел (бу — тормыш агышын гәүдәләндерүче хронотоп) «куе караңгылык эченә батып, шул төпсез-чиксез караңгылыкны ертып алга барырга маташучы, никадәр ыңгырашып кычкырса да, ялварса да, җавап таба алмаучы» пароход белән тиңли. Әсәрнең икенче героинясы — Нәфисәнең бу үзәккә үтә торган салкынлыкта, бу газап белән алга баручы пароходта гаме дә юк. Ул җылы каютасында «татлы хыяллар дөньясын сөйли торган җылы китап эченә» чумып утыра.

Әсәр ахырында автор тормыш агышын гәүдәләндергән Идел образына игътибарын юнәлтә (өзек укыла). Тормыш дәвам итә, аның үз агышы, үз матурлыгы. Әмма язмышлар төрле. Шуны дәлилләп, әсәрдә героиняларның эчке халәтен кабат янәшә куеп чагыштыра: «*Төн ауды, таң атты, тирә-юнь яктырды. Ике хатын тагы бик озак сөйләшкәннең соңында, берсе иртәгә бәхетле көнен көтеп, икенчесе иртәгә янына киләчәк бәлане көтеп йокыга киттеләр... Иртәнге яктыда Гөлсемнең яшьли картайган битен бик күп җыерчыклар каплады. Эчкә җыя алмый күзләрдән ташып чыккан бәхет елмаюы Нәфисәнең йөзенә яшеннән дә артык*

*яшьлек буявы сөртте*». Дәрес башында куелган сорауларга җаваплар табуга киленә.

*Ни өчен автор реаль вакыт эзлеклелеген үзгәртә?* (Иң элек Гөлсем һәм Нәфисәнең төрле язмышын ача, алга таба аның сәбәпләрен ачыклый. Нәфисәнең бәхете Гөлсемнең бәхетсезлеген тагын да тирәнрәк аңларга ярдәм итә).

*Гөлсем ни өчен бәхетсезлеккә дучар булган?* (Укучылар җавабы тыңлана һәм тулыландырыла.)

Милли асылыннан ераклашкан, иман ныклыгы булмаганнар үзәге черек агач сыман, аларның язмыш җилләренә каршы тора алырлык ныклыгы юк. Килеп бәрелгән беренче давыл ук аларны тамырыннан кубарып ташлый. Шуңа һәркем милли асылын, телен иманын саклап яшәргә тиеш.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Көз» әсәрендәге геройлар язмышын аларның сәбәпләрен ачу хронотоп үзенчәлеген ачарга ярдәм иткән сораулар бирелә.

**VI. Өй эше бирү.**

«Һәркемнең үз көзе» темасына кечкенә инша язарга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Җырга тиң мәхәббәт (Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестенда хронотоп бирелеше).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — кешеләрнең хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен хөрмәт итү; гаилә бәхетенең нигезен күзаллау, авырлыклар алдында югалып калмау, үз хаталарыңны күрә һәм төзәтә белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби күренешләрне өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, үз фикерләреңнең һәм башкалар фикерләренең дөреслеге турында гипо-

теза формалаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — «хронотоп», «эпистоляр стиль» төшенчәләрен белү, әсәрнең эчтәлеген, идеясен аңлау, геройларга бәя бирү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 147—188.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Әдәби әсәрнең язучы тарафыннан тудырылган тормыш моделе икәнлеген искә төшереп, анда да һәрнәрсә урын һәм вакыт төшенчәсенә ия булуын ачыкларга кирәк. Әйтик, бүгенге дәрес, аның урыны һәм вакыты бар. Дәрестәге һәр эш тә урын һәм вакыт ягыннан характерлана ала.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы әңгәмәгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әдәби әсәрдә «хронотоп», «ачык һәм ябык пространство», «перцептуаль (субъектив) хронотоп» төшенчәләренең үзенчәлекләренә тукталып, бу сәнгати алымны өйрәнү өчен Г. Кутуй иҗатына, аның «Тапшырылмаган хатлар» әсәренә тукталачаклары әйтелә.

Г. Кутуйның тормыш юлы белән таныштырыла. Г. Кутуй үзенең әсәре турындагы болай дип яза: «Мин «Тапшырылмаган хатлар»да безнең чорның татар хатыны турында, аның бай һәм матур эчке дөньясы турында, сәләтлелеге турында сөйләргә теләдем». Әлеге фикергә кабат нәтиҗә ясаганда әйләнеп кайтырга туры киләчәге дә искәртелә.

*Нинди хатлар язучыны әсәр иҗат итәргә этәрде икән?* Әлеге сорауга җавап итеп, сыйныфта әсәрнең бер өлеше белән танышыла. (Татар телендә белем бирүче мәктәпләрдә беренче хат, рус телендә белем алучылар өчен беренче һәм икенче хатларны укый)

Әсәрне хронотоп бирелеше ягыннан өйрәнергә тиешлекне истә тотып, сөйләшү шул юнәлешне ала.

«Тапшырылмаган хатлар» әсәрендә ачык пространство өстенлек итә Урам, Кабан күле, «Швейцария» бакчасы, Идел кебек хронотопларның мәгънәсе ачыклана.

Әсәрдә хронотоп ике параллель яссылыкта бара: Галия хатларында үткәннәр турында сөйли, шул ук вакытта ул хатны язу вакыты белән дә үрелеп бара. «Менә хәзер дә үзем сиңа хат язам, үзем радио аркылы Шубертның «Язылып бетмәгән симфония»сен тыңлыйм», — дигән фикер шуны раслый.

Геройның үткәндәге вакыйгаларын сөйләве перцептуаль вакыт, ул хәзерге мизгелне сузып, үткән вакыт белән тоташтыра. Ретроспекция алымы перцептив хронотопның нигезен тәшкил итә.

Әсәрдәге ачык пространство образларының берничәсе аерым игътибарга алына. Мәсәлән, Кабан күленең ташыган вакыты (*Кабан күле тирәсе чын-чынлап Венециягә — су шәһәренә охшап китте. Ләкин бу матурлык шәһәребезгә күп кенә зарарлар да китерде. (Матурлыкның да ямьсез ягы була икән.*)

Кабан күленең язгы ташы — Галия белән Искәндәрнең мәхәббәткә бирелгән вакытлары. Әмма бу мәхәббәтнең гомере дә язгы ташу кебек вакытлы гына булып чыга. Әсәрдә әйтелгәнчә, матурлыкның ямьсез ягы килеп туа, ул гаиләнең таркалуына китерә.

Яз хронотобы да мәхәббәтнең матур вакытын гәүдәләндерә. Ләкин яз үткән кебек мәхәббәтнең дә гомере чикләнгәнлеге ачыла. Аның да көзе килә. (*Көз көне мин Казан университетының медицина факультетына укырга кердем. Бу көзгә хәтле безнең тормыш яхшы барды. Ә көз көне иртә чәчәк аткан мәхәббәтебезнең хуш исле яфраклары арасында сары яфраклар күренә башлады.)*

Идел хронотобы тормышның авырлыкларын үтеп, тыныч агымга күчүне гәүдәләндерә (*Искәндәр сиңа тормый, дип үземне кулга алдым да, башымны югары күтәреп, алга, күп кайгы күргән Иделнең тынычлыгына карадым.*)

Г. Исхакыйның «Көз» әсәрендә очрашуны белдергән пристань хронотобы Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» әсәрендә аерылышуны белдерә. Пароход бу очракта үткәннәрдән китү, яңа тормышка юл буларак аңлашыла.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әсәрдә хронотопик образларның вазифасын билгеләүгә юнәлтелә.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрнең калган өлешен укып бетерергә. Әдәби алым буларак хронотоп төшенчәсен аңлатырга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

*Беренче дәрестә вакыт ягыннан сыеша алмаган материал белән икенче дәрескә күчәргә мөмкин.*

**Тема**: Гаилә — тигез хокуклы кешеләр союзы ул (Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар повестенда геройлар язмышын ачарга ярдәм итүче хронотопик образлар).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — кешеләрнең хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен хөрмәт итү; гаилә бәхетенең нигезен күзаллау, авырлыклар алдында югалып калмау, үз хаталарыңны күрә һәм төзәтә белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — әдәби геройларның үзара мөнәсәбәтләре турында уйланып, башка кешегә, аның фикеренә аңлы рәвештә карау, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби күренешләрне өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, үз фикерләреңнең һәм башкалар фикерләренең дөреслеге турында гипотеза формалаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, аралашу шартларына һәм максатларына бәйле рәвештә эмоцияләрне белдерү.

*Предмет нәтиҗәләр* — әсәрнең эчтәлеген белү, идея-проблематикасын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б.151—188.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Хат язышу турында сөйләшү үткәрергә мөмкин. Хат үзеңнең хәлеңне, хис-кичерешләреңне уртаклашау өчен языла. Сине аңламаслар дип яки хисләр җаваплы булмас дигән уйлар, я башка сәбәпләр белән хат тапшырылмаска мөмкин. Менә шундый хатлар язучыга иҗат азыгы булганлыгы искәртелә. *Әсәр ахырында Галия тормышта гаилә бәхетен таба. Ләкин һәр очракта да бу шулай тәмамлана аламы? Әлеге хакыйкатьне үрнәк итеп кую дөрес булырмы? Гаилә кануннарын сез ничек күзаллыйсыз?*

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы сөйләшүгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әсәр белән танышканнан соң анализ ясарга, геройларга аларның гамәлләренә бәя бирергә һәм гаилә тормышына укучыларның фикерләрен дә тыңлап әхлакый, тәрбияви нәтиҗәләр дә ясарга, тормышчан киңәшләр дә бирергә мөмкинлек ачыла.

*Әсәрне сез теләп, яратып укыдыгызмы? Ни өчен? Авторның үзенең геройларына мөнәсәбәте нинди? Сез автор позициясе белән килешәсезме? Ни өчен?* кебек сорулар ачыклана. Беренче дәрестә Г. Кутуйның: «Мин «Тапшырылмаган хат-

лар»да безнең чорның татар хатыны турында, аның бай һәм матур эчке дөньясы турында, сәләтлелеге турында сөйләргә теләдем», — дигән фикере белән танышканнар иде. Чыннан да, автор Галияне яратып, урыны белән идеальләштереп тә бирә. Ниндидер караңгы авылдан белеме булмаган кешеләрнең ятим калган кызы Казанга килә, университетка укырга керә, табиб була, берничә тел белә, дөнья буйлап сәяхәт итә, очраклы рәвештә Вәли белән очрашып бәхетле була.

*Сезнең Галиянең эш-гамәлләренә, тормышка карашларына карата фикерегез нинди?* Укучыларның фикерләрен тыңлап, укытучы нәтиҗә ясый: әлбәттә, Галия идеаль кеше булырга тырыша: җәмгыятьтә үз урыны булган һәм тормышта үз максатлары булган хатын-кыз булырга тели. Галиягә үз теләкләре, хыялары һәм сайлау иреге кадерле. Шул ук вакытта, ул бәхетле гаилә төзү өчен дә барысын да эшләргә тырыша. Ләкин хатын-кыз ике тормышны да (гаилә һәм җәмгыять) бертигез алып бара алмый. Галиянең дә беренче планга җәмгыять белән бәйле тормышы алга чыга, ә гаилә икенче планга күчә. Ул идеаль ана итеп сурәтләнә: «Эштән арткан һәрбер минутымны мин балаларыма биреп килдем. Миңа алар янында ана да, ата да була белергә кирәк иде». Ул балалары өчен борчылып, аларны кайгыртып яши (радио куйдыра, пианино алырга тели һ. б.). Гаилә таркалуда Галияне бөтенләй гаепсез түгел.

Укучылар Искәндәрнең Галиягә куйган таләпләренә үз мөнәсәбәтләрен белдерәләр һәм Искәндәр белән Галиянең нәрсәдә хаклы, ә кайсы очракта хаксыз булуларын ачыклыйлар.

Әсәрдә Искәндәргә тәнкыйть күзлегеннән карала һәм гаиләне таркатуда гаепләнә. Билгеле, геройлар романтик рухта сурәтләнгәнлектән, хәтта Искәндәр дә, каршылыклы образ булуга карамастан, автор тарафыннан бизәп, матурлап күрсәтелә.

*Искәндәр генә гаепleme? «Тапшырылмаган хатлар» әсәрендә вакыйгалар Галия исеменнән сөйләнә һәм бәяләнә. Әгәр хатларны Галия урынына Искәндәр язган булса, ул бу вакыйгаларга нинди бәя бирер иде?* Шул турыда сыйныфта фикер алышу үткәререргә мөмкин. Галиянең әлеге фикерен дә аңлатып китү урынлы булыр.

Мәхәббәт — башка кеше язмышына карата җаваплылыкны үз өстеңә алу. Яраткан кешең, балалар язмышы өчен җаваплылык. Җавапсызлык кешеләрне (башкаларны һәм үзен дә) бәхетсез итә. Әлеге нәтиҗәне ясау дөрес булыр.

Бу дәрестә перцептуаль (субъектив) вакыт төшенчәсенә игътибар бирелә. Укучылар Г. Исхакыйның «Көз» әсәрендә инде аның белән танышканлыгын истә тотылып, Галиянең Искәндәргә гашыйк булып татлы хыяллар белән яшәгән вакытына бәя бирәләр. Геройларның тормышын ачуда үткән/хәзер (Галиянең үткән тормышы һәм хәзер аның тормышында ачылган мөмкинлекләр), хәзер/киләчәк оппозицияләре аңлатыла. Җимерек амбулатория Галиянең тәртипкә китерәсе тормышы белән янәшә куела.

Тыныч якты Идел өсте тыныч киләчәк вәгъдә итә, һ. б. детальләр аша әсәрдәге хронотопларның герой язмышын аңларга ярдәм итүе ачыклана.

Эпистоляр стильнең үзенчәлекләре ачыклана. Хатлар хронотопның киң мөмкинлекләре булуы күрсәтелә. Психологик кичерешләрне ачу мөмкинлегенә тукталына.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектә бирелгән сорауларга нигезләнергә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәр турында шәхси фикерләрегез белән уртаклашып, кечкенә инша языгыз.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

Әсәр турында шәхси фикерләрегез белән уртаклашып, кечкенә инша языгыз.

**Тема:** Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт. Лирик әсәрләрдә хронотоп бирелеше (Марсель Галиевнең «Кичке сурәт» шигыре).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — хәтернең кешелек өчен зур байлык булуын аңлау, үткәннәргә карап нәтиҗә ясый белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; аралашу шартларына һәм максатларына бәйле рәвештә эмоцияләрне белдерү, үз фикерләрен әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — лирик әсәрдә хронотопны ачыклый алу, шигырьнең идеясен аңлау, лирик геройның хисләрен, хисләрнең сәбәбен күрсәтә алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 188—189.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Укучыларга берничә өзек тәкъдим ителә һәм сораулар куела.

*Сезгә бу әсәрләр танышмы?*
*Алар нинди жанрларга карый?*
*Бирелгән өзекләрдә урын, вакытны ачыкларга мөмкинме?*

*Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл — Кырлай диләр;*
*Җырлаганда, көй өчен «тавыклары җырлай» диләр.*
*Гәрчә анда тугъмасам да, мин бераз торган идем,*
*Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем.*

*(Г. Тукай. Шүрәле.)*

*Яз, яз, яз җитә,*
*Тәрәзәне ачтылар.*
*Тып, тып, тып итә*
*Эре-эре тамчылар*

*(Ф. Кәрим. Яз)*

*Кеше китә — җыры кала, диләр,*
*Бер җыр калсын әле бездән дә.*
*Ул җыр җанга шатлык булып керсен,*
*Кояш булып кунсын йөзләргә.*

*(Фәнис Яруллин. Җыр калдырыйк.)*

Укытучыга үзе теләгән әсәрләрдән өзекләр сайлап алырга мөмкин. Жанр төрлелеге, хронотоп ачык билгеле булган һәм төгәлләштерелмәгән, әмма тоемлау мөмкин булган өзекләр сайланырга тиеш. Мәсәлән, Ф. Яруллин шигырендә урын-вакыт төгәлләштерелми, әмма ул хәзер һәм киләчәк буларак аңлашыла. Вакыт һәм урынның чикләнмәгәнлеге сизелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы сөйләшүгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

М. Галиевнең «Кичке сурәт» шигыре укыла. Алдагы сыйныфларда өйрәнелгән лирик әсәрне анализлау тәҗрибәсенә нигезләнеп, кыскача гына, шигырьнең эчтәлеге, лирик геройның хисләре, ул хисләрне тудырган сәбәпләр, автор әйтергә теләгән фикер ачыклана.

Шуннан соң шигырьдәге хронотопны ачыклауга күчелә.

Шигырьнең исеменә игътибар ителә, ул вакытны билгели: кич. Шигырьдән вакытка мөнәсәбәтле булган башка сүзобразлар табыла. Алар — төн, шәфәкъ кызыллыгы, борынгылык, гасырлар, хәтер, көн егылу, көн белән төн чиген узу, мизгел.

Лирик герой кич сурәтен кайдан торып күзәтә дип фаразларга мөмкин?

Лирик герой тәрәзә аша (урын — ябык пространство) кичке табигатьне күзәтә. Моны шигырьдәге «Тәрәзәдәге бәллүр тамчылар да шәфәкъ кызылына манчылган» дигән юллар дәлилли.

Шигырьдән кичке вакытны белдергән урыннар табып күрсәтелә: «көн егылгач офык мендәренә», «көн белән төн чиген узган чакта».

Шәфәкъ кызыллыгына манчылган болытлар, изүләрен ачкан офык, хәтер лирик геройны ябык пространстводан ачык пространствога — чиксез галәм киңлегенә алып чыга. Төн вакытында уй йөгереклеге белән ул ерак гасырларга, Җир хәтере аша галәм киңлегенә тоташа. Сорауларга җавап эзли. Аерым тарихи вакыйгалар («Хәрабәле, канлы манзара») мәңгелек вакыт агышына тоташа. Нәтиҗәдә лирик герой шундый фикергә килә: Мәңгелек вакыт агышында кеше гомере — бер мизгел, атылган йолдыз кебек кенә. Әмма кеше гомере мәңгелек вакыт агышыннан аерылмаска тиеш. Ул үткән белән киләчәкне тоташтыручы. Ул — үткәнне хәтерләргә, бүгенгедә яшәргә, киләчәк турында кайгыртырга бурычлы. Лирик герой тормыш тәҗрибәсе туплаган, зирәк, яшәешне фәлсәфи югарылыкта бәяли алырлык шәхес буларак күз алдына килә.

Шигырьдә вакыйга барган вакыт (лирик геройның тәрәзә аша кичке күренешне күзәтү вакыты абстракт вакыт белән алышына. Вакытны сурәтләгәндә, *төн — көн, гасырлар — мизгел, Җир — күк, үткән — хәзер* кебек бинар оппозицияләр (каршылыклар) шигырьгә салынган фәлсәфи фикерне тагында тирәнәйтә.

Шигырьдә вакыт һәм урын бердәмлеге лирик геройның кичерешләрен, рухи дөньясын, тормышка карашларын ачарга ярдәм итә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектәге сорауларга нигезләнергә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

М. Галиевнең «Кичке сурәт» шигырен сәнгатьле итеп укырга, шигырьгә нигезләнеп, рәсем ясарга тәкъдим итәргә мөмкин.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Нәтиҗәләр чыгару. Контроль эш.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — тырышлыкның нәтиҗәсен, белемнең әһәмиятен күрә белү, әдәбиятның тормыш мәктәбе булуын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — эшчәнлек нәтиҗәләренә ирешү (ирешмәү) сәбәпләрен исәпкә алу, алган тәҗрибәгә бәя бирү, билгеле бер ситуациядә уңай якны таба белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; куелган уку бурычын чишү өчен, кирәкле җитешмәгән мәгълүматны ачыклау, нәтиҗә чыгару, гомиләштерүләр ясау, мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерләрен әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — белемнәрне гомумиләштереп системалаштыру.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 8 нче сыйныф. Ике кисәктә : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Һәрнәрсәгә кайчандыр йомгак, нәтиҗә ясалуы, һәр эшнең ахыры булуы, бу нәтиҗә ясау киләчәккә планнарны, максатларны билгеләү өчен кирәклеге турында әңгәмә үткәрү мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Еллык нәтиҗә ясауны укытучы үз тәҗрибәсеннән, сыйныфның мөмкинлеген һәм теләген дә исәпкә алып оештыра.

Ул гади дәрескә караганда кызыклырак та, белемнәре төрле булган укучыларның һәркайсына да уңайлы да булса яхшы. Шуның өчен биремнәрнең төрлесен сайлау, төркемнәрдә эшләү формаларында куллану файдалы.

Алдан әзерлекне дә таләп итә. Әйтик, укучылар сорауларны үзләре әзерли ала. Моның өчен аларга үрнәк бирү дә мөмкин. Мәсәлән, әдәби әсәрләрдән пейзаж, портрет һәм башка темаларны ачыкларга ярдәм итәрлек өзекләр һәм аңа карата сораулар әзерләп килә алалар. Бу сорауларны бер төркем икенчесенә, яки гадирәк сорауларны бер укучы икенче укучыга бирә ала. Сорауның дөрес куелышын да бергәләп бәяләргә мөмкин.

Дәрес барышында каралган материалны гомумиләштереп кую.

**VI. Өй эше бирү.**

Дәрестән тыш уку өчен әсәрләр тәкъдим ителә. Укытучы үзенең теләк, биремнәрен укучыларга җиткерә.

**VII. Рефлексия.**

1. Уку елы дәвамында өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

2. Бәяләү, үзбәя бирелә. Укучыларның фикерләре тыңлана.

Матур теләкләр, хушлашу сүзләре җиткерелә.

## ЭЛЕКТРОН РЕСУРСЛАР ИСЕМЛЕГЕ

www.antat.ru/ru/iyli/publishing/book/uchebniki — Дәреслекләрнең электрон формалары.

www.antat.ru/ru/tatzet — Татар теле: зур электрон туплама.

https://magrifat.antat.ru — Укытучылар, әти-әниләр һәм балалар өчен мәгълүмати ресурс.

https://photo.miras.info/№ — «Татарское визуальное наследие» сайты.

www.belem.ru — Татар мәгарифе порталы.

www.balarf.ru — Интерактив мультимедия китапханәсе.

http://tatarile.tatar — «Татар иле» укучылар өчен электрон энциклопедиясе.

www.ganiev.org — Русча-татарча тавышландырылган онлайн сүзлек.

www.tatarhistory.ru — Татарстан тарихы буенча электрон атлас.

www.tatarcartoon.ru — «Татармультфильм» берләшмәсе эшләгән анимацион фильмнар җыентыгы.

Учебное издание

**Абдуллина** Дилария Маратовна
**Мухарлямова** Гульназ Нурфатовна

РОДНАЯ (ТАТАРСКАЯ) ЛИТЕРАТУРА

**8 класс**

Методическое пособие
для преподавателей образовательных организаций
основного общего образования, работающих с обучающимися,
владеющими родным (татарким) языком

*На татарском языке*

Уку-укыту басмасы

**Абдуллина** Диләрия Марат кызы
**Мөхәрләмова** Гөлназ Нурфат кызы

ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ

**8 нче сыйныф**

Методик әсбап
Төп гомуми белем бирү оешмаларында
(туган (татар) телендә сөйләшүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

Мөхәррире *А. А. Дәүләтова*
Рәссамы *Д. Л. Нәүрузова*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *Л. И. Матвеева*

Подписано в печать с оригинал-макета 21.08.2024
Формат 60×84 $^{1}/_{16}$.